Безнең Мирас
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
04
апрель 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

«Сез бетәчәк түгел!»

26 нчы бит

Каһарман Гали маҗаралары

64 нче бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдеменд

Безнең МИРАС

12 +

04
(316)
апрель 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

50

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Хәсән Сарьян

ТАРИХИ МИРАС

4 Этрусклар – Рим остазлары. *С.Шәмси*
10 Мәмәтевләр нәселе – Бәрәңге төбәгенең горурлыгы. *Ф.Мусин-Мәмәтев*
15 Гөләйза кыйссасы. *Г.Хисамиев*
22 Җучи Олысының беренче ханбикәсе һәм ислам дине. *И.Миргалиев*
26 «Сез бетәчәк түгел!» (Ерак Шәрыкта Тукай кичәләре). *Л.Мортазина*
30 Габдулла Тукай иҗаты поляк телендә. *Л.Галиева*
34 «Кызыл Урал» газетасы. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
38 Мирхәйдәр Фәйзи: «Никах сәгатьләре сукмый бит!»
44 Шагыйрь тормышында Сосна Пучинкәсе. *Л.Мөхәммәтшина*
47 Исемең матур, кемнәр куйган? *Г.Хаҗиева*

22

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул итела. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Л.Усманованың «The Turk-Tatar Diaspora in Northeast Asia» (Токио, 2007) китабыннан, «Милли байрак» газетасыннан, А.Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

50 Ирек Шәрипов: «Мирасыбыз көндәшлеккә сәләтле!»
57 Гөләйза. *С.Галиева*

ДИНИ МИРАС

58 Ислам дөньясы. *Г.Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

64 Каһарман Гали маҗаралары
70 Мөһаҗирлектәге татар китабы. *Х.Миңнегулов*
74 Идел һәм Муса. *М.Хәсәнов*
78 Һәр солдатның үз язмышы. *Н.Гыйләҗева*
82 «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер». *Э.Шәрифуллина*
86 Тыйнак табигатьле каләмдәшебез. *М.Госманов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

88 Шәхесләребез: Галимҗан Латыйп, Хөснул Вәлиуллин һәм Зәки Нури

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 Гомерлек үкенеч. *Ф.Кутлу*
94 Истә, һаман да истә!
96 Сагыш. *Р.Сәгъди*

СӘНГАТИ МИРАС

101 Сау бул, авыл! Исәнме, Казан! *Х.Җәләлов*
106 «Урман кызы». *М.Фәйзуллин*
109 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

112 Яңа тарих язылганда... *Р.Низами*
113 Эт көннәре. *Р.Сафаров*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Апрель*

Заказ №А-656. Тираж – 1438 данә. Формат 70x108 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 27.03.2020. Чыгу көне: 01.04.2020.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Бу сан «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның 1 нче битендә –
Фәгыйлә Заһидуллина ишегалдында чәй эчү.
Арча районының Гөберчәк авылы. 1950 нче еллар.
Фото М.Мәһдиев музее (җитәкчесе – Халидә Габидуллина) фондыннан алынды.

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Габдулла Тукай

Профессор Карл Фукс искәрткәнчә, татарлар – чисталык яратучы халык, беренче чиратта – рухи чисталыкны. Әлеге ханым-туташларга игътибар белән карагыз әле (XIX гасыр азагы-XX гасыр башы фотосурәте): милләтебез хатын-кызларына хас булган күңел сафлыгы, иман нуры, гыйффәтлелек чагыла аларның йөзләрендә.

Хәсән Сарьян
(24.03.1930-21.09.1978)

* * *

Моң ул – әсәрнең җаны.

* * *

Әдәби осталыкка башка телдән өйрәнеп булса да, үз телеңә фәкать үз телеңнән генә өйрәнеп була.

* * *

Чын шигырь ул – чын талантлан тыш, иң әүвәл, яшьлек, – картайгач та сүнмәс яшьлек.

* * *

Һәрнәрсәдә, гыйбрәттән әүвәл, үрнәк булырга тиеш: начардан гыйбрәт алганчы, яхшыдан үрнәк алу яхшы түгелмени!

* * *

Тормыш материалы ул – язучыдан башка да яши торган чынбарлык. Тормыш материалы хикәянең эчтәлеге булып әверелгәнче, ул язучының күңел күзеннән үтәргә тиеш.

* * *

Чын әдәби әсәр, фоторәсем шикелле, чынбарлыкның төгәл күчермәсе түгел.

* * *

Күргән бер нәрсәне энәсеннән җебенә чаклы төгәл, дөрес итеп язып чыгудан гына эчтәлек барлыкка килми.

* * *

Язучы ни генә язмасын – ярларына сыймый аккан бер дәрьямы йә бер ком бөртегеме – ул аны кешегә битараф итеп язмый, аның рухи халәтенә тәэсир итәрлек итеп яза. Чөнки табигатьтәге гүя безгә битараф итеп яратылган матурлыкны да кешегә мөнәсәбәтсез аңлап булмый.

* * *

Әдәби әсәрнең эстетик тәэсире никадәр куәтле булса, аның кыйммәте дә шулкадәр өстен була.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

Мифология һәм дин

Борынгы халыкның дөньяны ничек күзаллавын ачыклау өчен, гадәттә, аның мифларына һәм диненә мөрәҗәгать итәләр, аларны җентекләп өйрәнәләр. Шул нигездә аның нинди халык булуын һәм нинди халыкларга якын торуын ачыклау мөмкинлеге туа. Этрусклар дәүләте барлыкка килгән Италиядә алар күршесендә яшәгән халыклардан умбрлар, кельтлар, лигурлар, латиннар, сабалар, самнитлар, пиценнар, фалисклар һәм башкаларның дини-мифологик карашлары шактый аерылып торган һәм бу хәл этрускларның бирегә читтән килеп төпләнүе хакында сөйли кебек.

Ул дәвердә яшәгән һәм иҗат иткән авторларның кайберләре этрускларның гаять дини халык булуы турында язып калдырган. Римның башлангыч тарихын язган Тит Ливий да этрускларның үз аллаларына зур хөрмәт күрсәтүләре, аларга бик нык табынулары хакында яза. Этрускларда изге саналган китаплар, дини һәм тарихи әдәбият та булган. Мәшһүр этрусколог А.И.Немировский язганча, атаклы Рим авторы һәм философы Цицерон этрускларның гаруспиция, ягъни күрәзәлек итү турындагы китаплары булуын телгә алган. Рим философы һәм трагигы Сенека этрусклардан Цецина исемле авторның яшен яшьнәвен шәрехләгән тәгълиматы белән таныш булуын язып калдырган. Шулай да ул этруск исемнәрен йөрткән латин авторлары – Арунтийны, Турраний Грацилны, Тарквитий Прискны, Фабриций Тускны да телгә алган (Нем., 165). Ә Рим императоры Клавдий этрусклар белән шулкадәр нык кызыксынган ки, хәтта аларның тарихы турында 20 томлык хезмәт тә язган. Кызганыч ки, бу хезмәт безнең көннәргә килеп җитмәгән. Аның юкка чыгуы очраклы хәл түгелдер. Тарихта андый кыйммәтле чыганакларның кинәт «юкка чыгуын» махсус оештыручы көчләр булуын да онытмыйк.

Этрускларның изге саналган китапларындагы тәгълиматны аларның атаклы дин башлыгы һәм җәмгыятьне үзгәртеп коручы Таг атлы пәйгамбәре һәм Вегоя атлы күренекле хатын-кыз күрәзәче иҗат иткән. Кайбер китапларны латин авторлары үз телләренә тәрҗемә дә кылганнар. Гомумән, этрускларның дине римлылар тарафыннан зур абруйга ия тәгълимат буларак кабул ителгән. Бик күп римлылар үз балаларын Этруриягә дин сабагы алырга җибәргәннәр. Этрускларның күрше кавемнәрнекеннән югарырак торган мәдәнияте, заманына күрә билгеле бер камиллеккә ирешкән дини тәгълиматы ут күршеләренә үрнәк булып хезмәт иткән, этрускларның абруе аларда бу халык ирешкән һәм рухи, һәм матди казанышларны үзләштерү теләге уяткан.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында.

*Фәнни-популяр тарихи бәян.

Таг һәм Вегоя

Этрускларның дини тәгълиматы ничек барлыкка килгән соң? Риваять аларның рухи лидеры Тагның лукумоннар (шәһәр-дәүләт башлыклары, патшалар) җыенында бу тәгълиматны шигъри юлларга салып бәян итүе хакында сөйли. Этрусклар җәмгыяте шушы тәгълиматка нигезләнеп төзелә. Дини карашлары, күктәге күренешләрне күзәтү һәм нәтиҗә чыгару, йолалар үткәрү тәртибе, шәһәрләргә, гыйбадәтханәләргә нигез салу, җирләрне бүлү, таш баганалар утыртылган ызаннарның үзгәртелмәс дәрәҗәдә изге саналуы – барысы да этрусклар җәмгыятенә нигез салган пәйгамбәрләре Таг тарафыннан кертелә. Аның тәгълиматы Изге Китапларда теркәлә, этрускларның төп яшәү кануныңа әверелә. Дин әһелләре, гаруспиклар эшчәнлекләрен Таг тарафыннан бәян ителгән тәгълиматка таянып алып барганнар. Әлбәттә, этрускларда изге саналган китаплар берәү генә булмаган һәм аларның кайберсе шигъри тел белән язылган.

Тагның дини тәгълиматын тукымадан ясалган китап рәвешендә Тарквини (Таркна) шәһәренә нигез салучы Таркон язып чыккан. Шул ук шәхес Этруриядә 12 шәһәр-дәүләт төзүне дә оештырган. Кайбер авторлар Тарконны безгә билгеле Тирренның улы яисә туганы булган дигән карашта торалар. Тарконны Мантуя, Пиза, Кортона шәһәрләренә нигез салган Телеф (татарча Талип буладыр инде ул) улы булган дип санаучылар да бар икән (Нем., 214). Таг этрускларга аларны киләчәктә нәрсә көткәнен дә әйтеп калдырган. Борынгы Грециянең төньягындагы Фессалия патшалыгында әүвәл этрусклар белән тугандаш пеласк дигән кавем яшәгән. Бу илдә дәүләт башлыгының титулы «таг» булган дигән мәгълүмат та бар. Фессалиядә хакимлек иткән бер патшаның исеме Абас (Аббас, Габбас) булган. Ул Фессалиянең башкаласы Ларисса шәһәренә нигез салган (Нем., 86). Кыскасы, бу исемнең мәгънәсе әлегә ачылмыйча кала. Дөрес, төркиләрдә «таг-даг» – «тау» дигәнне аңлата. Бәлки, этрускларда бу исем «бөек» мәгънәсендә йөргәндер.

Этрускларның Вегоя (этрускча Вецуе) атлы атаклы күрәзәчеләре дә булган. Мифологиядә ул нимфа, ягъни аллалар юлдашы рәвешендә телгә алына. Вегоя этрускларда киң таралган яшен яшьнәүне һәм аның төрле мәгънәләрен аңлатып бирүче зат саналган. Шул тәгълиматка таянып, этрускларның дин әһелләре, гаруспиклары яшен яшьнәү, яшен сугуның асылын аңлату белән шөгыльләнгәннәр. Соңрак чорда хәтта Рим сенаты да, берәр әһәмиятле карар кабул итәр алдыннан, яшен яшьнәүне шәрехләүче, сарык бавырын җентекләп тикшереп күрәзәлек кылучы этруск гаруспикларына мөрәҗәгать иткән. Алар сүзенә таянып, карар чыгарганнар. Вегояның Этрурия язмышына караган бер күрәзәсе тарихта теркәлеп калган. Ул: *«Этрурия тарихында шундый заман килер, кешеләр аллалар тарафыннан билгеләнгән, изге ызаннарга утыртылган таш баганаларны күчерерләр, илдә тәртип бетәр, бу хәл этрусклар тарихының сигезенче гасырында булыр»*, – дип әйтеп калдырган.

Чыннан да, Италиягә б.э.к. IX-VIII гасырда килеп төпләнгән халык б.э.к. I гасырда инде тулысынча Рим дәүләте кул астында кала, мөстәкыйльлеген, телен, мәдәниятен югалта, дөресрәге, аларның барлык казанышларын Рим үзләштереп бетерә һәм этрусклар шушы дәүләт гражданнарына әвереләләр. Атаклы күрәзәче Вегояның сүзләре дөрес булып чыга.

Этрускларның космогоник карашлары

Этрускларның дөньяның барлыкка килүен күзаллавы, ягъни космогоник карашлары нинди булган соң? Галимнәргә бу мәсьәләне ачыкларга Рим авторлары үз китапларында телгә алган «этрусклар тәгълиматы»ның эчтәлеге һәм сакланып калган бер кыйммәтле чыганак ярдәм иткән. Ул чыганак «Суда» дип аталган. «Суда» сүзенең мәгънәсе билгеле түгел. Ул бу халыкның космогоник карашларын

һәм «этруск дисциплинасы»ның кайбер өлешләрен туплаган җыентык булгандыр, күрәсең. Һәрхәлдә, бу сүзнең мәгънәсен этрусклар турында язылган фәнни китаплардан ачыклап булмады.

Без этрускларның космогоник карашларын бәян иткән шактый төзек бер текстка мөрәҗәгать итик. Анда болай диелгән: *«Тирреннар – алар тусклар дип атала иде. Аларның тарихын бер галим теркәп калдырган. Аның сөйләвенчә, бөтен нәрсәне бар кылган Илаһ дөньядагы яратылмыш нәрсәләрне унике мең ел буе иҗат иткән һәм аларны йортлар дип аталган унике тарафка урнаштырган. Беренче меңьеллыкта ул Күкне һәм Җирне яралткан. Икенчесендә – күзгә күренә торган Күк гөмбәзен яралткан, аны күк йөзе дип атаган; өченчесендә – диңгезне һәм җир өстеннән аккан суларны яралткан; дүртенчесендә – яктылык биреп торучы бөек күк җисемнәрен – кояшны, айны һәм йолдызларны яралткан; бишенчесендә – оча һәм шуыша торган тереклек ияләрен, дүрт аяклы хайваннарны, һавада очучы, җирдә йөрүче һәм суда йөзүчеләрне яралткан; алтынчы көндә – адәми затны яралткан. Күрсәтелгәнчә, беренче алты мең ел вакыт адәми затны яралту белән тәгамәлләнгән, калган алты мең ел вакыт кешеләрнең тереклек итүенә китәчәк, шулай унике мең елга сузылган дәверләр тәгамәлләнәчәк»* икән (Нем., 169).

Әйтергә кирәк, бу текстны укыгач, шактый кызыклы галәми картина күз алдына килеп баса. Дөрес, сакланып калган әлеге текстның кайбер өлешләре Библия белән тәңгәл килә, әмма аермалары да зур. Библиядә Илаһ дөньяны алты «көндә» бар кылса, «Суда» текстында дөнья алты «меңьеллыкта» яралтыла. «Меңьеллык» реаль тормышка якынрак тора һәм ышандыру көче дә арта төшә. Анда кешелек дөньясының яшәү дәвере адәми зат яралтылганнан соң алты мең ел дәвам итәчәк дип белдерелә. Без этрускларның космогоник күзаллауларын чагылдырган «Суда» тексты Библиядән алып үзгәртелгән дип һич әйтә алмыйбыз, чөнки этрускларның яһүд дине вәкилләре белән элемтәләрен раслаган бернинди тарихи фактлар юк. Мондый космогоник күзаллауларны этрусклар Кече Азиядә, Урта диңгезнең көнчыгышында яшәгән дәвердә үк үзләштергән булганнардыр, күрәсең.

Без алдагы бүлекләрнең берсендә этрускларда унике саны изге сан саналуын һәм аларның күкне дә унике өлешкә бүленгән дип күзаллавын, шул сәбәпле, аларның унике шәһәр-дәүләттән торган Этрурия шәһәр-дәүләтләре конфедерациясе төзүләре хакында әйтеп үткән идек. Аларның космогоник карашлары да, дөнья яралтылудан башлап, кешелек дөньясының тереклек итү дәвере унике меңьеллык циклга бәйле булуы да бик табигый кабул ителә. Чыннан да, этрускларда унике саны изге сан дип каралган, ахры.

А.И.Немировский: *«Кайбер галимнәр, этрусклар космогониясенә Көнчыгыш чыганакларның йогынтысын кире кагып, географик яктан якынрак торган Борынгы Греция белән бәйле параллельләргә күрсәтәләр. Алар тарафыннан китерелгән Гесиод «Теогония»се өзекләре дә, Аполлоний Родослы әсәре дә, безнеңчә, этруск текстыннан бик нык аерылып тора. Әмма андый якынлык гаять зур булган очракта да, бу хәл этрускларның космогоник идеясе грек чыганакларына бәйле икәнне раслый алмас иде. Чөнки грекларда космогоник карашларның Якын Көнчыгыш регионнары йогынтысында барлыкка килүе бүгенге көндә бернинди шик уятмый»*, – ди (Нем., 170).

Этруск аллалары

Хәзерге заманда дин тоту адәм баласының шәхси эше булып тора, хәтта нинди динне тоту да аның үз ихтыярында. Ә борынгы заманда алай булмаган. Ул чорларда дин тормышның барлык өлкәләрен үз колачына алган, иҗтимагый тормыш белән дәүләт эшчәнлеге дә дин белән тыгыз бәйләнештә торган.

Борынгы заман авторлары этрускларны дингә бик нык бирелгән халык буларак тасвирлыйлар. Мәсәлән, Диодор Сицилияле этрусклар турында: *«Аллалар турындагы фәнне алар көнләшерлек ихласлык белән өйрәнәләр»*, – дип яза. Ә Рим тарихчысы Тит Ливий этрускларны: *«Бу халык, башка халыклар белән чагыштырганда, зуррак хирыслык күрсәтеп, дини йолалар үткәрә һәм әлеге эшне зур осталык белән башкара»,* – дигән. Шунысын да әйтергә кирәк: ул заманда яшәгән Италия халыклары арасында бары этрусклар дине генә изге саналган китапларда теркәлү дәрәҗәсенә ирешә. Китаби дин буларак, «Этруск тәгълиматы» ул китапларда тулы чагылыш таба. Дин бу халыкка бик күп аңлашылмаган нәрсәләрне аңларга һәм практик яктан хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Аллалар ихтыярын аңларга тырышкан, чарасыз калганда аларга сыгынган, мәгълүм йолалар үткәреп һәм корбаннар чалып, ярдәм сораган һәм яклауга өметләнгән адәм баласына фәкать дин генә ярдәм иткән. Дин шулай ук үлем белән төгәлләнәчәк рәхимсез вакыт каршында үзеңнең көчсезлегеңне җиңәргә, яшәү өчен өмет һәм күңел тынычлыгы табарга, үлгәннән соң да яшәү бар дигән ышану иңдереп, адәм баласына һәрдаим ярдәм иткән. Чыннан да, этрусклар үлгәннән соң да кеше яшәвен дәвам итә дип ышанып яшәгәннәр. Аларның «тумули» дип аталган курган кебек төрбәләре эченә, кешегә тормышта ни кирәк булса, шул нәрсәләр куела торган булган.

Әлбәттә, этрусклар ышануынча, адәми затның тормышы, шәһәрләр, шулай ук илдәүләт язмышы аллалар ихтыярында булган. Аллалар бәхет тә, кайгы-хәсрәт тә китерә алганнар.

«Грек мифологиясен чагылдырган күренешләр төшерелгән этруск көзгеләрендә аллалар сурәте бик сирәк очрый, ә грек мифологиясендәге исемнәрнең очравы берничек тә Этруриядә чит ил аллалары культы яшәгән дигәнне аңлатмый», – дип яза француз этрускологы Ж.-Н.Робер (178 б.). Димәк, этрусклар, нигездә, үз аллаларына табынып яшәгәннәр.

Тин этрускларның аллалар пантеонында иң бөек урынны алып тора. Ул күк хуҗасы, яшен яшьнәтүче һәм яшен атучы алла санала. Аның кулында өч бәйләм яшен уклары булып, беренчесен ул кешеләрне кисәтү өчен кулланган, икенчесен башка 12 алла белән киңәшкәннән соң гына аткан, өченче – иң хәтәр, үтергеч яшенне, берничә олуг аллаларның ризалыгын алгач кына, гөнаһлы адәмгә юнәлткән. Этрускларда патшалар Тинның җирдәге вәкиле саналганнар.

Триумф (тантана) вакытында этруск патшалары тәннәренең ачык калган өлешләрен, дини йолалар таләп иткәнчә, Тинның скульптурасын буяган кебек буяганнар. Бу гадәт бер үк вакытта патшаның Тинны символик рәвештә гәүдәләндерүен күрсәтү өчен башкарылган. Этрусклар Тинны күк гөмбәзенең төньягында яшәүче алла дип күзаллаганнар. Тинга багышланган гыйбадәтханәләр биек калкулыклар өстенә төзелгән. Көннең якты вакыты Тинга багышланган. Римдагы Капитолий храмы культында Тин, Уни, Менрва – өч этруск алласыннан торган триада да урын алган. Күрәсең, бу культ Римда этруск патшалары хакимлек иткән

Арреций шәһәрендә табылган бронза көзге (б.э.к. 350-325 еллар). Уртада уң кулына скипетр тоткан Танр (Тәңре) утыра

дәвердә гамәлдә булгандыр. Соңрак, этруск патшаларыннан арынгач, римлылар Капитолий храмына үз аллалары – Юпитер, Юнона һәм Минерва сыннарын урнаштыралар.

«Шунысы кызык: Тин шулай ук Вольтумна исеме белән дә олыланган», – дип яза Ж.-Н.Робер. – Рим авторларыннан Варрон үзенең «Латин теле» исемле хезмәтендә аның Этруриядә төп алла булуын әйтеп уза, һәм римлылар аның исемен Вертумнис дип үзгәртәләр <...> Безгә бу алланың төп алтаре Вольсини шәһәрендә төзелүе һәм анда ел саен Этруриянең унике шәһәре вәкилләре җыелуы, аларның анда үз федерацияләренең (автор Этрурия шәһәрләре федерациясе дип яза. Ләкин бер үзәккә буйсынып яшәмәгән шәһәр-дәүләтләр конфедерацияне тәшкил иткән. – С.Ш.) данын-шөһрәтен күтәрә торган уеннар, дини йола мәрасимнәре үткәрүләре дә билгеле. Шулай алар этрускларның бербөтен халыкны тәшкил итүен раслый торган булганнар» (Ж.-Н.Робер, 178, 180). Әмма Вольтумнаның этрускларда төп алла булуын инкяр итүчеләр дә бар.

Тинны барлык авторлар этрускларның баш алласы дип язсалар да, бу халык **Тәңрене** дә белгән икән. Этруриянең Арреций каласында табылган бер бронза көзгедә (б.э.к. 350-325 елларга карый) кәнәфидә уң кулына скипетр тотып утырган Тәңре сурәте төшерелгән. Аны арттан Тална (Талинә) исемле хатын-кыз кочаклап тора, ә икенче Тина (Тиния) исемле хатын-кыз Тәңренең башына кулларын сузган. Сетлан исемле егет, кулына озын саплы матур балта тоткан килеш, кырыйдарак басып тора. Көзгедәге бу затларның этрускча язылган исемнәре җиңел укыла. Бу сурәт греклар мифологиясендәге бер сюжетны хәтерләтә. Эш шунда ки, греклар мифологиясендә Афина исемле алиһә баш алла Зевс башыннан коралланган хатын-кыз рәвешендә килеп чыга. Этруск көзгесендә дә Тәңре башыннан бер кулына – сөңге, икенчесенә калкан тоткан, матур шлем кигән кечкенә генә хатын-кызның килеп чыгуы сурәтләнгән. Күрәсең, бу көзгегә сурәт төшергәндә этруск рәссамы греклар мифологиясе сюжетына таянып иҗат иткәндер. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: этрусклар Тәңрене, үзләренчә, **Танр** дип атаганнар. Көзгедә аның исеме шулай язылган. Бу инде этруск теленә хас бер үзенчәлек кенә. Этрускларның **Танр** алласы гадәти төрки телдә **Тәңрегә** әйләнүе бик табигый хәл бит.

Уни – этруск аллалары пантеонында, Тиннан кала, икенче урынны алып тора. Этрусклар мифологиясендә ул – патша хакимиятен саклау вазыйфаларын үтәүче алиһә. Уни бер үк вакытта хатын-кызларны яклаучы буларак та билгеле. Шулай ук, Вея шәһәрен саклаучы алиһә буларак, анда олыланган, хөрмәт ителгән. Рим гаскәрләре Вея шәһәрен басып алып җимергәннән соң, алар үзенчәлекле бер «алла чакыру» мәрасиме үткәрәләр һәм Уни алиһәнең статуясын үзләренә алып китәләр. Археологлар тарафыннан табылган таблицада Уни тәхеттә утырган килеш сурәтләнгән. Ә башка аллалар, хәтта Тин да, астарак торган кәнәфиләргә урнашканнар. Шунысы кызык: Уни, элекке татар хатын-кызлары гадәте буенча, киеменең якасы белән йөзен каплабрак утырган килеш ясалган.

Бу алиһә, этрускларның аллалар пантеонында дәрәҗәле урын алганчы, бик зур эволюция юлы узган. Ул Урта диңгез буендагы күп халыкларга билгеле булган. *«Төрле дәвердә ул төрле исемнәр йөрткән. Бу хәл Урта диңгез буе илләрендә барган этник процесслар турында сөйли. Мәсәлән, этрусклар белән тугандаш пеласкларда ул – Эйлифия, грекларда – Левкофея, этрускларда – Уни, римлыларда – Юнона исемнәрендә зурланган»* (Нем., 194). Вольтерра шәһәрендә табылган этруск көзгесендә: «Уни улы Херкле» дигән язу булган. Бу очракта Херкле – Геракл дигәнне аңлата. Бу хәл Унинының Борынгы дөньяда атаклы, зур абруйга ия алиһә булуы турында сөйли.

«Этрускларда иң борынгы сыннар Эгей диңгезе-Анатолия традицияләре үрнәгендә агачтан һәм балчыктан ясалганнар. Этрускларның Популония шәһәре гыйбадәтханәсендә Тинның агачтан ясалган борынгы сыны булган. Вея шәһәрендәге гыйбадәтханәдә Уни алиһәнең сынын да шулай ук агачтан ясаганнар <...> Мон-

Уни алиһә

дый ысул белән сыннар иҗат итү грекларда кабул ителгән үрнәкләрдән ерак тора. Бу очракта аллалар сыны билгә кадәр ялангач итеп эшләнгән һәм аларның кыяфәтләре Крит утравындагы Алиһә-Ана сыннарына бик якын тора» икән (Нем., 219).

Менрва – этрусклар аллалары пантеоны триадасын тәшкил иткән өченче зур алиһә. Этрусклар мифологиясендә ул – аналарны кайгыртучы алиһә, бала тудыручы хатын-кызларны саклаучы. Аны галимнәр Эгей диңгезе бассейны – Анатолия төбәкләрендә бик борынгыдан билгеле алиһә булган дип саныйлар. Соңрак ул һөнәрчеләрне һәм балыкчыларны яклаучы булып киткән. Аны шулай ук Этрурия шәһәрләрен саклаучы алиһә дип тә кабул иткәннәр. Мәсәлән, Вея шәһәрендә аның сыннарын, сугыш киемнәре кигән килеш, кулына сөңге тоттырып ясаганнар. Менрва шулай ук төрки халык сабаларда да хөрмәт ителгән. Рим авторы Теренций Варрон аны саба халкы алиһәсе дип санаган. Латиннар аны үзләренең борынгы алиһәләре дип кабул итмәгәннәр. Цере шәһәре порты Пиргидагы храмда Менрва аллалар белән пәһлеваннар сугышында катнашучы сыйфатында сурәтләнгән. Ул шулай ук этрускларның бронза көзгеләрендә Тин, Туран, Аплу, Сефланс, Марис һәм Херкле белән бергә сурәтләнгән (Нем., 194). Аны соңрак, Минерва исеме белән, римлылар да олылый башлаганнар. Римдагы Авентин калкулыгындагы храм шагыйрьләр һәм актерлар җыела торган урын булган. Минерва укытучыларны, табибларны һәм трубада уйнаучы музыкантларны гына түгел, гомумән, һөнәр ияләрен яклаучы саналган.

«Галимнәр этрускларның Менрвасы грекларның Афинасына якын торуына да игътибар иткәннәр. Моның сәбәбен ике алиһәнең дә Эгей диңгезе бассейны – Анатолия төбәкләрендә киң таралыш алган Алиһә-Ана образына бәйләп аңлаталар» (Нем., 196).

Шулай итеп, без этруск аллалары пантеонындагы триадага кергән иң дәрәҗәле аллаларның – Тин, Уни һәм Менрваның нинди вазыйфалар башкаруын барлап чыктык. Аларның өчесенең дә башка халыклардан кабул ителгән аллалар түгел, фәкать этрусклар мифологиясендә барлыкка килгән аллалар гына булуы бернинди шик уятмый. Этрусклар үзләренә хас мифологик күзаллаулар һәм аллалар пантеонында кодрәтле аллалар триадасы булдырган сәләтле халык икән. Гомумән, Менрва Италия җирлегендә барлыкка килгән алиһә түгел икән, гәрчә аны Минерва исеме белән соңрак римлылар олылый башласа да.

Ахыры киләсе санда ■

Мәмәтевләр нәселе – *Бәрәңге төбәгенең горурлыгы*

Фәнил Мусин-Мәмәтев

Мәмәтевләр нәселеннән безнең төбәккә иң беренче күчеп төпләнгән кеше – йомышлы татар Бикмәт (Бикмөхәммәд) Мәмәшев (Мәмәтев). Ул, 1719 елгы халык санын алу мәгълүматына караганда, Морзабаш – бүгенге Бәрәңге районындагы Мазарбашы авылының югары өлешендә яшәгән һәм 1740 елда вафат булган. Бу шәхеснең хәзерге Татарстан Республикасындагы Олы Солабаш авылыннан күчеп килгәнен дә ачыклый алдык. 1716 елгы җан исәбен алу документында Бикмәт һәм аның хатыны Бибисолтан Үзибәкованың нәкъ менә әлеге авылда яшәве әйтелә.

Хәзерге вакытта Мәскәүдә яшәүче якташыбыз Рафаиз Нурмөхәммәтулы Гайнанов сүзләренә караганда, Бикмәт Мәмәшев – Касыйм ханлыгы морзалары Мәкъсутовлар нәселеннән. Әлеге мәгълүмат Мәмәшев һәм Мәкъсутовлар нәселеннән булган ир-атларны генетик тикшерүләр белән дә раслана. Бу кешеләрнең Касыйм төбәгенә, Казан яулап алынганнан соң, ханлык җирләреннән күченгәнлегенә дәлилләр дә бар. Ә Казан ягына алар, мөгаен, Олуг Мөхәммәд белән бергә килгәннәрдер. Тарихи документларда Мәкъсутовларның тагы да борынгырак – сәлҗүк солтаннары белән туганлык мөнәсәбәтендә булган, соңрак язмыш җилләре Алтын Урда һәм Кырым җирләренә китереп чыгарган бабалары турында да мәгълүмат бар.

1710 һәм 1716 елгы җанисәп мәгълүматларына караганда, йомышлы татар Бикмәт Мәмәшев – Касыйм өязендәге Курски авылында яшәүче Мәмәш морза Котлымәмбәт Чынбаевның уртанчы улы. Р.Н.Гайнанов әйтүенчә, ул 1703-1705 елларда Казан төбәгенә адмиралтейство эшләре буенча җибәрелә һәм Солабаш авылында



Купай авылы турында язылган иң әүвәлге чыганак. 1762 ел

Безнең мирас №4 апрель 2020

төпләнеп кала, күрше Урта Алат авылы кызы Бибисолтан Үзибәкова белән гаилә кора. 1710, 1716 һәм 1719 еллардагы халык санын алу мәгълүматларына караганда, йомышлы татар Үзибәковлар гаиләсе Урта Алатта яшәгән. Алар да, Мәмәтевләр кебек үк, бу вакытта инде рус дәүләте составына кергән Касыйм ханлыгы җирләреннән күчеп килгәннәр. Мөгаен, бу нәсел кешеләре дә, йомышлы татар буларак, Казанда һәм Алат даругасында юлларны күзәтү яки башка эш белән шөгыльләнгәннәрдер.

Солабаш авылы тарихы Казан ханлыгындагы Алат даругасының йомышлы татарлары белән бәйле. Биредә яшәүче халык нугайлар нәселеннән дип санала. Алат кенәзлегендә ханлыкның көчле хәрби берләшмәләре булып, кагыйдә буларак, алар ханны һәм аның яраннарын саклаган. Бу кенәзлек Казан шәһәре яулап алынганнан соң дистә ел вакыт узгач, 1562 елда гына рус дәүләтенә буйсынган. Әмма әлеге хәрбиләрнең һәм бу вакыйгаларның Мәмәтевләр нәселенә бернинди дә бәйләнеше юк.

1718 елда Казан адмиралтействосы барлыкка килү белән, йомышлы татарлар да кораб төзү өчен агач кисү һәм ташу эшенә – лашманчылыкка язылган. Нәкъ менә шул елда йомышлы татар Бикмәт Мәмәшев безнең төбәккә җибәрелә һәм Морзабаш авылына нигез сала. Шулай ук, йомышлы татар Дусмәмәт Полатов (1671-1726) та бирегә килеп төпләнә. Әмма аның нәсел-нәсәбе турында мәгълүмат әлегә табылмады.

Бикмәт Мәмәшевнең ике улы – Рәхманкол (1707) һәм Мәкъсут (1716) булган. 1745 елгы халык санын алу мәгълүматына караганда, икесе дә Морзабаш авылында хатыннары һәм балалары белән яшәгән. Шулай ук, алар уллары белән Казан каласының, Алат, Галич, Арча, Җөри, Нугай даругаларының 1745 елгы теркәү кенәгәләрендә кораб төзелеше эшенә мөнәсәбәтле теркәлгән. 1762 елгы өченче «Ревизские сказки» биргән мәгълүмат буенча, Рәхманкол Бикмәтев-Мәмәтев һәм аның гаиләсе Портянур пүчинкәсендә (хәзерге Купай), ә Мәкъсут Бикмәтев-Мәмәтев Морзабашта яшәгән. Шуны да искәртик: бу елларда әлеге авылда фәкать йомышлы татарлардан торган өч гаилә генә гомер иткән.

Бай һәм мал-мөлкәткә ия гаярь ирләр берничә хатын белән гомер иткән. Рәхманкол да ясаклы татарлар яши торган Тимершәех авылы кызы Мөслимә Ниязова (1729), ясаклылар авылы Ташкичүдән (хәзерге Арча районы) Сәгыйдә Бакирова (1732) һәм тагын исеме безгә мәгълүм булмаган өченче хатын белән тормыш алып барган.


Вѣдомость.

Званiе выделываемыхъ товаровъ	Число становъ	Въ теченiи того года выделано		Продано оптомъ на ярмонкѣ и в городѣ Казани		За тѣмъ въ остаткѣ къ 1821 году
		число кусковъ кумачей	число внутреннихъ аршинъ	число кусковъ кумачей	число внутреннихъ аршинъ	
Кумачей	16.	3225.	25800.	3225.	25800.	—
Итого	16.	3225.	25800.	3225.	25800.	—

Мөхәммәдәмин Монасыйпов-Мәмәтевнең комач фабрикасы турында кенәгәсе. 1820 ел

Мәкъсутның исә ике хатыны булган: Салихә Солтанаева (1727) һәм Ясаклы Оры авылы (хәзерге Арча районы) кызы, данлыклы сәүдәгәр Хуҗасәетовлар нәселенең затлы ханымы Сәгадәтбану Туктамышева (1742).

Рәхманкол Бикмәтевнең 14 баласы туган, шулардан берничәсенең генә язмышы билгеле. 1735 елгы Фазилә Рәхманколова – Арча даругасының Салауш авылындагы йомышлы татарга, 1738 елда дөньяга килгән Сәгыйдә Рәхманколова исә, шул ук даругадагы Түнтәр авылы йомышлы татарына кияүгә чыккан. Рәхманколның олы улы Габдерәшит (1743) Морзабаш авылында яшәгән. Аның кызы Салиха (1764) алда әйтелгән Дусмәмәт Полатовның оныгы Габит Арслановның (1751 елгы) хәләл җефете була. Габит тарихка хәзерге Бәрәңге районының Хәсән авылына нигез салучы буларак кереп калган шәхес. Гобәйдулла Рәхманколов Порт-Мәмәт (Купай) авылында зур гаиләнең башлыгы була. XVIII гасырда нигез салынган авыл исеме дә, шуңа бәйле рәвештә, Мәмәт дип атала. Шуны да искәртик: аның оныгы Сөләйман Каһарманов (1839-1886) күренекле мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең сеңлесе Бибисәйдәгә өйләнә. Гобәйдулланың улы Рөстәм 1812 елгы Ватан сугышында катнаша. 1816 елда ул үзен – рекрут, ә инде 1834 елда чит илдә булып кайткан кеше итеп күрсәтә.

Рәхманкол Бикмәтевнең кече улы Московъ (1764-1839) исеме белән күрсәтелгән. Дөрестән дә, бу исем-фамилия татарлар арасында XVIII гасыр ахырында шактый таралган була. Московъ та Порт-Мәмәт (Купай) авылында янә зур бер гаиләнең башлыгы булып тора. Аның кече улы Мөхәммәтфазыл Московның (1808) гына да 11 баласы дөньяга килә. Аларның күбесе шушы авылда төпләнеп кала. Ә Мөхәммәтфазыл улы Әхмәтнең (1859) өч хатыны, җиде кызы һәм дүрт ир баласы булган.

1782 елда Койло-Портянурга (хәзерге вакытта Портчара авылы эчендә калган элеккеге Поташ пүчинкәсе) нигез салган Мәкъсут Бикмәтевнең дүрт улы һәм җиде кызы дөньяга килгән. Минемчә, аның өлкән улы, башкалар арасында иң танылганы – фабрикалар хуҗасы һәм эре җирбиләүче Монасыйп Мәкъсутовны (1744-1804) аерып күрсәтергә кирәк. Аның гаиләсе дә XVIII гасыр ахыры-20 йөз башында Поташ пүчинкәсендә яшәгән. 1834 елгы сигезенче «Ревизские сказки»да Монасыйпның уллары Мөхәммәтшәрип, Рәхмәтулла һәм Мөхәммәтвәли Мазарбашында яши дип күрсәтелгән. 1850 елда оныклары да шунда яши. Монасыйпның кардәшләре Мәхмүт белән Мөхәммәтрәхим Мәкъсутовлар 1812 елда Порт-Мәмәт (Купай) пүчинкәсендә төпләнеп калган. Мөхәммәтрәхимнең дүрт улы һәм өч кызы була.

Йомышлы татарлар Бикмәт Мәмәшев, аның уллары Рәхманкол белән Мәкъсут һәм аларның балалары белән оныклары туган ягыбызның икътисади һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән. Бигрәк тә Әби патша идарә иткән чордан, ягъни 1760 нчы еллардан башлап, XVIII-XIX гасыр чикләрендә хәзерге Бәрәңге җирендә милли тормыш тагын да җанлана төшә, татар икътисады гөрләп үсә, сәүдә алга китә, кешеләргә эш урыннары булдырыла. 30-50 ел эчендә татар авыллары һәм пүчинкәләрендә яшәүчеләр саны дистәләрчә мәртәбә арта. Яңа татар авыллары барлыкка килә, мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр салына.

1782 елда Мәкъсут Бикмәтев-Мәмәтев, улы Монасыйп Мәкъсутов-Мәмәтев белән, поташ заводына нигез сала. Монасыйп шул ук елда Поташ һәм тагын якындагы берничә пүчинкә-авылларда комач фабрикалары төзетә. XIX гасыр башына Мәмәтевләр поташ заводына, комач һәм кәгазь фабрикаларына, киң мәйданлы җир, урман, елга үзәнлекләренә хуҗа булганнар. XVIII гасыр азагыннан Лаж авылында (хәзерге Киров өлкәсенең Лебяжск районы биләмәсендә) әлеге торак пункт тарихында бердәнбер сәнәгать предприятиесе – Мәмәтевләрнең мамык-кәгазь фабрикасы эшләп килгән. Биредә комач һәм алача җитештерелгән. Төрле буй-буй төсләр белән сугылган киндер алачаны казан арты татарлары – өйләрендә ашъяулык һәм тастымаллар, ә керәшен татарлары үс киемнәре тегү өчен күпләп сатып алган.

Мәмәтевләр нәселенең дәвамчылары – Бәрәңге районында чыга торган «Безнең тормыш» газетасының баш мөхәррире, районның төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе Фәнил Мусин (сулда), Мари АССРның атказанган механизаторы Рәис Салихов Мазарбашы Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы Әхмәт хәзрәт Вәгыйзов белән. 2019 елның гыйнвары

Эрләнгән җеп исә Оренбург аша Урта Азиядән китерелгән. Фабриканың, 25 станоклы туку остаханәсеннән һәм буяу цехыннан тыш, ике киптерү, ике склад һәм тукыма саклау өчен ике амбары булган. Ул сезонлы гына – октябрьдән алып майга чаклы эшләгән. Моның сәбәбе шунда: анда җирле халык арасыннан 40ка якын эшче хезмәт куйган һәм алар, җәйге чорда өйләренә таралып, игенчелек белән дә шөгыльләнгән. Буяу остаханәсе эшчеләре генә башкалардан озаграк эшләгән, чөнки тукыманы кызыл яки башка төсләргә ману, нигездә, көннәр җылыткач, апрель-май айларында гына башкарылган. 1804 елда Монасыйп Мәкъсутов вафат булганнан соң, фабрикалар аның абыйсы Мөхәммәтрәхим Мәкъсутов-Мәмәтев һәм аның уллары Мөхәммәдәмин, Мөхәммәдситдыйк һәм Мөхәммәдшәрип Монасыйпов-Мәмәтевләр милкенә күчкән.

Мәмәтевләр Казан, Вятка, Түбән Новгород, Уфа, Оренбург, Урта Азия фабрикантлары һәм эшкуарлары белән тыгыз икътисади элемтәләр урнаштырганнар, уртак хуҗалык һәм сәүдә эшләре алып барганнар, гаилә корып, туганлашканнар. Алардан туган оныкларның бер өлеше, Казан, Өрҗем, Нократ һәм башка шәһәрләргә күчеп, шунда сәүдә белән шөгыльләнгән.

Татар авылында эшкуарлык үсеше, эшлекле, булдыклы ир-атлар барлыкка килү төбәктәге татар мәдәниятенә дә уңай йогынты ясаган. Хәзерге Мазарбашы авылындагы Җәмигъ мәчет – архитектура һәм ислам мәдәниятенең күркәм ядкәре. Мәчетне хәзерге Арча районы Түбән Оры авылындагы күренекле сәүдәгәр һәм сәнәгатьче Мөэмин Таһир улы Хуҗасәетев төзеткән. 1823-1829 елларда барган төзелеш эшләре белән Мәмәтевләр җитәкчелек иткән. Ни өчен Оры бае нәкъ менә Мазарбашында Җәмигъ мәчете төзергә уйлаган соң? Беренчедән, Мөэмин Хуҗасәетевне Мәмәтевләр белән туганлык һәм эшлекле мөнәсәбәтләр бәйләгән. Алда әйткәнемчә, аның апасы Сәгадәтбану Туктамышева – Мәкъсут Бикмәтев-Мәмәтевнең икенче хатыны, ә Мөэминнең беренче хатыны Бәдигылҗамал Мәкъсутның

Мазарбашы авылы мәчетенең эчке күренеше

кызы була. Икенчедән, бу елларда биредә тирә-яктагы күренекле дин әһелләренең остазы, ишан Халид бине Биккол бине Ибраһим әл-Шаши хезмәт итеп, мәчет карамагындагы зур мәдрәсәне оештырып җибәргән.

Ике катлы Аллаһ йорты Арча районындагы Ташкичү авылында атаклы Мәрҗаниләр имамлык иткән мәчет проекты нигезендә төзелгән. Мәгълүм булганча, бинаның беренче катында – шәкертләр өчен мәдрәсә, ә икенче катында михраб белән ике өлештән торган мәчет залы эшләгән. Мәчетнең агачтан төзелгән манарасына ярымайны рус тимерчеләре ясаган, чөнки бу чорда татарларга, шул исәптән, күрше мариларга да тимерчелек эше белән шөгыльләнү дәүләт тарафыннан тыелган.

Өрҗем өязенең Генераль ызанлау планында Мәмәтевләрнең биләмәләре турында ике язма бар. Шуларның берсендә болай диелгән: *«Портянур һәм Койли пүчинкәләрендә йомышлы татар Мәмәтевләрнең өч ат, тире иләү һәм поташ заводлары, бер комач, өч кәгазь фабрикалары һәм тегермәне бар»*. Икенчесендә: *«Ляж елгасының Ноляга кушылган үзәнлегендәге ике комач фабрикасы йомышлы татар Мәмәтевләр кулында»*, – дип язылган. Бу ике комач фабрикасы Прикум-Фабрика (хәзерге Куян авылы) пүчинкәсендә урнашкан була.

XIX гасыр ахырында инде Мәмәтевләр милкендә фабрика һәм заводлар булмаган. Портчара авылында (Поташ) элегрәк Мөхәмммәтрәхим Мәкъсутов милкендә булган кәгазь фабрикаларының берсе Мәмәтевләрнең туганнан туган энесе Сөләйман Йосыповныкы дип күрсәтелгән.

Бикмәт (Бикмөхәммәд) Мәмәтев нәселе кешеләре дөньяның төрле илләренә таралган. Аларның бер өлеше Мари Эл Республикасының Бәрәңге районындагы Бәрәңге бистәсендә, Купай, Мазарбашы, Куян һәм Портянур авылларында әле дә яши. Бу нәселнең тарихын тирәнтен өйрәнү эше дәвам итә. ■

Гөләйза кыйссасы

Галим Хисамиев

Ишук Уразманов ни өчен ялганлый?

Дәүләт һәм чиркәү каршында «олы гөнаһ» кылган – керәшенлектән язып исламга кайткан, өстәвенә, мөселман егетенә кияүгә чыгып, аннан балалар да тапкан Гөләйза эше буенча сорау алу дәвам итә. Кыр Шонталасы крестьяны, чукындырылган татар Ишук (Ишмөхәммәд) Уразманов: *«Татарча исемем – Ишук, чын исемем – Измаил Ефремов, 73 яшемдә, башкалар белән мөселманлыкка кайтуым сәбәпле, бу турыда аерым «җинаять эше» алып барыла. Мөселманлыкка кайту сәбәпле, язык әйтүдә һәм өлеш алуда булганым юк. Мәхкәмә утырышчысы Смурановка карата дорфалык күрсәткән өчен хөкем астында торам, имеш. 8 нче ревизиядә Кыр Шонталасы авылының чукындырылган татары дип теркәлгәнмен. Авылдашым Фекла Тимофееваның никахсыз тапкан һәм чукындырганда Иван, ә үрсәти исеме буенча Денисов дип аталган баласын, аның соравы буенча, үземә уллыкка алдым, 8 нче ревизиядә аны гаиләм әгъзасы итеп яздырдым. Аның өчен барлык салымнарны үзем түлим. Уллыкка алган Иван да минем белән мөселманлыкка кайтты. Аны өч ел элек чукындырылган татар (исемен белмим) кызы Миңҗамалга (русча исемен белмим) өйләндердем»*, – дип җавап бирә. Аның урынына Юшков хуҗалыгынннан крестьян Николай Адамов имза куйган.



1838 елгы чиркәү документында Измаил Ефремовка – 66, аның хатыны Анастасия Афанасьевага – 69, кызы Мариягә – 21, улы Николайга – 26, аның хатыны Анисья Алексеевага – 26, балалары Фирска – 6, Никитага – 2 яшь. Аларда хезмәтче булып 49 яшьлек Фекла Тимофеева яши. Аның законсыз туган балалары Пелагея (29 яшь), Федосья (12 яшь), Иван (11 яшь) һәм Марья (3 яшь) дип язылган.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2020) санында.

Чыннан да, 1839 елда Кыр һәм Чирүле Шонталалары, Байтирәк авылларындагы чукындырылган татарларның мөселманлыкка кайтуы сәбәпле, аларга карата җинаять эше ачыла. Атакай М.Лавров 1843 елның 27 мартында архиепископ Владимирга юллаган рапортында «главными начинателями и возмутителями душ», дип, нәкъ Измаил Ефремовны һәм аның улы Федор Измайловны күрсәтә. Күргәнебезчә, отставкадагы солдат Ишук Уразманов «мәхкәмә утырышчысы Смурановка дорфалык күрсәткән өчен» түгел, ә «котыртучы, фетнә чыгаручы» һәм мөселманлыкка кайтучы татарларның әйдаманы булганы өчен хөкемгә тартыла.

Гөләйза кем кызы?

Утырышта катнашучыларның башын аңлы рәвештә бутау дәвам итә. Әлбәттә, Ишмөхәммәд белән Фекла Тимофеева арасындагы мөнәсәбәт гади генә булмаган. Гөләйза һәм башка балалар шушы Ишук-Ишмөхәммәдтән туган булырга бик мөмкин! Закон каршында Фекла Измаилның хатыны дип түгел, ә аның хезмәтчесе итеп күрсәтелә. Юкка гына Ишук Уразманов, Иванны уллыкка алдым дигән булып, ревизия вакытында аны үз гаиләсендә Бикмөхәммәд Ишмөхәммәд улы (Ишуков) дип яздырмагандыр. Шул рәвешле, законны урап, җәза алмыйча, үз баласын рәсмиләштергән дип уйларга мөмкин. Моңа чукындырылган татарларның хәлен, татар телен яхшы белгән Актау авылы атакае (бәлки, татар керәшенедер) Яков Алякринскийның рапортында Гөләйзаны Измаил кызы дип күрсәтүе дә ишарәли.

Мөселман һәм чукындырылган татарлар бергә яшәгән авылларда «законсыз никахлар» – ирләрнең берничә хатын белән гомер кичерүе еш күзәтелгән. Әлбәттә, икенче никах чиркәүдә теркәлмәгән, мулла яшерен генә аларга никах укыган очракта бу хакта метрика кенәгәсенә язмаган. Мәсәлән, Кыр Шонталасы авылы метрика кенәгәләрендә элек чукындырылган һәм мөселманлыкка кайтканнар турындагы мәгълүмат 1905 елда «Дин иреге турында» фәрман игълан ителгәнче теркәлмәгән. Еш кына аларга никахны үзләре кебек мөселманлыкка кайткан, ислам йолаларын белгән «мулла» укыган. Моңа мисал итеп, Кыр Шонталасы авылыннан чукындырылган татар Имаметдин Ишмурзинның («Шәкерт бабай») 1907 елда Диния нәзарәтенә барып имтихан бирүен, мөәзин, мөгаллим-сабиан, имам вазыйфаларын башкарырга сәләтле булуы турында таныклык алуын һәм, Казан губерна идарәсе указы буенча, Урманасты Шонталасына указлы мөәзин итеп билгеләнүен әйтергә мөмкин. Ул 1940 нчы елларда Донбасска күчеп киткәнче, әлеге вазыйфаны башкара, совет чорында да яшерен рәвештә авылдашларын хак исламга өнди.

Кызылъяр атакае: «Мулла этәргән булуы ихтимал!»

Кызылъяр атакае Алексей Мефодьев та мөселманлыкка кайткан «керәшеннәр»нең эшен тикшерүдә катнашучы депутатлар, стан приставы вазыйфаларын башкаручы Шахт алдында аңлатма биргән. Ул: *«Минем приходка караган Кыр Шонталасы авылы кешесе – православиедән мөселманлыкка кайткан Фекла Тимофеева үзенең законсыз тапкан кызы Гөләйзаны Чирүле Шонталасы татар мөселманы Хәким Камаевка кияүгә бирү турында бервакытта да миннән рөхсәт сорамады һәм мин мөселманча никах укытуга рөхсәт бирмәдем. Чөнки ул үзе дә, аның кызы Гөләйза да, православие динендә туып, шул диндә булдылар, христиан динен бөтен төгәллекләре белән үтәделәр, ә аннары әкренләп мөселманлыкка авыштылар. Соңгысы, балигъ булгач, анасы кебек, татар мөселманы белән кушылып, өч бала тапты. Соңрак Фекла да, Гөләйза да, башка чукындырылган татарлар белән бергәләп, православие диненнән ваз кичте. Аларны мондый адымга яңа туган сабыйларга татар исемнәре кушкан Чирүле Шонталасы мулласы этәргән булуы ихтимал. Фекла Тимофеева: «Гөләйза чукындырылмаган, миңа кадәрге рухани Трифон Андреев, янәсе, аның чыгышын белмәү сәбәпле, үтенечен үтәмәгән», – дип әйтсә дә, бу*

сүзләр чеп-чи ялган. Чөнки 55 яшьлек Фекла да, аның никахсыз балалары – 24 яшьлек Пелагея, 18 яшьлек Федосья, 14 яшьлек Марья һәм Измаил Ефремовка тәрбиягә бирелгән 17 яшьлек Иван Денисов та чиркәү документларында теркәлгәннәр. Рухани Андреевның Фекла Тимофеева балаларын чукындырырга алып килгәч кенә үзенең төп вазыйфасыннан баш тартуы бик шикле», – дип, судан коры чыгарга омтыла.

> **Атакайлар да татар телен белмәгәннәр, белергә теләмәгәннәр, җаена карап, баю юлын сайлаганнар. Чукындырылган татарлардан акча таләп итүләре, эчкечелек белән шөгыльләнү фактлары архив документлары белән дә раслана.**

Дин юлында хезмәт итүче атакай Алексей Мефодьев хакында архив документлары ни сөйли соң? Ул 1789 елда туган. Казан семинариясенең 3 классын тәмамлаганнан соң, 1809 елның 16 июлендә Спас өязенең Бездна авылына дьякон итеп билгеләнә. 1818 елның 9 июнендә Базяково авылына атакай итеп куела. 1824 елда 25 сум штрафка тартыла. Эчкечелек һәм башка «непристойные поступки», авыл халкының аны приходта күрәсе килмәү сәбәпле, ул 1827 елда эшеннән азат ителә. 1828 елның октябрендә Кызылъяр авылына билгеләнү турында указ ала. Приходта аның карамагына 651 кеше, шул исәптән, Чирүле Шонталасындагы хәрбиләр, ясаклы татарлар (16 ир-ат һәм 21 хатын-кыз), Кызылъяр алпавытларының крестьяннары, Кыр Шонталасындагы (72 ир-ат һәм 70 хатын-кыз) һәм Байтирәк авылындагы (21 ир-ат һәм 37 хатын-кыз) чукындырылган татарлар керә.

Кызылъяр атакае Алексей Мефодьевның Пелагея, Фекла һәм башка татарларның мөселманлыкка кайтуына төп гаепле кеше итеп Чирүле Шонталасы мулласы Әхмәт Әхмәревне күрсәтүе, үз «гөнаһ»ын башкага аударып, тикшерү органнары каршында үзен «фәрештә» итеп күрсәтү максатыннан булгандыр. Чөнки ул үзенең Кыр Шонталасы һәм Байтирәк авылларында гомер итүче чукындырылган татарларны православие динендә тота, тәрбияли, указлы муллалар эшчәнлегенә каршы тора алмавын, әхлаксызлыгы белән татарларны православие диненнән биздергәнен бик яхшы аңлаган. Нәкъ аның карамагында булган Кыр Шонталасы һәм Байтирәк авылларындагы чукындырылган татарлар 1839 елда, дәррәү кубып, мөселманлыкка кайта. Моңа исә, чукындырылган татарларга чиркәү әһелләренең формаль карашы һәм Кыр Шонталасы указлы муллалары Хәмит Мортазин (1775-1800), Вәлид Сәетов (1800-1832), аның улы Бикмөхәммәд Вәлитов тырышлыгы (1832-1867) сәбәпче була. Татарстан һәм Бошкортстан Республикалары Милли архивларында муллаларның эшчәнлеге – өйләрендә мәдрәсә оештырып, чукындырылган татарларны укытулары, мәчеткә намазга кертүләре, авылдашларының өйләрендә иконалар тотмавы, муеннарына тәре асмавы, мөселманча киенеп йөрүе, чәчләрен кырдыруы, атакайлар килгәндә хатын-кызларның мөселман йортларына кереп качуы һ.б. турында шактый мәгълүмат саклана.

Атакайлар баю юлын сайлаганнар

Рухи остаз булырга тиешле затлар – христиан һәм, шул исәптән, ислам дине әһелләренең – руханиларның әхлакый дәрәҗәсе, намусы, шәхси сыйфатларының мәхәллә халкына йогынтысы тарих фәнендә бик аз тикшерелгән. Совет чорында, аеруча атеизм шартларында өйрәнелгән очракта да, объектив бәя бирелмәгән, сәяси режимга яраклашыр өчен генә каралтып күрсәтелгән.

Әби-бабайлардан калган риваятьләр буенча, Кызылъярдан атакайларның авылга бик сирәк килүен, килгән очракта да тәре сатып йөрүләрен яки яхшы гына сыйлануын әйтеп узарга кирәк. Күрәсең, татарларны мөселманлыктан аера алмавын


Дѣло № 17
о скотоложствѣ крестьянина
села Краснаго Яра Андрея Алексан-
дрова обвиняемаго. № 2635
Начато 11го Октября 1864 г.
р. 26 Маія 1865 г.

Кызылъяр авылыннан Андрей Александровның бия белән җенси мөнәсәбәткә керүе турындагы эш (ТР МА.17 нче фонд, 66 нчы тасв., 216 нчы эш)

аңлап, алар эшкә формаль рәвештә генә караган, күп кенә хәлләргә күз йомган. Яңа чукындырылган татарлар да, чиркәүгә язык әйтергә һәм өлеш алуга барып яки балаларына исем куштырып кайткач, мөселманча яшәүләрен дәвам иткән. Моңа, күпмедер дәрәҗәдә, атакай тутырган чиркәү документлары да ишарәли. Чыннан да, 1795-1838 еллардагы чиркәү документларында авыллардан язык әйтергә һәм өлеш алуга килгән чукындырылган татарларның исеме, яше күрсәтелгән графада «балалардан тыш, өлкәннәр генә булды» дип язылган. Кайбер очракта исемнәр буталган, яшьләре дөрес язылмаган. Әйтерсең, исемлек уйлап чыгарылган.

Мондый хәл татарларга да кулай булган: формаль рәвештә атакай янына елына бер-ике тапкыр гына барып, әҗерен биреп кайткан да мөселманча гомер иткән. Балаларын чиркәүгә йөртмәгән, аларны христиан дине йогынтысыннан саклаган. Әлбәттә, мондый хәлләр, күбесенчә, Кыр Шонталасындагы кебек мәчетле, мөселманнар белән керәшеннәр аралашып яшәгән чиркәүсез авылларда еш күзәтелгән. Атакайлар да татар телен белмәгәннәр, белергә теләмәгәннәр, җаена карап, баю юлын сайлаганнар. Чукындырылган татарлардан акча таләп итүләре, эчкечелек белән шөгыльләнү фактлары архив документлары белән дә раслана. Мисал өчен, атакай А.Мефодьев улын Чистай өяз училищесында түләп, дөресрәге, мәхәллә халкы хисабына укыта. Мондый эшләрне булдырмас өчен, Казан рухани консисториясе Кубас һәм Кызылъяр чиркәүләре руханиларына карата төрле чаралар күрергә тырыша. Мәсәлән,

1839 елның 10 октябрендә Казан консисториясендәге тикшерү нәтиҗәсендә атакай Мефодьевның русчадан татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә итә, яза белмәве, сөйләм телен аз гына аңлаганлыгы ачыклана. Бу атакайларның чукындырган татарларны дини яктан тәрбияләү түгел, хәтта рус крестьяннарына да йогынтылары аз булган, күрәсең. Шул сәбәпле, соңгылары әхлаксызлык упкынына тәгәрәгән, аларда төрле бозыклыклар таралган. Эчкечелек, сугыш-кыйнаштан тыш, Кызылъяр авылында яшәүче кайбер крестьяннарның, түбән дәрәҗәгә төшеп, йорт хайваннары белән җенси мөнәсәбәткә керүе күзәтелгән. (Сүзебез шик-шөбһә, бәхәс тудырмасын өчен, архив документын да тәкъдим итәбез.) Кешеләрнең мондый түбәнлекләргә төшүе дин әһелләренең халык алдында абруе юклыгын, авылдашларына остаз була белмәүләрен, дингә, әхлакый тәрбиягә бармак аша гына карауларын күрсәтә. Бу урында, чиркәү абруен саклап калу ниятеннән, руханиларның эшенә мәхкәмә тарафыннан бәя бирелми, ә Консистория аларны, эчкечелектә гаепләп, Казанга дәваланырга – «дин йолаларын үтәргә» генә җибәргән. Мәсәлән, Кызылъяр чиркәвенең икенче рухание Алексей Иванович Рождественский, 1841 елда Консисториягә чакыртылып, бер ай буе кафедраль собор протоиерее Флегонт Талантов күзәтчелегендә эчкечелектән «дәваланып», айнып, иман яңартып кайткан.

Шулай итеп, атакайлар, чиркәү әһелләре, үз милләттәшләренең, авылдашларының әхлагын, рухи дөньясын кайгыртасы урында, судтан судка йөреп, мескен бер татар хатынын авыруга дучар иткән, хак исламга кайтучыларны эзәрлекләгән.

Кыр Шонталасы халкыннан ант-присяга. 1845 елның 14 гыйнвары


Татарская присяга

Иван Михайлов: «Гөләйзаны китереп тапшырырмын!»

Кызылъярда баручы мәхкәмәнең күчмә утырышына кире кайтып, шул ук көнне Кыр Шонталасы авылы крестьяннарыннан да сорау алынуын билгеләп үтик. «Мирской начальник» Иван Михайлов депутатлар катнашында 2 нче стан приставы Шахтка: *«Минем карамакка бирелгән авылдашларым Фекла Тимофееваны, Измаил Ефремовны, аның тәрбиягә алган улы Иван Денисовны хатыны Марфа белән, шушы эш тәмамланганчы беркая да җибәрмәм һәм таләп иткәндә китереп тапшырырмын»*, – дип язылган кәгазь биргән.

Шул ук көнне Чирүле Шонталасы авылы полиция сотнигы Әбүталип Ташаев та авылдашы (чынында, туганы) Хәким Камаевны, «аның белән законсыз гомер итүче Гөләйзаны», указлы мулла Әхмәт Әхмәревне күзәтү астына алуы турында расписка язган.

Шушы гамәлләрдән соң, 1844 елның 28 февралендә, 2 нче стан приставы земство мәхкәмәсенә рапорт юллый. Анда: *«Биләр өлкән атакае Лавров хаты нигезендә, христианлыктан тайпылган Кыр Шонталасы авылы хатын-кызы Гөләйза турындагы җинаять эше буенча, депутатлар катнашында мин туплаган 29 битлек тикшерү материалларын, законлы хәл итү өчен, Сезгә тапшырам»*, – дип язылган. Рапортның земство мәхкәмәсенә 2 мартта кергәнлеге теркәлгән.

Земство мәхкәмәсе: «Христиан руханиларының игътибарсызлыгы аркасында...»

«Гөләйза эше», стан приставы рапорты буенча, Чистай земство мәхкәмәсендә 1844 елның 4 мартында кабат карала. Эшне карап чыгып, мәхкәмә мондый карар чыгара: *«Кыр Шонталасы авылыннан Фекла Тимофеева яшьли ятим калган, кеше өстендә торып, законсыз ул һәм кыз тапкан. Соңгысы, ягъни Пелагея, ә татарча Гөлайза исемле кызы, христиан гореф-гадәтләрен үтәмичә, татар мөселманы белән гаилә корып, законсыз рәвештә ике малай тапкан. Ул балаларга Спас өязенең Урта Тигәнәле авылыннан Ә.Әхмәрев татарча исемнәр кушкан. Христиан руханиларының игътибарсызлыгы аркасында алар шушы юлга баскан. Барлык материалларны, шул исәптән, элегрәк 2 нче стан приставы вазыйфаларын башкарган провинция сәркатибе Шоших, 9 нчы класслы чиновник Разумов, коллегия регистраторы Михайлов һәм хәзерге вакытта отставкадагы корнет Шахтның гамәлләрен яңадан тикшереп, Чистай өяз мәхкәмәсенә тәкъдим итәргә».* Карарны сәркатип вазыйфасын башкаручы Невфалинов имзалаган.

Өяз мәхкәмәсе: «Гөләйзаны Казанга җибәрергә»

10 мартта Чистай земство мәхкәмәсе «Гөләйза эше»н өяз мәхкәмәсенә җибәргән. Соңгысы, эшне тикшереп, 18 апрельдә: *«Рапортны эшкә беркетеп куярга, әгәр православиедән тайпылган Гөләйза канун буенча Рухани консистория әгъзалары тарафыннан үгетләнергә тиеш булса, аны балалары белән төбәк мәхкәмәсе аша Казанга, Консисториягә җибәрергә, ә эш тәмам»*, – дип, үз карарын чыгарган. Земство мәхкәмәсе *«Өяз мәхкәмәсенең карарын гамәлгә ашыруны 2 нче стан приставы вазыйфаларын башкаручыга йөкләргә»* дигән карар кабул иткән. Гөләйзага иреннән аерылу, үзен һәм балаларын чукындырганнан соң, «әхлагын төзәтү өчен» руска яки керәшенгә көчләп кияүгә бирелү куркынычы янаган.

Әмма стан приставы А.Шахт мәхкәмә карарын гамәлгә ашырырга өлгерми...

Шахт: «Гөләйза озак авырудан соң үлеп китте»

1844 елның сентябрендә 2 нче стан приставы яшерен рәвештә земство мәхкәмәсенә яңа рапорт җибәрә. Рапортта: *«Минем таләбемә Чирүле Шонталасы авылы полиция сотнигы Әбүталип Камаев: «Шушы авылда Хәким Камаев белән гомер итүче Гөләйза, язгы чәчү алдыннан, озак авырудан соң, үлеп китте», – дип хәбәр итте. Шул сәбәпле, 37 битлек эшне кире земство мәхкәмәсенә җибәрәм. Пристав вазыйфаларын башкаручы корнет Шахт»*, – дип язылган.

Буш каберләр яки ике каберле мәрхүмнәр

Гөләйзаны бакый дөньяга күчкәч тә тынычлыкта калдырмыйлар, аның рухын, туганнарын, авылдашларын рәнҗетерлек гамәлләр кылу дәвам итә. 1845 елның 14 гыйнварында А.Шахт, Кыр Шонталасы татар мөселманнарын Кызылъярдагы управага җыеп, ант иттерә һәм сорау ала. Беренче булып, Бикчәнтәй Ибәтуллин җавап тота. Ул: *«Гөләйза 1844 елның апрель аенда язгы чәчү алдыннан вафат булды, христианча да, мөселман гореф-гадәтләре буенча да җирләнмәде»*, – дип сөйли. Башкалар да шулай җавап бирә.

Кыр Шонталасы авылы халкыннан Гөләйзаның үлеме турындагы сораштыру мәетнең нинди йола буенча җирләнгәнен ачыклау максатыннан каберне казып мәшәкатьләнмәс өчен эшләнгән. «Христианча да, мөселман гореф-гадәтләре буенча да җирләнмәде», – дигән җаваптан мәрхүмәнең кабере Кыр Шонталасы авылының өченче – мөселманлыкка кайткан татарлар зиратында икәнлеге аңлашыла.

Авылның икенче – «керәшен зираты» 1745 елгы көчләп чукындырудан соң барлыкка килә. 1838 елдан соң мөселманлыкка кайтучыларның җәсәдләрен 1905 елга кадәр яңа – өченче зиратка җирләгәннәр. 1854 елгы картадан чукындырылганнар һәм мөселманлыкка кайтканнар җирләнгән зиратларның мәйданы тигез икәнен күрәбез. Ә иң гаҗәбе: берсенә мәрхүмнәр – бер гасыр, икенчесенә нибары 10-15 ел дәвамында гына җирләнгән! Мөселманлыкка кайтучылар берничә дистә ел эчендә кинәт күпләп үлгән, дип, һич кенә дә әйтеп булмый. «Керәшен зираты»нда җирләнгән мөселманлыкка кайткан мәрхүмнәрнең мәетен, атакай китеп баргач, авылдашлары казып алып, җеназа намазы укып, яңа урында җирләү фактлары билгеле. Шуңа нигезләнеп: «Кыр Шонталасында да мондый хәл кабатланмадымы, христианча күмелгән мәетләр яңа зиратка күчерелеп, мөселманча җирләнмәдеме, «Керәшен зираты»ндагы каберләр буш түгелме икән?» – дигән сорау туа. Әлбәттә, моны раслау өчен, әлеге зиратта казу эшләре алып бару кирәклеге аңлашыла.

«Керәшен зираты», Кыр күленең биек ярында булып, Кыр Шонталасы авылындагы чукындырылган татарларның мөселманлыкка кайтуы сәбәпле, үзенә ихтыяҗны югалткан. Аның сакланып калган киртәләрен авыл халкы Бөек Ватан сугышы елларында утын урынына ягып бетерә. Совет чорында зират урыны күмәк хуҗалыкның техника «каберлеге»нә әверелә, бер өлешенә алмагачлар утыртыла. Шулай да, авыл кешеләрендә бу каберлеккә карата хөрмәт саклана. Кайбер бабайлар, «Керәшен зираты» өстендә уйнаучы балаларны кисәтеп: «Каберләрне таптамагыз, анда сезнең әби-бабаларыгыз җирләнгән бит!» – дип әйтә торган булган. 1970 нче елларда да бабайларның, «Керәшен зираты»на менеп, Коръән укуларын әйтеп үтү урынлы. Ә исламга кайтканнарның зираты, еллар узу белән, мөселманнар каберстаны зураю сәбәпле, уртада калган.

Дошманнардан, шымчы һәм куштаннардан саклану максатыннан, Гөләйзаны соңгы юлга озатуда авылдашлары – Кыр Шонталасының указлы мулласы Бикмөхәммәт Вәлитов һәм указлы мәзин Мөхәммәтша Вәлитов катнашмый. Заманы өчен шактый куркыныч дип саналган әлеге изге йоланы башкарып чыгу эше Чирүле Шонталасы авылы мулласына тапшырыла.

Ахыры киләсе санда ■

ҖҮЧИ ОЛЫСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ХАНБИКӘСЕ *һәм ислам дине*

Илнур Миргалиев

Җүчинең хатыны Хан-Солтан – тарихыбызда аз мәгълүм шәхес. Әмма ул Алтын Урдада исламның дәүләт дине буларак кабул ителүендә гаять мөһим роль уйный. Хан-Солтан – Хәрәзем шаһы Мөхәммәднең олы кызы. Аның Җүчигә кадәрге ире – караханилар нәселеннән булган Сәмәрканд солтаны Госман. Әмма Хан-Солтан, әсирлеккә алынганчы ук, 1212 елда билгесез сәбәпләр аркасында ире Госманны тәхет тирәсендәге караханиларның барлык вәкилләре белән бергә җәзалап үтертә.

1220 елда Мазендәрандагы Илал ныгытмасы монголлар тарафыннан алынган вакытта Хәрәзем шаһы Галәветдин Мөхәммәднең (1169-1220) әнисе Теркән хатын (1150 нче елларда туган – 1223 елда вафат) белән кызы Хан-Солтан әсирлеккә төшә. Чыңгыз хан аны олы улы Җүчигә өченче хатын итеп бирә. Әлеге парның Бәркә, Бәркәчар һәм Бури исемле уллары туа. Бу вакыйгалар тимури Шахрух сараенда 1426-1427 елларда язылган «Нәсел шәҗәрәсен данлаучы китап»та теркәлгән.

Хан-Солтан турындагы чыганаклар бик аз, әмма шактый кызыклы. Мәсәлән, энесе солтан Җәләлетдиннең кятибе һәм елъязмачысы Шиһабетдин Мөхәммәд ән-Нәсави «Сират әс-солтан Җәләлетдин» исемле китабында аның хакында менә ниләр яза: *«Солтан Мөхәммәднең олы кызы Хан-Солтан әбисе Теркән хатын белән әсир ителә. Аны Җүчи хан үзенә хатын итеп ала һәм Хан-Солтан аңа балалар таба. Хан-Солтан үзенең агасы Җәләлетдингә татарлар турындагы яңалыкларны хәбәр итә. Ә иң мөһиме – Җүчи хан үз балаларына Коръән укытырга куша, ди»*. Чыганактан аңлашылганча, Хан-Солтанның балалары, шул исәптән Бәркә дә, балачактан ук ислам дине рухында тәрбияләнә.

Бәркә хан тамгасы белән сугылган тәңкә

Бәркә хан. Р.Шәмсетдинов рәсеме

Бәркә (1209-1266) Чыңгыз хан нәселеннән беренче булып ислам динен кабул итүе белән тарихка кереп калган. Агасы Батый хан яуларында катнашып чарланган. Бәркә, Сартакның үлеменнән соң, 1256 елда Батыйның өлкән хатыны Баракчин ханбикә тарафдарлары каршылыгын җиңеп, тәхеткә утыра. Ул 1258-1259 елларда Литва, Польша һәм Волынь, 1265 елда Византия илләренә яулар оештыра. Бәркә исламны дәүләт дине буларак кабул итә, илнең дөньядагы йогынтысын көчәйтә, чикләрен киңәйтә, җүчиләр тамгасы белән акча суктыра, халык санын исәпкә ала башлый, баскаклык идарәсен гамәлгә кертә, гаскәрне камилләштерә. Бәркә хан булганда Җүчи Олысы Монгол империясеннән бәйсезлеккә ирешә.

Монгол империясенең барча мөселманнары да, намаздан соң дога кылганда, Бәркә исемен телгә ала. Мисыр мәмлүкләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырылганнан соң, Мәккә, Мәдинә, Иерусалим һәм Каһирә мәчетләрендә дә Бәркә ханның исәнлегенә дога кыла башлыйлар. Шунысын да искәртик: мәмлүк солтаны Сәйфетдин Котаз (?-1260) – Бәркәнең әнисе ягыннан туганнан туганы. Шунлыктан, Бәркә ханның ислам мәмләкәтләре белән якынаюы гаҗәп түгел. Мөселманнарның Бәркәгә тугрылыгы, аны хөрмәтләве хакында XIII-XIV гасырларда яшәгән башка авторлар да хәбәр итә. Мисыр елъязмачысы Шиһабетдин ән-Нүвайри (1279-1332): *«Бәркә мөселман булды, иманы да камил иде. Ул ислам динен күтәрде, мөселман гореф-гадәтләрен урнаштырды, фәкыйһләр белән аралашып, аларны үзенә якынайтты һәм дәүләтендә мәчет-мәдрәсәләр төзетте»*, – дип язып калдырган.

Бу мәгълүматны Бәркәнең замандашы, фарсы тарихчысы Әбү Гомәр әл-Җүзҗани (XIII гасыр) тулыландыра төшә: *«Аның гаскәре утыз мең мөселманнан тора һәм алар җомга намазын укый. Ышанычлы кешеләр аның барлык гаскәрендә мондый тәртип диләр: һәр җайдакның үзе белән намазлыгы булып, вакыты җиткәч, шуны җәеп, намаз*

*укырга тиеш. Бер генә гаскәри дә шәраб эчмәс. Гаскәрнең үзе белән тәрҗемәчеләр, фәкыйһләр, мөхәддисләр (*хәдис галимнәре. – ***Ред.****) һәм галим-голәмә булыр. Ханның бик күп дини китаплары бар. Җыелыш һәм очрашуларының күбесе мәшһүр галимнәр катнашында уза. Сараенда шәригать фәненә кагылышлы бәхәсләр оештырыла. Дини эшләрдә Бәркә гадәттән тыш тырыш һәм максатчан».*

Бәркә ханның әлеге гамәлләре XIII гасыр өчен гаять үзенчәлекле. Чөнки ислам диненә бәйле моның хәрәкәт ул вакыттагы татар-монгол җәмгыяте өчен гадәти булмаган. Чыңгызыйлар нәселеннән булган даирә вәкилләре – несториан, буддист, тәңрече, әмма бер Аллаһка иман китерүчеләр – мөселман түгелләр иде. Бәркәнең дәүләттә иң югары урынны биләве исламны Евразиянең аксөякләре арасында киңрәк җәелдерергә мөмкинлек бирә.

Ни өчен Бәркә, үз даирәсенә хас булган динне кабул итеп, дәүләт дәрәҗәсенә күтәрмәгән соң? Нигә өстенлекне исламга биргән? Тарих фәнендә Бәркә ислам динен, хан булганчы ук, Бохарадагы абруйлы суфи, шәех Сәйфетдин әл-Бохарзый (1190-1261) йогынтысында кабул иткән дигән караш бар. Бу фикер XIV-XV гасырларда яшәгән гарәп авторларының хезмәтләре, иң беренче чиратта, Ибне Халдун (1332-1406) китабы нигезендә әйтелде. Сәяхәтченең язуына караганда, шәех үзе үк ислам динен кабул итү тәкъдиме белән Бәркәгә мөрәҗәгать иткән. Бәркә, Бохарзыйның теләген тормышка ашырып кына калмыйча, аңа Җучи Олысы биләмәсендә иркен йөрү хокукын бирә торган хат та җибәрә. Шәех, суфи буларак, әлеге игелекне кире кага, нәтиҗәдә, Бәркә Бохарага үзе китә. Бәркә Әл-Бохарзый белән әңгәмә вакытында шәһадәт китерә – Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәткә лаеклы зат булмаганына, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәсәлламнең Аллаһның илчесе булуына ышануын белдерә һәм үз халкын ислам диненә ачыктан-ачык дәгъват кылачагы турында нәзер әйтә.

Ибне Халдун биргән мәгълүматны Мисыр авторлары да раслый. Аларның күбесе – Шиһабетдин әл-Гомәри (1301-1349), Шиһабетдин әл-Калкашанди (1355-1412), Бәдретдин әл-Айни (1360-1451) Бәркә ислам динен хан булганчы ук кабул иткән дигән фикердә тора. Чыганак авторлары Бәркәнең Бохарага баруын 1251 елда Корылтайга сәяхәте белән бәйли. Бөек монгол корылтаенда Бәркә һәм аның яраннарына малны хәләл итеп, юкка гына мөселманча чалмыйлар. Әл-Айни Бәркә Бохарага сәяхәт иткәнче үк мөселман булган дип санаса, әл-Гомәри һәм әл-Калкашанди булачак ханның исламны турыдан-туры Әл-Бохарзыйдан кабул иткәнлеге хакында яза.

Ибне Халдун, без искә алган башка урта гасыр тарихчылары кебек, «Бәркә ни өчен ислам динен кабул иткән?» дигән сорауга җавап бирми. Дөрес, Әл-Бохарзый үзенең вәгазьләре белән Бәркәнең фикер-карашларына җитди йогынты ясаса да, аны ислам динен кабул итәргә этәрүче сәбәп булмаган. Ханның ислам дине белән аңа кадәр үк якыннан таныш икәнлеге хакында берничә факт бар. Беренчедән, шәехнең Бәркәгә мөрәҗәгать итүе генә дә Җучи Олысы ханының ислам динендә икәнлеген сөйли. Бәркәнең шәех тәкъдименә тиз генә риза булуы да аның хак мөселман булуын раслый. Бу җәһәттән, Әл-Бохарзый белән күрешергә керер алдыннан, Бәркәнең үз-үзен тоту тәртибе дә игътибарга лаек. Монгол империясенең идарә итүче катламы вәкиле өчен шактый түбәнчелекле күренеш – хөҗрәгә керү өчен чакыру көтеп торуы да ханзадәнең дини карашлары эчкерсез һәм саф булуы, суфичылык гореф-гадәтләренә хөрмәте турында сөйли.

Төрки-татар тарихи әсәрләре дә бу фикерне кабатлый. Үтәмеш хаҗи һәм Габделгаффар Кырыми да Бәркә һәм аның белән булган могҗизаи хәлләр, шәех Әл-Бохарзыйда укыган еллары турында мәгълүмат бирә.

Болар барысы да безгә Бәркәнең ислам дине белән Бохарзый белән очрашканчы, хан булганчы ук танышлыгы – мөселман булганлыгы хакында тулы ышаныч белән әйтергә мөмкинлек тудыра. Чыганаклар хан углының танылган шәех белән аралашуы, аннан дәресләр алганлыгы турында гына түгел, ә суфилар даирәсе йогынтысында да

Газан хан ислам динен кабул итә. Рәшидеддин кулъязмасыннан миниатюра. XIV гасыр

булганлыгын сөйлиләр. Бу шул заман өчен аеруча актуаль, чөнки XIII гасырда хәлифәт җимерелеп, эре мөселман дәүләте таркалганнан соң, халыкчан ислам өстенлек ала, суфичылык гади халык өчен күпкә якынрак була.

Әлеге җәһәттән, Җүзҗанинең дә язмалары кызыклы. 1260 елда Бәркә ханлык иткән заманда язылып төгәлләнгән «Табакатен-Насыйри» хезмәтендә ул менә ниләр әйтә: *«Бәркә әтисе мөселман җирләрен яулап алган вакытта дөньяга килгән. Дөньяга аваз салгач, әтисе: «Бу углымның кендеген мөселман киссен, мөэмин мөселман булсын өчен, мөслимәнең сөтен имеп үссен», – дигән»*. Моны исә Чыңгыз ханның олы улы – тәңречелек рухында тәрбияләнгән Җүчи хан үзе таләп итә!

Янә Хан-Солтанның абыйсы Җәләлетдингә язган хатын искә төшерик. Хатында ул балаларына Коръән укытылганы турында хәбәр итә. Хан-Солтан, Җүчинең хатыны буларак, чыңгызыйлар йортына Коръән сүзен, ислам дине йолаларын алып килә.

Дини толерантлык шартларында ханның йортында ислам нуры балкый, җүчиләрнең күбесе әлеге дин белән таныша, намазга баса. Бәркәгә ана сөте, тәрбия белән иман керә. Ул әнисеннән килгән традицияләрне дәвам итә һәм исламны дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрә. Бер үк вакытта Алтын Урдада башка дин тоту да тыелмый. 1261 елда Сарай әл-Мәхрүсәдә православие дине епархиясе ачыла.

Без Җүчи Олысын хак исламга күндерүдә биниһая роль уйнаган Хан-Солтанны хөрмәт белән искә алырга тиеш. Ул урта гасыр төрки-татар дөньясының олуг хатын-кызлары янәшәсендә мәртәбәле урын алырга лаек. ■

Тукай кичәсендә катнашучылар

«Сез бетәчәк түгел!»

(Ерак Шәрыкта Тукай кичәләре)

Ләлә Мортазина

Татарлар яшәгән кайсы гына кыйтгада Тукай кичәләре оештырылмады икән?! Япониядә, Кытайда, Кореяда, Финляндиядә, Германиядә, Польшада, Төркиядә, Мисырда, Америкада яшәүче, туган туфрагыннан, рухи мирасыннан аерылган татар мөһаҗирләре өчен Тукай – туган ил символы, татар телен, рухи бердәмлекне саклау чарасы булып хезмәт иткән. Үз телеңне онытуны зур кимчелек, түбәнлек санаган татарлар Тукай иҗаты, Тукай шәхесе, Тукай көннәре ярдәмендә миллилекне, милли әдәбиятны, мәдәниятне сакларга һәм үстерергә омтылган. Шулай итеп, Тукай бәйрәме чит илләрдә сибелеп яшәгән татарларны туплаган, берләштергән, саклап калган.

Тукай кичәләре Россиянең төрле шәһәрләрендә – татарның мәркәзе Казанда, Мәскәүдә, Петербургта, Уфада, Оренбургта, шулай ук Бакуда, Ташкентта, Бохарада, Семипалатинскида, Әстерханда, Троицкида, хәтта кайбер авылларда да уздырылган. Бу кичәләрдә Коръән укылган, бөек шагыйребезнең рухына дога кылынган, аның тәрҗемәи хәле, шигырьләре сөйләнгән, милли җырлар башкарылган.

Әдәби кичәләргә, шигырь бәйрәмнәренә әзерлек алдан ук оештырылган. Зал Тукайның рәсемнәре, китаплары, чәчәкләр белән бизәлгән. Бәйрәмдә катнашучылар күкрәкләренә «Тукай көне» дип язылган тасма тамгалар такканнар. Күп очракта,



Япониянең Нагоя шәһәрендә Тукай көне. 1937 ел, 15 апрель

рәсми өлеш тәмамланганнан соң, бәйрәм чәй табыны янында дәвам иткән. Әлеге кичәләр вакытында төрле максатлар өчен, мәсәлән, татар мәктәпләре, китапханәләр файдасына, аерым студентларга стипендия түләү, татарлар яшәгән төрле җирләрдә Тукайга һәйкәл ачу өчен иганә җыелган.

Тукай кичәләрендә, татарлардан тыш, башка милләт вәкилләренең дә катнашуы төрки-мөселман дөньясында аңа карата олы ихтирам турында сөйли. Чыннан да, татарлар гына түгел, башка төрки халыклар да бөек шагыйребезне яраткан. Төрки әдәбиятлар үсешенә зур йогынты ясаган татар шагыйренә багышлап, әсәрләр иҗат ителгән, аның шигырьләре башка телләргә тәрҗемә кылынган, зур шәһәрләрдә, шул исәптән, Ташкент, Бохара, Троицк, Алма-Ата кебек калаларның үзәк урамнарына Тукай исеме бирелгән.

Г.Әхмәди. Ерак Шәрыкта Тукаевны искә төшерү[1]

2 нче апрельдә, халык шагыйре Тукаевның вафатына ел тулу мөнәсәбәте илә, Харбин мөселманнары, мәсҗеткә җыелып, Тукаевны бик олуглап искә алдылар. Мәҗлес сәгать 9га тәгаен ителгән булса да, мәсҗеткә халык иртә белән, сәгать 8дә җыела башлады. Тукаев шәрәфе өчен әлеге көнне хатын-кызларга да күрергә рөхсәт ителде. Бу көн мөселман халыклары беренче мәртәбә үзләренең «И мөкатдәс яртыбыз» дип атаган шагыйрьләрене тәкъдир иттеләр. Сөннәт бүлмәсеннән генә булса да күреп, бу мәҗлескә иштирак итүне *(катнашуны)* үтенделәр. Ирләр фарыз бүлмәсенә, кыз-хатыннар сөннәт бүлмәсенә тулдылар. Сәгать 9да имам әфәнде, мөнбәргә чыгып, бу мәҗлеснең бондан бер ел элек вафат иткән Тукаев шәрифенә ясалганлыгын вә аның әһәмиятен бәян итте. Тукаевның тәрҗемәи хәлен вә бәгъзе шигырьләрендә булган шигърият вә мәгънәләрен аңлатты. Соңра Коръән укылып, мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукаевның рухына багышланды. Берәм-берәм мәктәп балалары чыгып, бик мөәссир *(йөрәккә үтүче)* бер тавыш белән, Тукаевның шигырьләрене укыдылар. Бу шигырьләрне укыган вакытта күзендән яшь килмәгән кеше аз булгандыр. Хосусан, *(аеруча)* 7 яшьлек бер баланың фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* назек вә нәфис бер

[1] Вакыт. – 1914. – 19 апрель.

Шанхайдагы Украина клубында Тукай кичәсе

тавыш белән «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле» дигән укуы вә «Кадер кич» бик тәэсирле чыкты. Соңра Агишев хезмәткәрләреннән Галимкәй әфәнде Акчурин «Мөхәммәдия» көенә Тукаевның «Пәйгамбәр» шигырен укыды. Тәгъбир мөмкин булмаслык бер тәэсир бирде. Соңра хөкүмәт мәктәпләрендә укучылардан Габдулла әфәнде Әхмәрев, хатыннар хөррияте, милләт вә миллият хакында булган бәгъзе шигырьләрене укып, Тукаевның хәятында булган бәгъзе вакыйгаларны рус әдәбиятларыннан, бәгъзеләренең башларыннан үткән вакыйгаларга татбикъ кылып *(туры китереп)* күрсәтте. Тукаев шигырьләре вә Тукай сүзләренең аз бер заман эчендә халык арасына таралуының сәбәп вә фазыйләтләрен сөйләде. Мәҗлестә сөйләнгән сүзләр, укылган шигырьләр халыкта бик зур бер тәэсир калдырды. Шул тәэсир белән халык, бу мәҗлесне хәтердә калдыру өчен, Тукаев исеменә ачылачак җәмгыятькә иганә кылдылар. 110 сум акча җыелды. Тукаевның асыл ватаны булган Казанга Тукаевның Ерак Шәрыкта булган тәкъдир итүче кардәшләре, телеграм җибәреп, үзләренең дога кылганлыкларын белдерергә булдылар. Телеграм укылганнан соң, тәкърар бер мәртәбә дога кылдылар. Дога ахырында «Амин!» тавышы белән мәсҗет яңгырады. Телеграм яхшы, озын язылган иде. 110 сум акча белән бу телеграм Казанга «Кояш» идарәсенә җибәрелде.

Хәбәрче. Тукай кичәсе[2]

Шанхай Төрек-татар мәдәният җәмгыяте тарафыннан 17 апрельдә шагыйребез Габдулла Тукайга багышланып эшләнгән кичә, узган елдагыча ук, бик муаффәкыятьле *(уңышлы)* рәвештә уздырылды. [...]

Мәҗлесне җәмгыятьнең рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәди бүген яд итә торган Тукайның, милли барлыгыбызны арттыру юлында күп хезмәтләр куйган Курсави, Каюм Насыйри, Шиһаб хәзрәт Мәрҗани, Исмәгыйль бәк Гаспралы, Гаяз әфәнде Ис-

[2] Мәкалә 1935-1945 елларда Ерак Шәрыкның Мукден шәһәрендә татар телендә чыгып килгән «Милли байрак» газетасының 1936 елгы 8 май санында басылып чыккан.

«Милли байрак»ның еллык зыяфәт *(кунак иту)* **мәҗлесе**

хакыйлар белән бер максат, бер идеал өчен янучы затларның берсе булуы һәм шул затлар тугрында көчебез, аңыбыз җиткән кадәр халкыбызга мәгълүмат бирү вазыйфалары – мәдәният җәмгыятьләренең эше икәнлеге тугрындагы сүзләр белән мәҗлесне ачты.

Соңра, мәктәп шәкертләре тарафыннан Коръән укылгач, Мәдинә ханым Әхмәди «Габдулла Тукай – борынгы ил шагыйрьләренең варисы» мәүзугында *(эчтәлегендә)* мәгъруза *(доклад)* эшләде. Халык әдәбияты, чыгытай, госманлы әдәбиятлары, аларның Тукайга тәэсире, халык әдәбияты аркылы үзен-үзе табуы хакында мәгълүмат бирде. Мәгърузадан соң зурлар һәм балалар мөрәккәб *(бергәләп)* күмәк «Өзелгән өмид»не җырладылар.

Шуның белән мәҗлеснең матәм мәрасиме бетеп, балалар кыйсеме башланды. Кичәдә иштиракъ иткән *(катнашкан)* балалар: Рифгать Хаҗи, Равил Әхмәди, Камал Мостафа, Рәшидә Ильяс, Тасия Габдрахман, Зәйтүнә Дүзи, Искәндәр Дүзи, Нияз Габдрахманнар – һәркайсы сөекле шагыйребезнең шигырьләрен бик килешле итеп әйттеләр, күмәкләп җырладылар. Шулай ук бик осталык белән Тукайның «Таз» һәм «Су анасы»н уйнадылар.

Әдәбият бүлеме беткәч, ханымнарыбызның тырышлыгы һәм уңганлыклары аркасында, бәйрәм көннәрендәге кебек күркәм хәзерләнгән өстәл янына кунаклар дәгъват ителделәр *(чакырылдылар)*. Җәбһәдәшләребезнең *(аркадашларыбызның)* сораулары буенча Габдулла Тукай турында аларга аерым мәгълүмат бирелде һәм алар да үз нәүбәтләрендә: «Сез, төрек милләте – шундый Габдулла Тукай кебек шагыйрьгә малик *(ия)* булуыңыз белән бәхетле милләтләрнең берсе. Сез бетәчәк түгел! Киресенчә, Тукайлардан көч алып, куәтле, мөстәкыйль милләткә әйләнәчәксез һәм сезнең шундый мәҗлесләреңездә булуыбызга бик шатбыз», – мәфһүмендә *(мәгънәсендә)* сүзләр сөйләделәр.

Шанхай имамы Әүхәди әфәнде динебезне, милләтебезне берлек аркасында гына саклый алганыбыз хакындагы сүзләр сөйләде. Сүзләр дәвамында Гайниҗамал ханым, Мәрьям ханым, Латыйфа ханым, Фатыйма ханымнар милли көйләребезне җырладылар. Рәшидә вәТасия туташлар, милли биюләребезне биеп, кичәгә матурлык бирделәр. Гомумән, кичә бик рухлы узып, килгән халык та бик мәмнүн *(канәгать)* калды. ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

DALEKI WSCHÓD

№ 7-8 (35-36) 15 Kwietnia 1933 roku Rok III

Wydawca: Stowarzyszenie „Gospoda Polska"
Redakcja i Administracja: 5, Gluhaya Str. Harbin

W ROCZNICĘ TUKAJOWĄ.

16 kwietnia b. r. cały świat Tatarski obchodzi 20 lecie śmierci wielkiego poety tatarskiego Abdulli Tukaja.

Kolonje Tatarskie w Mandżurji, Japonji, Chinach obchodzą dzień ten, jako wielkie narodowe święto.

W ośrodkach emigracyjnych powstały specjalne komitety opiekujące się i kierujące akcją obchodową.

Kolonja tatarska w Harbinie, jedna z najliczniejszych i najlepiej zorganizowanych kolonij w Mandżurji również bardzo uroczyście święci dzień tukajowski.

Miejscowe Towarzystwo Muzułmańskie wyłoniło specjalny komitet, który zorganizuje uroczysty obchód, na który złoży się akademja dla społeczeństwa starszego z zaproszeniem gości cudzoziemskich, poranek dla dzieci i młodzieży tatarskiej, oraz akcja zbierania składek na zasilenie wydawnictwa dzieł poety, podjętego w Tokjo przez tamtejszą kolonję tatarską. Obok tego ma pows[...] dek i ofiar specjalny fund[...] djalny im. Abdulli Tukaja, [...] udzielane będą zasiłki dla młod[...] scowej, udającej się na wyższe [...] ne studja do Europy.

Kolonja Polska w Harbini[e] żywem zainteresowaniem śledzi życiem bratniej kolonji tatarskie[j] z nią we wspólnym hołdzie, składanym wieszczowi tatarskiemu—Abdulli Tukajowi.

Poza uczęstniczeniem reprezentantów organizacyj polskich w obchodzie tukajowskim, redakcja „Dalekiego Wschodu" poświęci w numerze niniejszem swego pisma kilka stron wielkiemu poecie tatarskiemu i przeglądowi uroczystości, jakie się odbywają lub mają się odbyć na terenie kolonij tatarskich na Dalekim Wschodzie.

Najlepszą pamiątką tukajowską byłoby tłumaczenie jego poezyj na język polski, które należałoby wykonać w czasie jak najbliższym.

DALEKI WSCHÓD

№ 7-8 (35-36) 15 Kwietnia 1933 roku Rok III

Wydawca: Stowarzyszenie „Gospoda Polska"
Redakcja i Administracja: 5, Gluhaya Str. Harbin

JEDEN Z ZAKĄTKÓW W STARYM PEKINIE.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ иҗаты поляк телендә

Ләйсән Галиева

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның аерым әсәрләре дөньяның ике дистәдән артык теленә тәрҗемә ителгән. Шагыйрьнең энциклопедиясенә мәкаләләр әзерләү барышында Польша татарлары әдәбияты буенча хезмәтләре билгеле поляк галиме **Гжегож Червинский**га (соңрак, 2017 елда, поляк телендә басылып чыккан, поляк-татар әдәбиятының 1918 елдан соңгы тарихы буенча «Мин – күчмәннәр ыруыннан» дип исемләнгән монография авторы) Г.Тукай әсәрләренең поляк теленә тәрҗемәләрен эзләвен сорап мөрәҗәгать иткән идек. Әмма галим Г.Тукай иҗатының поляк теленә тәрҗемәсе билгеле булмавын хәбәр итте. 2011 елда «Przegląd Tatarski» («Татар күзәтүе») журналында басылган «Татар халкының бөек шагыйре» исемле мәкаләсендә дә ул: *«Кызганыч ки, Польшада Тукай шигърияте белән танышу шактый авыр мәсьәлә, чөнки татар әдәбияты буенча поляк телендәге басмалар юк дәрәҗәсендә»*, – дип яза. Г.Червинский мәкаләдә поляк татарларын (әлар, ислам динен сакласалар да, туган телне күптән оныткан) шагыйрьнең кыскача биографиясе, иҗаты белән таныштыра. Галим поляк шагыйре **Адам Мицкевич**ның

«Daleki wschod» журналының Габдулла Тукайга багышланган сәхифәләре. Харбин

> Тукайның, бер шагыйрь буларак, поляк җәмәгате эчендә, бигрәк тә аның яшьләре арасында атаклы бер шагыйрь булып китәрлек отышлы яклары бик күп.

«Филомат юллары» һәм Г.Тукайның «Дустларга бер сүз» шигыре арасында уртак мотивлар таба. Филомат* традицияләре, белгеч фикеренчә, бигрәк тә «Голүмең бакчасында...» шигырендә дә ачык чагыла. Шагыйрьнең «Чыршы», «Ай һәм Кояш», «Җәй көнендә», «Иртә» әсәрләрен исә **Чеслав Милош**ның шигъри юллары белән чагыштыра.

Нәкъ менә «Тукай энциклопедиясе»н басмага әзерләү эше барышында шагыйрьнең әсәрләре поляк теленә тәрҗемә ителгән һәм 2015 елда «Rocznik Tatarów Polskich» («Польша татарларының елъязмасы») басмасында дөнья күргән. «Туган тел», «Бер татар шагыйренең сүзләре» әсәрләрен татар теленнән **Антони Саркади**, «Хөррият хакында», «Милләтә», «Алтынга каршы», «Шагыйрь», «Күңел», «Нәсыйхәт», «Иртә», «Яз галәмәтләре», «Кичке теләк», «Тәфсирме? Тәрҗемәме?», «Казан» шигырьләрен исә рус теленнән Польшада яшәүче журналист һәм җәмәгать эшлеклесе **Муса Чахоровский** тәрҗемә кыла. Шигырьләр алдыннан **Зайонц Гражина** Г.Тукай һәм аның иҗаты хакында кыскача мәгълүмат биреп уза. Сүз уңаеннан шуны да әйтик: 2019 елда М.Чахоровский тарафыннан Муса Җәлил шигырьләре дә поляк теленә тәрҗемә итеп бастырыла. Ул – «Rocznik Tatarów Polskich» җыентыгының, шулай ук Польшада дүрт айга бер чыга торган «Przegląd Tatarski» һәм «Литовск татарлары» басмаларының мөхәррире, унике шигырь җыентыгы авторы да әле.

---

*Филоматлар (грек. «белемгә омтылучы») – 1817-1823 елларда Вильна университеты студентларының яшерен патриотик һәм мәгърифәтчелек берләшмәсе. Соңыннан аның әгъзалары булып күренекле шагыйрьләр, галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре дә тора.

بزنك بارش

№ 1 آپریل. 1933.

توقای تانتاناسی.

«Daleki wschod» журналының татарча басылган «Безнең барыш» кушымтасы (1933 ел, №1). Харбин

***

Г.Тукай иҗаты шагыйрь үзе исән чагында поляк һәм Польшада яшәүче татар халкына таныш булганмы-юкмы – төгәл әйтүе кыен. Әмма шунысы хак: Казан ягыннан Польшага мөһаҗир буларак килгән татарлар, Г.Тукайга багышлап, төрле чаралар, кичәләр үткәргәннәр. Әлеге мәгълүматлар белән **Гаяз Исхакый** мөхәррирлегендә чыккан «Яңа милли юл» мәҗмугасыннан танышып була. Нәкъ менә татар әдибенең Польшадагы мөһаҗирлек чорын өйрәнү Г.Тукайның 1930 нчы елларда поляк теленә тәрҗемә ителгән шигырьләренә юлыктырды да инде.

1938 елгы «Wschod» («Көнчыгыш») журналының икенче санында, Г.Тукайның үлеменә 25 ел тулу уңаеннан, **Мехмед Вейси**нең «Идел-Уралның халык шагыйре Габдулла Тукай» дип исемләнгән мәкаләсе дөнья күрә. Мәкаләдә, шагыйрьнең биографиясеннән кала, аерым шигъри юллары уңышлы тәрҗемә ителгән, рифма сакланган. Әмма тәрҗемәченең исеме күрсәтелмәгән. М.Вейси Г.Тукайны милли телне үстерүгә

керткән өлеше өчен данлый, «Туган тел» әсәренең татар халкының гимнына әйләнүен ассызыклый.

Г.Тукайның поляк теленә тәрҗемә ителгән дүрт шигыре – «Милли моңнар», «Үз-үземә», «Өзелгән өмид», «Туган тел» 1933 елда Харбин шәһәрендә поляк телендә дөнья күргән «Daleki wschod» («Ерак Шәрык») журналында басылган. Кызганыч, тәрҗемәченең исеме күрсәтелмәгән. Г.Червинский фикеренчә, болар «әдәби тәрҗемә омтылышы» гына булып тора, полякча шигырьләрдә ритм, рифма сакланмау да күзәтелә. Галим фикеренчә, полякчага тәрҗемә ителгән шигырьләр шагыйрьнең рус телендәге тәрҗемәләре нигезендә башкарылган.

Татар шагыйре вафат булуга 20 ел тулу уңаеннан, әлеге басманың беренче мәкаләсе дә Тукайга багышланган. «Тукай юбилеена» дип аталган әлеге язманың авторы – галим **Хатыйп Миңнегулов** сүзләре белән әйтсәк, «Ерак Шәрыктагы татар мәдәни тормышының үзәгендә кайнаучы, аны оештыручы, нурландыручы, фидакяр затларның берсе», әдип, шагыйрь, журналист, артист, режиссер, мөгаллим, тәрҗемәче **Хөсәен Габдүш** (1901-1944). Язмадан күренгәнчә, шагыйрьне искә алу чаралары Манчьжурия, Кытай һәм Япониядә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан югары дәрәҗәдәге тантана рәвешендә оештырыла. Х.Габдүшнең Г.Тукайга багышланган әлеге мәкаләсенең кыскартылган варианты поляк телендәге «Życie» газетасында да бастырыла. Шунысы кызык: «Daleki wschod» журналының азагында гарәп имлясында «Безнең барыш» – «Ошбу исемдә Харбинда әледән-әле чыгып торачак татар тормышына багышланган сәхифәләр» урын алган. Биредә «сәхифәләр»нең идарәсе тарафыннан «Тукай тантанасы» дигән язма басылган. Кушымтаның икенче өлешендә Гаяз Исхакыйның «Ерак Шәрык» исемле мәкаләсе дә дөнья күргән. ■

Харбинда чыга торган полякча «Daleki wschod» журналының гарәп имлясында басылган «Безнең барыш» кушымтасыннан (1933 ел, №1) бер мәкалә тәкъдим итәбез. Әлеге кыска гына язмадан «Поляк халкы ни өчен Тукай иҗаты белән кызыксынган?» дигән сорауга җавап табарга мөмкин.

ТУКАЙ ТАНТАНАСЫ

Ошбу елның апрелендә татар халкы үзенең иң зур шагыйрьләреннән берсе булган Габдулла Тукайны искә төшерә. Манчьжурия, Япония, Кытай вә бөтен Ерак Шәрыкта булган татар мәхәлләләре Тукай тантанасына хәзерләнделәр. «Дальний Восток» журналы идарәсе, гомуми бәйрәмгә катнашып, үзенең берничә сәхифәсен бу бөек шагыйрьгә багышлады.

Без күптән инде Тукайның шигырьләрен поляк теленә тәрҗемә итәргә кирәклекне әйтеп узган идек. Тукайның, бер шагыйрь, буларак поляк җәмәгате эчендә, бигрәк тә аның яшьләре арасында атаклы бер шагыйрь булып китәрлек отышлы яклары бик күп. Самими, романтик, идеалистик иҗадияте хиссият берлә бөркелгән, халкының бәхете, яхшы киләчәге өчен көрәшүче – шундан да артык поляк рухының нечкә кылларына якын булырлык нәрсә булырмы?!

Хәзер, татар халкына каратып, берничә сүз. Алкышлыйбыз сезне, күп михнәт күргән егет халык! Сез омтылган нәрсә безгә бервакытта да ят булмады. Безнең арабызда самими бер якынлык бар. Тукайның иҗадияте поляк теленә күчерелү белән безнең ара тагын да якынрак булачак, чөнки Тукайның йөрәге һәм аның җырлары – алар безнең җырларыбызның, халкыбызның тәрбиячеләре булган романтикларыбызның авазыдыр.

Шуңа күрә дә без чын күңелдән Тукай тантанасына кушылабыз. Зур дәрәҗә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга!

Татар матбугаты тарихы

«КЫЗЫЛ УРАЛ» ГАЗЕТАСЫ

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

газета на татарском языке
«КЗЫЛ УРАЛ»
(Красный Урал)
Орган Челяб. Губмусбюро
Р. К. П. (б-в) и Губотнац.
Издание Челяб. отделения
Госиздательства.

Адрес редакции: г. Челяб.
Рабоче-Крестьянская улица
дом Холодова № 62 редакция
газ. „Кзыл Урал“

ТГ 99

№ 35 Вторник 8-го Марта 1921 г. № 35

بوکون ٨ نچی مارت، بەینەلمیلەل خاتونلار کونی!
شەرق خاتون-قزلاری! بوکونکی بو-
قەتدەس بەیرەمگە قاتناشو سزگەدە فەرز!

بەینەلمیلەل خاتونلار کونی.

«Кызыл Урал»ның 8 Март – Бәйнәлмиләл *(халыкара)* **хатын-кызлар көне уңаеннан чыгарылган саны. 1921 ел**

Исмәгыйль Рәмиев биргән мәгълүматка караганда, «Кызыл Урал» 1920 елның 27 октябрендә Чиләбе шәһәрендә чыга башлаган. «Бу газетаның алып язарлык бер генә дә аермалыгы юк. Бик тә тонык, фәкыйрь гәзит иде. Басылуы пычрак, җүнләп танылмый да. Чиләбедә «дәүләт матбагасы»нда басылып килде», – дип яза матбугат белгече газета турында. Шигаре – «Берләшегез, бөтендөнья юксыллары!» Газетаның үзенә: «Шәрык халыклары коммунистлары оешмаларының Чиләбе вилаят бюросы һәм вилаят милләтләр шәгъбәсе (бүлеге) нашир әфкяре», – дип язылган.

---

*Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905-1925): альбом. – Казан: Гажур, 1926. – Б.147.

Газета редакциясе Чиләбе шәһәренең Рабоче-Крестьянская (хәзерге Киров) урамындагы А.П.Холодов йортында урнашкан була

«Кызыл Урал», дөнья, партия яңалыкларын, шәрык халыклары хәлен яктырту белән бергә, Чиләбе, Троицк, Курган һәм башка шәһәрләрдәге, төрле приискалардагы татар-башкорт эшчеләренең мәсьәләләрен, аларның рухи дөньясын, мәдәниятен, мәгарифен чагылдырып килгән. Аеруча ачлык һәм әле фаҗига китереп чыгарган проблемаларга игътибар ителгән.

Чиләбе хәбәрләре

Вилаять мәгариф шәгъбәсе *(бүлеге)* янындагы вак милләтләр бүлекчәсе тарафыннан соңгы ике ай эчендә тәрбиясез калган ятим вә фәкыйрь татар-башкорт балалары өчен дүрт приют ачылып, бер җирдә балаларны кабул итү урыны корылды. Дүрт приютта 500гә якын бала урынлашып, кабул итү йортында бер йөзләп бала приютларга бүленмәгән хәлдә торалар. Моннан башка, рус приютларына 200 бала урнаштырылды. Һәрбер приютларда балалар тулы булып, көннән-көн артуында дәвам итә. Тагын да берничә җирдә ачарга ихтыяҗ бик зур булганлыктан, катгый чаралар күрелеп ята. Ләкин бөтен эш бина мәсьәләсенә бәйләнеп тора. Бина табуы бик читен булганлыктан, ачылырга тиешле булган приютлар да ачылмый торалар. Приют һәм балалар бакчасы өчен матди яктан кирәк булган нәрсәләр һәркайсы диярлек югары мөәссәсәләр *(оешмалар)* тарафыннан җитәрлек микъдарда тәэмин ителделәр. Шулай ук Троицк, Миасс, башка өяз шәһәрләрендә дә балалар приюты ачылып, вилаять мәгариф шәгъбәсе һәр яктан тиешле булган ярдәмнәр биреп тора.

Ләкин приютлар вә бакчаларның материальный җәһәтеннән ул кадәр зур кимчелек күрелмәсә дә, мөрәббиләрнең *(тәрбиячеләрнең)* җитешмәве эшкә бераз уңайсызлык китерә. Киләчәктә боларын да җитештерү чаралары күрелә. Хәзерге көндә Чиләбедә барысы 800ләп татар-башкорт баласы приютларга урынлаштырылды.

Кызыл Урал. – 1921. – 4 август.

* * *

Чиләбе һәм Троицк шәһәрләрендә 1919 нчы еллардан бирле мәгариф шәгъбәләре карамагында ике татар труппасы яшәп килә иде. Соңгы көннәрдә бу труппаларның икесе дә хөкүмәт карамагыннан чыгарылып таратылды. Чиләбе артистлары хәзерге көндә бөтенләй таралып беткәннәр булса кирәк. Чөнки 8 ноябрьдә бер спектакль куйганнар иде, шуннан бирле һичбер тавыш-тыннары чыкканы ишетелми. Дөресрәк әйткән чагында, Чиләбе артистларына хәзерге көндә Чиләбедә азык мәсьәләсенең читенләшеп китүе нык тәэсир иткән булса кирәк. Күбесе сату эшенә бик ихлас тотынганнар.

Чиләбе труппасының соңгы көннәрендә режиссерлык вазыйфасын үтәүче Җәмалетдинов иптәш тә, Себердән кайткач: «Мин – коммунист, партиядә торам», – дип лаф орып йөргән иде, хәзер инде станса базарының «атаманы» булган дип ишетәбез. Троицк артистлары ничек яши торганнардыр, алардан хәбәр алган юк әле.

М.Н.

Чиләбе, Троицк шәһәрләрендә һәм районнарында татар-башкорт эшчеләренең күплеген игътибарга алып, хөкүмәт карамагында бер-ике труппаның булуы бик матлуб *(кирәкле)* эшләрдән хисапланырга тиешле, чөнки мәдәниятендә артта калган татар-башкорт эшче һәм крестьяннарына санаигы нәфисә *(нәфис сәнгать)* аркылы күп кенә аң-белем бирергә мөмкин. Моның тәшәббесенә *(чарасына)* керешүне вилаят вак милләтләр мәгариф идарәсеннән таләп итәргә тиешбез.

Идарә.
Кызыл Урал. – 1921. – 12 декабрь.

Яшьләр тормышыннан

Верхний Урал өязе Балкан приискасындагы татар-башкорт яшьләре, аз гына паек алып та, ачлы-туклы яшәүләрен артка ташлап, үзләрен юксыллар дөньясында беренче

санда икәнлеген ачык күрсәтә беләләр. Октябрь аеның соң көннәрендә ачлар файдасына берничә тапкыр спектакльләр куеп, куелган әсәрләр арасында «Галиябану» кебек зур гына драмаларны да яхшы гына үтәп киләләр. Приискадагы татар-башкорт эшчеләре яшьләр тарафыннан сәхнәгә куелган бер әсәрнең тагын да тәкрар *(кабат)* куелуын таләп итәләр.

Балкан яшьләре хакындагы эш белән генә канәгатьләнеп калмыйча, шундагы партийный һәм партиясез яшьләр арасында караңгылыкны бетерү максаты белән, мәгариф вә мәдәният түгәрәге оештырылып, бу түгәрәк үзе берничәгә бүленә: сәяси, әдәби, художественный һәм музыкальный секцияләргә.

Гомумән, яшьләр арасында хәрәкәт булган кебек, яшь коммунистлар оешмасында әгъза булган иптәшләр тагын да артыграк хәрәкәт күрсәтәләр. Балкан яшьләре арасындагы хәрәкәт шул рәвешле, аларда инкыйлаби рух күтәренке булып, башка җирләрдәге юксыл яшьләре оешмаларына да үрнәк булмаслык түгел.

Г.Камалов.
Кызыл Урал. – 1921. – 12 декабрь.

Куртамышта

Куртамыш өязе Звериноголовски татар-башкорт яшьләре, ачларга ярдәм кылу максаты белән, 10 нчы ноябрьдә спектакль куеп, Ф.Әмирханның «Тигезсезләр» исемендәге 3 пәрдәлек пьесасы уйналды. Уйнаучыларның да бик ихлас белән уйнаулары сәбәпле, спектакльгә килгән иптәшләр мәмнүн *(канәгать)* булып таралдылар. Ләкин шунысы гына уңайсыз хәлдә калдыра: Звериноголовскида керосин юклыктан, май яндырып кына кичәләр үткәрелә. Майны спекулянтлардан алганлык белән, җыелган сборга күп кенә зарар итә. Звериный яшьләре тарафыннан ачлар файдасына 3 мәртәбә спектакль куелды. 20 000 сум акча җыелып, тиешле урынына тапшырылды.

Габдрахман Әхмәдев.
Кызыл Урал. – 1921. – 12 декабрь.

Текстларны басмага
***Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

М.Фәйзи һәм билгесез кеше. Юлык. 1920 нче еллар башы

М.Фәйзи көндәлегенең март аеннан (1922 ел) башланган битләре

Мирхәйдәр Фәйзи: «Никах сәгатьләре сукмый бит!»

1922 ел, март. Темәс

1ендә Темәскә җитеп, Садыйк Чанышев фатирына төштем. Хәерле, җитеш урыннар булсын! Темәстә туклык, туганлык, дуслык, ямьлелек каршылады үземне. Тән һәм җан азыгы белән бәшарәт ителдем. Яшьләрнең репетициясе, рухи як белән дә өлешсез түгеллек белән сөенеч алдым. Җан тынычлап, Садыйк белән бергә генә ятып, сөйләшә-сөйләшә йоклап киттек.

2сендә Садыйк кунак итә. Күмәч мул, ак май бар, чәй шикәрле – менә нинди бәхет монда! Мин, Орски ягындагы ач хәяттән чыгып, шушы бәхеткә килеп ирештеммени? Дәвамлы бәхетләр булсын инде! Күп кешеләр белән күрештем. Күргән берсе: «Үлгән дип кайгырган идек», – диләр. Куанып, күңелләнеп йөрим. Бу бәхет дәвамлы, хәерле булсын инде, дип тели-тели йөрим. Илтифатлар, хөрмәтләр арасында тирбәләм. Шөкер!

Кич мөселманнар белән урысларның катнаш концерты булды. Яхшы гына үтте.

Бер башкорт хатынының милли киемдә чыгып биюе, Габдерәхимнең җыры, ике марҗа кызының гопакка биюе, кыллы музыкалар ошады миңа. Кантон Теләүбирдин белән таныштым.

9ында иртә чәйгә, маен мул итеп тотып, белен пешереп бирделәр. Бик һәйбәт булды.

«Менә мин, сәхнә эшләре белән маташмый, драматурглыкны гына алга җибәрә алсам икән. Мине чынлап рухландыручы шул гына!

Типографиягә кереп, газетада басыла торган шигыремнең корректурасын карадым. «Яшь өметләр»не хәрефкә тезүче яшь өмет, ләкин хәреф кассалары арасында саулыгын югалтучы Ибраһим Әгъзәмовка дустанә тәнбиһләр *(кисәтүләр)* ясадым.

11ендә җомга булу мөнәсәбәте белән, пилмән пешерттем. Бер табак пилмәнне ялгыз үзем ялтыраттым.

Репетиция булды. Исеме «Уен» булса да, эше авыр, дуңгыз, санаигы нәфисәнең *(нәфис сәнгатьнең)*. Бүген генеральный, үз пьесаларым куйганда канәгатьләнә алмау минем бер авыруым инде. Уйнаучыларны да аптыратып бетерәм. Ләкин хакыйкатьтә дә артист булып яратылган рухлар юк шул. Саҗидәсе тагы вәхшилеге белән җанны газаплый. Ирләр кулы тиюдән дә курыккан кызларның гыйффәтләрендә шигем генә арта минем. Әтәчтән качкан бозык хатын исемә төшә.

12сендә спектакльдә халык күп булды. Постановка яхшы гына чыкты. Темәснең талантка фәкыйрьлеген, бәгъзе бер беленерлек ноксаннарны хисапламаганда, муаффәкыятьле *(уңышлы)* үтте. Үз күңелемдә иң шәп тоелган җире – толпа уен күренеше булды. Соңыннан, «Автора!» дип чакыру көчле генә булган хәлдә, чыкмадым. Алар күңелемне күрергә тырышсалар да, уенның ни дәрәҗә чыкканын сизәм бит. Аның нәрсәсе белән мактаныйм.

14ендә көн буе буран, кар ява. Көнне күбрәк фатирымда – язып үткәрәм.

Кичкә таба Вәкил килеп утырып китте. Гайфулланың гармуны бар. Озак гармун уйнап утырдык. Бүген Юлык Әхмәт тә азрак уйнап киткән иде.

Кич фатир хуҗаларымның туганнарыннан Нәфисә ханым, Рамазан, Садыйк исемле яшьләр килделәр. Бу күңелле генә кешеләр белән үзләшеп алып, кичне күңелле үткәрдем. Лото уйнадык, чәйләр эчтек. Нәфисә ханымны яратып калдым.

Миңа зур поклонник булган халык картларыннан Хаҗбәк карт вафат булып калган. Бу кышкы вабаның корбанын кызгандым. Күңелле егет, карт иде. Әрәм булды.

Ваба, тифлар йога күрмәсен инде. И-и-и, кемгә мөрәҗәгать итим? Һәрхәлдә, сау гына була күрим. Чөнки авырып кеше өстендә ятасым да, үләсем дә килми.

17сендә базар көн. Базардан 17 кадак ит, кәрәсин сатып алдым.

Мозаффаров аркылы Мортаза абыйның хаты иреште. Өйнең саулыгын белдем. Бергә туып, бергә үсеп, бергә укыган, бергә күп хатирәләр калдырган туганым Габдулла (Әхмәтгәрәй абзый угылы) вафат, ди. Нык тәэсир итте. Чиксез кызгандым. Нинди тормышлар белән яшәгән кеше, нинди хәлгә төшеп гомерен тәмамлады. Мескен Габдулла! Кызганыч Габдулла! Бергә уйнап үскән якын туган! Гафу ит мине!

Фатирым яхшы, ләкин бик аулак түгел, язу эшләремә зарары тия. Темәс Әсмалары тиф белән авырый башлады. Башка фатир юк. Йогуыннан сакласын инде табигать!

20сендә иртә чәйгә күп итеп кабартма пешереп бирделәр. Чак ашап беттем. Бүген якшәмбе, бәйрәм итәләр. Вәкилләргә кереп чыктым. Кәмилә бәлеш ясап йөри

иде. Аннан наробраз бакчасында Гайфулла Зөбәиров, Хөсәен Морадшин, Ибраһим Әгъзәмов, Исмәгыйль Абзалов, Әвәлбаевлар – килгән типография служащийлары белән озак утырдым. Аннан Гайфулла белән итекче Бариларга бардык. Озак утырып чыктык. Репетиция ясадык. Сусап кайтып, шикәрләп чәй эчтек.

Без эчәбез сөтле чәй, сөткә шикәр катканын;
Без сөябез кызларның бит алмасы батканын.

Сөюен сөябез дә, никах сәгатьләре сукмый бит! Чәчләр чәчкә бәйләнми, күрәсең...

21ендә репетиция ясадык. Темәс яшьләре арасында җаныма ямьнәр бирүче хезмәтемне дәвам иттерәм. Артист та түгелмен, режиссерлыкта көч юк; ләкин Темәстә миннән артыграк бер талант юклыктан, халык шәп дип уйлый. Йолдыз караңгы төндә яктырак җана бит. Югыйсә зуррак талантлар янында шөребе какшар иде малайның. Менә мин, сәхнә эшләре белән маташмый, драматурглыкны гына алга җибәрә алсам икән. Мине чынлап рухландыручы шул гына!

«Мәргубә»мне Маһитаб туташ Мостафина уйный, Чүчпәрәне – Маһруй. Саҗидә Госмановага роль бирмәдем. Боларның кешечә кыйлануына рәхәтләндем, каприз юк. Бармак белән кагылу түгел, кочаклауга да күтләк хатыннар төсле кылану юк. Фәкать туганнарча, гыйффәтчә. Долой, Саҗидә.

Шәриф Корбангалиев ямьле «гармунчы егет» булып чыкты. Матур гына тип бирә. Шәхесемә иткән хезмәтләре белән дә күңелемнең мәхәббәтен казана. Яшә, егет! Миннән дуслый сиңа!

23ендә спектакль яхшы чыкты. «Ярты алма»дагы үлемне бәгъзе бер борчулар аркасында ноксанрак чыгардым. Шулай да икенче картина бик матур булды бугай. «Әмәти улы Мәмәти» һәм «Чүчпәрә туташ»та Мәмәти роле белән алкыш казандым. Өзлексез көлке астында уйнап, пәрдә төшкәч, ике рәт сәхнәгә чыгардылар. Кулда күтәреп йөрттеләр. Автор һәм артист өчен күңелле эш. Сәхнә артына кереп, хосусый тәбрикләрнең «чукындырып чыгардың» кебек иң самимиларын ишетергә туры килде. Садыйкка кереп кундым. Озак сөйләшеп яттык.

28ендә кичкә таба «минем каршымда сөйкемсез» егет, спирт алып кайтып, һич рөхсәтсез минем якта сиптерә башлады. Сплав эшчеләренә бирелгән спиртны эчә. Хуҗам, карт башы белән, шул компаниягә кушылды. Гайфулла атасы белән кара-каршы торып эчә. Әллә кемнәр килде. Кругом исерекләр арасында утырам. Үземне теге кеше үтереп кыстый. Чыгып китсәм, нәрсәләремне пычратырлар, туздырырлар, дим. Аларның безобразный компанияләренә тагы катышасы килми. Ахыр чыгып киттем. Картинаның ямьсезлеген күтәрә алмадым.

Кич белән кайтканымда бүлмәм исереп җыгылган, пычранып беткән, сүгенеп яткан кызганыч мәхлуклар белән тулы иде. Кулны селтәп чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Вәкилләргә бардым. Чәйдән соң Вәли скрипка, Әсма ханым гармун уйнап рухларны бәйрәм иттерделәр. Яшь кенә ир белән хатынның парлап уйнап утыру рәвешләрен сокланып, иркәләп, яратып карап тордым. Икесе дә музыкант, икесе дә бик матур, икесе дә әйбәт. Галиябану белән Хәлилгә тыңлап, матур сүзләр әйттем. Вәкил биеде. Вәли иптәш җырлады. Матурлык, ямь балкыды. Матур тойгылар алдым. Шәриф Корбангалиев янына кереп кундым.

29ында Вәкилләрдә чәй эчтек. Урамга чыккач, Нәфисә ханым Дасаева очрап, фатир хуҗам Габдулла абзыйның кичәге эчү белән җанып үлеп калганын, Гайфулланың чак котылганын хәбәр биреп, котымны алды. Менә зур уңайсызлык астында калынды...

Өйгә кайтсам – җылаш. Чыр-чу, хәсрәтләр арасында калдым. Күңелле түгел. Габдулла абзый минем якта үлеп, кара көеп ята. Әле дә Гайфулла үлмәгән дип куанам.

Мирхәйдәр Фәйзинең бертуган абыйсы Мортаза Мостафа улы Фәйзуллин

Үз бүлмәмдә шундый хәл булуга көенәм. Нәрсәләремне болгатмаска куштым да, Каюм Малаев иптәшнең чакыруы белән, аларга бардым. Көнем Малаевларда үтте. Матур, җиһазлы өйләрендә шикарный приборларына зәвыкланып, озак чәй эчтек. Кайтып җеназаны озаттым да кире аларга бардым. Аш, соңыннан чәй белән шәпләп сыйладылар. Каюмның кәләше күңелле хатын икән, бик хөрмәт күрдем.

Сакмар ташый, Каюмнарның өеннән су өсте бик күңелле күренә, бозлар ага. Ямьле булды. Урамнан үтеп барганда, начгарнизон Дасаев иптәш кычкырып чакырып алды. Чәй эчертеп чыгардылар.

Өйгә кайтып, бүген дә Шәрифтә куначагымны әйтеп чыктым. Күңелсез анда, җылыйлар. Эчмәвем, хәтта тартмавым да хакында мактаулар, рәхмәтләргә күмелдем. Хатыннарның хөрмәте астында мөтәфәхиррәнә *(горурланып)* утырып чыктым.

Урамнарда йөрдек. Көн күңелле. Сакмар арта. Матур, хатирәле йөрешләр булды. Шәриф Эстәрле сәхнәсе хәлләрен сөйләде. Хәбибулла янында утырам. Вәкил белән гулять иттек. Аннан аларга кердек. Шәрифтә озак утырдык. Гармун уйнадык. Шәрифкә кереп кундым.

> **«Ачыккан дусларга бер сынык икмәк белән булса да ярдәм итеп куандыра алмау белән нинди бәхетсез мин!**

Бүгенге көн күңеллелек белән күңелсезлекләр арасында чайкалып йөреп үтте.

31ендә иртә чәйгә кабартма пешерделәр.

Кичә яшьләрнең гомуми җыелышы булып, мин, Шәриф Корбангалиев, Вәкил һәйәт әгъзалары булып сайлануны көнендә язарга онытканмын. Бүген шул һәйәтнең минем фатирда җыелышы булды. Хәмзә Батыршин да килде. Җыелыш беткәч, чәй эчердем. Нәфисә ханым Дасаева да килде. Бик күңелле утырдык. Яшьләрчә, язча җиңел үтте. Флирт уйнадык. Кичне җиткереп киттеләр. Иртәгә репетиция башларга булдык.

Бари кодадан итекне табанлатып алдым. Газиз тәпиләремдә тузган иде.

Матур гына, сөйкемле кыз Мөнәүвәрә,
Мөнәүвәрә белән генә мин әүвәрә;
Матур тавышы, күбәләктәй рәвеше белән
Башларымны әйләндерде, менә бәла!

1922 ел, апрель. Темәс

4ендә иртә чәйгә кабартма пешерттем. Пасха бәйрәме шәрәфенә шикәр сибеп печеньеләр пешерттем.

Кич Вәкил, Кәмилә Зәйнелгабитдиноваларны, Хәмзә, Гөлҗамал, Кодрәт Батыршиннарны, Шәриф Корбангалиев, Мәрдан Яушев, Хәсән Хәлиуллиннарны, Гайфулла белән Әсма ханымны кунакка чакырдым. Хәлвә пешертеп сыйладым, малай! Күңелле булды. Яуш гармун уйнады, җырлар, биюләр, флирт, почталар, башка уеннар булды.

Ничек чыгар инде уеннар? Мондый халык арасында эш итү җиңел түгел! Йөрәк түзми бит, дәрт чыдатмый...

Юлык Хәсән миндә кунды. Күп сөйләштек. Ай, мескен, Мәүлетдин Гаширов ачтан үлгән, ди. Никадәр кызгандым, никадәр үкендем. Шундый ачыккан дусларга бер сынык икмәк белән булса да ярдәм итеп куандыра алмау белән нинди бәхетсез мин! Мәгъсум Мәүлетдин! Ямьле Мәүлетдин! Егет Мәүлетдин! Дус Мәүлетдин! Матур тавышың белән рухларымны азыкландырган «татар баласы»! Синең әрәм булуың белән мин мәңге кайгылы...

Шәрәф Биктин угрылыкта тотылган, ди. Советка чакырып, моннан соң энә урласа да, кыйналып үтереләчәген игълан иткәннәр, ди. Ах, бәдбәхет ачлык! Һәлак иттең адәм баласын! 19 яшьлек кенә ямьле, мәгъсум Мәүлетдиннәр ачка үлеп китә, 18



«Ядкәр» – төрле кешеләр М.Фәйзигә шигырьләр, рәсемнәр, теләкләр язган блокнот. Юлык. 1921-1922 нче еллар

яшьлек кенә матур рухлы, шаян, күңелле, гөлдәй җанып, яшендәй яшьнәп торган Шәрәф кебек егетләр, җан саклар өчен, угрылыкка ябыша. Тәмам аптыраган халык бу «гөнаһсыз гаеплеләр»не кыйнап үтерә…

Шәрәф! Юлыкта торганда, гел яныңа барып, яшь егет йөрәгеңнән сирпелгән рух тамчылары белән күңелемне сугарган мин, сине угрылыгың белән дә, кеше үтерүең белән дә гаепләмим. Син минем каршымда «ямь букеты», «шәрәф» көе торачаксың! Әрәм булырсыңмы? Йөрәкләремне җандырып әрәм булырсыңмы, дустым! Ачлык корбаны итмәс өчен, халык тарафыннан: «Шундый гөнаһыңны, шундый зимагур малайны яклый бит», – дип әйттертеп, вөҗданны бәйрәм иттерер өчен нинди генә әмәлләр табыйм?!

Мин Юлыктан киткәндә: «Син барында күңелле иде, син киткәчтен нишләрбез?» – дип җырлап, күңеленең хөрмәтен белдерә белгән ямьле Мәүлетдин үлде. «Син мине яратасың, ахры, мин дә сине яратам бит!» – дип мине куандыра торган сөекле Шәрәф Яр якасында. Авыр! Шәрәф!

Бүлермен, бергәләрмен мин синең кайгы вә аһыңны.
Сиңа дошманлык итмәм мин, алып күзгә гөнаһыңны!

12сендә «Яшь колхозниклар союзы»ның җаваплы секретаре Фәйзулла Биишев IIдән, 1 майга куячак спектакльләре өчен мәгънәви ярдәм сорап, отношение килде. Яшьләр союзы күңелем каршында хөрмәтле булганга, ярдәмнәр вәгъдә иттем.

«Авыл бәйрәме» өчен бер миллион авторский алдым.

14ендә базар. 1 500 000 сумга ун кадак ит алдым да, башка нәрсәләр алырга кесәсе такырайгач, шома гына шуды малаең.

Юлыктан Хөсәен килгән икән. Аның сәүдәсе янында байтак тордым. Ай, байгыш, Әсгать тә үлгән, аның өчен дә йөрәгем җанды. Шаян, шук, үткен бер малай иде. Кечкенә артист Борһанның үлүе дә бер хәсрәт. Әрәм булган бер талант. Рухың рәхәттә тирбәлсен, мәгъсум ачлык корбаны!

15ендә «Кызыл Урал»ның һәйәте тәхририя *(редколлегия)* әгъзасы булуым хакында рәсми язу алдым. Качак малаең! Алла сакласын, баш мөхәррир булып китә күрмим, аннан бөтенләй урысча хәбәрли башлармын.

Бүген ураза башланды. Мин туганнан бирле әнидән башка беренче ураза. Апай үзе генә тотар инде, байгыш. Аһ, әни исләремнән бер дә чыкмый! Аны уйлап бик җыш җылыйм. Җиһанның һичбер ямьнәренә алыштыру мөмкин булмаган бер вөҗүд булган икән ул минем өчен. Ул мине бик яратты, мин аны бик яраттым. Ул хәзер бернәрсә дә сизми, әмма мин аны гел сагынам. Аны мәмнүн *(шат)* итә алмавымны уйлап, бөтен вөҗүдем *(барлыгым)* кашый. Ни үкенеч!

18ендә – 1 май бәйрәме. Көн кодрәт белән матурланган. Төшкә кадәр газетага мәкалә әзерләп, өйдә мәхбүс утырдым. Гәрәй Шаһиәхмәтев килде. Яраткан дустым бит ул минем, куандым. Тик озак утырырга вакыты туры килмәде.

Аннан соң Гайфулланың дименә җиңелеп, йөрергә чыгарга күндем. Мин, ул, Ибраһим Әдһәмев – өчебез җиңел киемнәр белән генә Ягалча тавына киттек. Яхшы ук җырак кына, биек тауның башына менеп озак яттык. Түбәсеннән уникe авыл күренеп торган тауда, карлар ашап, утлар җагып, җырлап-биеп, умырзая җыеп, күңелле вакытлар үткәрдек. Ямьле йөреш булды. 1 май көненә беленерлек бер эз калдырылды.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Шагыйрь тормышында Сосна Пүчинкәсе

Ләйлә Мөхәммәтшина

Мәгълүм булганча, олуг Тукаебызның әнисе Бибимәмдүдәгә Казан артының шушы ерак авылына килен булып төшәргә язган була. Бибимәмдүдә, ире Мөхәммәтгариф үлгәннән соң, кечкенә улы белән әтисе йортына кайта. Болай да ачлы-туклы гына яшәгән, ишле балалы бу гаиләдә Бибимәмдүдә озак кала алмый. Икенчедән, муллалар, бер-берләре белән тыгыз бәйләнгән булып, еш кына элемтәләрен кыз бирү-кыз алу белән дә ныгытканнар. Шулчак Сосна Пүчинкәсе авылындагы тол калган Шакир мулла Өчилегә яучы җибәрә. Ашарына такы-токы гына булган күп балалы әлеге гаиләдә үги ананың авыр карашыннан басылып яшәгән Бибимәмдүдәгә бу тәкъдимне кабул итүдән башка чара калмый. Никах мәҗлесе Өчиледә, әтисе Зиннәтулла йортында 1888 елның 22 декабрендә үтә. Мөхәммәтшакир Бибимәмдүдә өчен 30 тәңкә мәһәр бирә.

Хәзрәткә инде бу вакытта – 69, Бибимәмдүдәгә исә 23 яшь була. Тумышы белән хәзерге Әтнә районының Мөндеш авылыннан булган Шакир мулла да Кышкар мәдрәсәсендә белем алган. Димәк, ул шушы мәдрәсәне тәмамлаган Зиннәтулла хәзрәтне дә, Мөхәммәтгариф мулланы да яхшы белгән.

Бибимәмдүдә, булачак иренең Габдуллага мөнәсәбәте нинди булуын белмәгәнлектән, улын вакытлыча Кушлавычта Шәрифә исемле карчыкта калдырып тора. Бер кибән арыш хакына кечкенә Габдулланы алып калган Шәрифә карчыкның тулы исеме

«Сосна Пүчинкәсе» Рәссам В.С. Антонов

Мөхәммәди кызы Шәрифәҗамал була һәм ул 1895 елда 77 яшендә дөньядан китә.

Шәрифә карчык турында Г.Тукай ишеткәннәренә таянып язган. Соңыннан шагыйрь: *«Ул карчык үлгән инде. Алла аңар рәхмәт итсен»*, – дип язып калдыра.

Яңа иренә беркадәр ияләшкәч, Бибимәмдүдә аңардан баланы үз янына алырга рөхсәт сорый. Мулла риза була. Булачак шагыйрьнең өч яшьлек чагыннан исендә калган бердәнбер бәхетле көне күз алдына килә: *«Үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә»*.

Ләкин булачак шагыйрь ана назын туйганчы татып калырга өлгерә алмый: 1890 елның 18 гыйнварында аның әнисе үлә. Бибимәмдүдәнең җәсәден Сосна Пүчинкәсе зиратында җир куенына иңдерәләр. Габдулла, өч яшь тә тугыз айлык сабый килеш, тома ятим булып кала. Менә шушы сабый хәтеренә таянып, ул әнисе белән мәңгелеккә хушлашу мизгелләрен үзәк өзгеч бер моң аша искә ала: *«...Мин монда, әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, ялана-як, яланбаш хәлемдә капка астыннан үкереп җылый-җылый җөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» – дип шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне (искә алганымны) язамын.*

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сосна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле карьясендәге анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән».

- 1819 елда туган Мөхәммәтшакир хәзрәтнең Бибимәмдүдәгә кадәрге хатыны яки хатыннары турында мәгълүматыбыз әлегә юк.
- 1888 елда ул **69 яшендә 23 яшьлек Бибимәмдүдә белән никахлаша.**
- Мөхәммәтшакир хәзрәт, Бибимәмдүдә 1890 елда вафат булганнан соң, **Әсмабикә Касыйм кызына өйләнә**.
- Аларның Закир, Гамилә һәм Фатыйх исемле балалары туа.
- Улы **Фатыйх дөньяга килгәндә хәзрәткә 81 яшь була**.
- Әсмабикә вафат булганнан соң, Мөхәммәтшакир хәзрәт Смәел авылыннан **Фатыймага өйләнә**.
- Фатыйма абыстайдан соң Сосна гүзәле Мәүлидәгә өйләнә.
- 1909 елда **90 яшен тутырган хәзрәтнең Шамил исемле улы туа.**
- Мөхәммәтшакир 1916 елда 97 яшендә дөнья куя.

Зиннәтулла хәзрәт һәр гыйнвар аенда, озын юлны якын итеп, вафат булган кызының каберен зиярәт кылырга барган. Барган саен, авыл мулласы Мөхәммәтшакир йортына кагылып, хәл-әхвәл белешкән. Элекке кияве аны ачык йөзе белән каршы алган, чәйгә дәшкән. Мөхәммәтшакир мулла, шактый олы яшьтә булуына карамастан, яшь хатыны тәрбиясендә җир җимертеп йөргән.

Мөхәммәтшакир Фәйзуллин, Бибимәмдүдә үлгәннән соң, Әсмабикә Касыйм кызына өйләнә. Аннан Закир (1894), Гамилә (1897), Фатыйх (1900) исемле балалары туа. Әсмабикә дә вакытсыз үлеп китә, аның балаларын яңа хатынга – Смәел авылыннан Фатыймага үстерергә туры килә. Үги ана балаларга карата мәрхәмәтле була.

Фатыйма абыстайдан соң 80 яшьтән узган Шакир хәзрәт Сосна авылыннан Мәүлидә исемле яшь хатын белән никахлаша һәм аларның 1909 елда Шамил исемле уртак балалары туа. Ул 1942 елда сугышта һәлак була. Шамилнең 1941 елның 29 августында кызы Сәйдә туа. Улы Равил 1938 елгы, аның 4 баласы туа, ул 1991 елда үлә. Бүгенге көндә Сәйдә Казанда яши, авылына кайткалап йөри.

Сосна Пүчинкәсе авылының соңгы указлы мулласы Габделгалләм Мәннанов Шакир хәзрәтнең Бибиәсма абыстайдан туган кызы Гамилә белән никахта була. Галләм

мулла 1934 елда 5 елга Себергә сөрелә. Сөрелгәнче, Галләм белән Гамиләнең 4 баласы дөньяга килә: Нургаян (1924) Яшел Үзәндә яшәгән. Кавый (1926) очучы була, 1941 елда үлә. Кызы Мөкәррәмә Мәскәү тирәсендәге Березники шәһәрендә яшәгән. Дүртенче баласы Рәфкать исемле була. Галләм мулла Себердән 3,5 елдан кайта. Аның аяклары авырта. Кайткач, Нәзифә исемле кызы туа. Галләм мулла 1938 елда вафат була, әтисе үлгәндә Нәзифә 6 айлык булып кала. Ул абыйсы янына Яшел Үзәнгә китә, шунда тормышка чыга. Нәзифә озын-озак еллар дәвамында шушында абыстай вазыйфаларын башкара. Фатыйхның улы Мәхмүт 1996 елда төзелгән мәчетнең аен ясатып куя. Әлмәт шәһәрендә яшәүче Рәфкать улы Фәрит тә мәчеткә матди ярдәм оештыра. Әлеге мәгълүматлар, Нәзифә һәм Сәйдә абыстайларның истәлекләренә таянып, Россиянең мәгариф отличнигы Камил Габделәхәт улы Заһидуллин тарафыннан язып алына. 2018 елда Сосна Пүчинкәсе авылының 150 еллык юбилей чараларын үткәрүдә дә ул башлап йөри.

Ярты гасырлык тарихы булган Сосна Пүчинкәсе авылы – сөекле шагыйребезнең сабый чак эзләрен саклаучы, әнисе Бибимәмдүдәнең җәсәден үз күкрәгендә саклаучы авыл бит ул!

Тукай тормышының Сосна Пүчинкәсе чорын шактый еллар үткәч тә искә ала, алар турында уйлана. *«Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереӊ ташы, Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы...»* – дип мөрәҗәгать итә ул әнисенә, күп еллар узгач. Бибимәмдүдә абыстайның кабере өстенә Г.Тукайның тууына 100 яшь тулган көннәрдә архитектор Р.Билалов проекты буенча эшләнгән мәрмәр таш куелды, кабер төзекләндерелде. Кабер ташы алдына куелган кара гранит ташта шагыйрьнең нәкъ менә шушы үзәк өзгеч моңлы шигъри юллары язылган.

Тукайның Сосна Пүчинкәсе авылына килүе хакында Балтач районының «Хезмәт» газетасында Пермь краенда яшәүче Илдар Зиннуровның 2009 елда басылган «Тукай янә Сосна Пүчинкәсендә» исемле мәкаләсен тәкъдим итәм:

«Бәләкәй Тукайга Балтач җирендә, Сосна Пүчинкәсе авылында урнашкан үги атасы Шакирҗан хәзрәт йортында бик аз вакыт кына яшәргә туры килә. Минем әти ягыннан Сәгъдәтбану әбием – Шакирҗан хәзрәтнең бертуганының кызы. Ул, Габдулладан берничә яшькә генә олы булуына карамастан, аның белән уйнап, аңа күз-колак булып торган. Әбиемне бик яхшы хәтерләмәсәм дә, аның сөйләгән кайбер хатирәләре исемдә.

Шакирҗан хәзрәт яшь хатыны Бибимәмдүдәне өзелеп яраткан һәм ихтирам итеп яшәгән, аңа йорт эшләрен башкарырга рөхсәт бирмәгән. Ә хатыны, үз чиратында, аралашучан булган, бәйләгән, чиккән, теккән. Авылда аңа, яратып, яшь абыстай, дип эндәшкәннәр. Пөхтә итеп милли киемнәрдән йөргән, урамда аның ак перчаткалар киеп йөрүе авыл җирлеге өчен гаҗәп күренеш булган. Кечкенә Тукай да җыйнак киенеп йөргән. Ак сызыклы зәңгәрсу күлмәген аеруча яратып кигән. Өстеннән кара төстәге җиңсез күлмәген, ә башыннан кара бәрхет түбәтәен төшермәгән. Габдулла шау-шулы уеннарны яратмаган, яшьтәшләре белән аз аралашкан. Яшел хәтфә үлән өстендә уйчан гына еракка карап, хыял диңгезендә йөзгән мизгелләрне Габдулла бигрәк тә яраткан.

Әнисенең вафатыннан соң, кечкенә Габдулланы үги әтисе йортыннан алып китәләр. Ләкин, үсә төшкәч, Сосна Пүчинкәсе авылына ул тагын бер кайта. Әнисенең каберен иң элек Сосна авылыннан эзли, таба алмагач, Сосна Пүчинкәсенә килә (шуңа күрә авылга, тарантаска утырып, Көшкәтбаш ягыннан керә). Әнисенең кабере янында икәнен белгән әбием, бабам Гыйләҗ белән, аны чәйгә дәшәләр. Габдулла Тукай кергән йорт инде күптәннән юк...

Сосна Пүчинкәсе авылына ул тагын кайтканмы? Белмим. Ләкин Балтач җире Бөек Тукай биографиясендә аерым урын алып тора». ■

безнең мирас №4 апрель 2020

ИСЕМЕҢ МАТУР, *кемнәр куйган?*

Хөрмәтле остазыбыз, филология фәннәре докторы, профессор, төрки-татар ономастика мәктәбенә нигез салучы, татар исемнәрен дөньяга танытткан мәшһүр галим Гомәр абый Саттаровның «Татар исемнәре» сүзлегенең кабат нәшер ителүе төрки-татар дөньясы өчен зур куаныч булды.

Халкыбызның исемнәрендә дөньяны күзаллау, халык традицияләре, туган телгә мәхәббәт чагыла. XI гасырга караган Йосыф Баласагуни «Котадгу билик» исемле әсәрендә болай дип язып калдыра: *«Дөнья фани, Үлә һәрбер тумыш зат, һәрберсеннән кала яхшы-яман ат»*. Анда кешенең исеменә зур мәгънә йөкләнелә һәм ул поэмада гел игътибар үзәгендә тора. Татар исемнәренең саны бүгенге көндә 20000нән артып китә. Шуңа күрә тарих төпкелендәге исемнәрне барлап, теркәп, аларны эзлекле фәнни яссылыкта тикшергән, шулай ук исемнәребезне үткән һәм бүгенге көн ноктасыннан якын килеп өйрәнгән фәнни хезмәтләргә ихтыяҗ үзен һәрдаим сиздереп тора.

Татар исемнәрен фәнни өйрәнү эше XIX гасырның икенче яртысыннан башлана. Бу эштә В.В.Радлов, В.К.Магницкий, Н.И.Ашмарин, В.В.Вельяминов-Зернов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәрев, Г.Тукай һ.б. үзләреннән зур өлеш кертәләр. 1863-1866 елларда В.В.Вельяминов-Зернов тарафыннан нәшер ителгән «Исследование о касимовских царях и царевичах» һәм «Источники для изучения тарханства, жалованного башкирам русскими государями» дигән хезмәтләрендә гаять бай төрки-татар исемнәрен тәкъдим итә. XIX гасырның 70 нче елларында Казан университеты каршында «Ар-



«Исем. Балаларга күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» (Ахун Бендуков, 1899)



Бертуган Кәримовлар тарафыннан чыгарылган «Унбер Әхмәт исемнәре» сүзлегенең тышлыгы (1914)

хеология, тарих һәм этнография җәмгыяте» оештырыла. Шул елларда В.В.Радлов җитәкчелегендә туган як ономастикасы түгәрәге оештырылу Казанда исемнәрне өйрәнүне киңәйтүгә китерә. Бу түгәрәктә Н.И.Золотницкий, Н.Ф.Катанов, Н.И.Ашмарин, И.А.Износков, В.К.Магницкий, татар галимнәреннән Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәрев эшчәнлекләрен киң җәелдереп җибәрәләр. Шул рәвешле, XIX гасырның 80 нче елларында Казан ономастика мәктәбенә нигез салына. Ш.Мәрҗанинең 1897 елда дөнья күргән ике томлык «Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә, Болгар һәм Казан тарихыннан тыш, бик күп ономастик материал китерелә. Ш.Мәрҗани бу хезмәтнең икенче кисәгендә борынгы кеше исемнәрен үз эченә алган татар шәҗәрәләрен тәкъдим итә. К.Насыйриның «Зөя өязе авыллары» хезмәтендә бирелгән шәҗәрәләр, эпитафияләр, кульязмалар тарихи антропонимика өчен кыйммәтле чыганак ролен үти. Г.Әхмәрев 1903 елда Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография хәбәрләре» журналының 2 нче санында «Мишәрләр теле һәм халкы» дигән мәкаләсендә мишәр диалектларында кулланылган кеше исемнәренең кайбер үзенчәлекләрен күрсәтә. Бу мәкалә татар исемнәрен җирле үзенчәлекләр аша өйрәнүдә әһәмиятле урын тота.

XIX гасырның уртасында, гарәп-фарсы исемнәрен пропагандалау максатында, төрле кечкенә китапчыклар дөнья күрә («Исме Аллаһы Тәгалә әл-Хәсәни» [1848], «Авраде Фәтхия» [1865]). Бу сүзлекчәләрдә балаларга мөселман исемнәре бирергә кирәклегенә басым ясала. Җыентыкларда Аллаһы Тәгаләнең 99 исеменең мәгънәсе бирелә.

XX гасыр башында шундый ук юнәлештәге сүзлекләр чыгару эше дәвам итә. Ш.Т.Хәмидуллинның «Исемнәрнең бәгъзеләрене дөрес язу» [1899], Ахун Бендуковның

«Исем. Балаларга күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» [1899], бертуган Кәримовлар тарафыннан чыгарылган «Унбер Әхмәт исемнәре» [1914] сүзлекләрендә дә төрле исемнәр тәкъдим ителә. Мисал өчен, Ахун Бендуковның «Исем. Балаларга күркәм исем бирергә киңәш һәм укучы сабыйларга һәдия кылырга муафыйк китап» сүзлегендә автор, исемнәрне генә биреп калмыйча, аларны классификацияләргә дә омтыла. Ул исемнәрне болай бүлә: 1. Мәгънәсе яхшы, шәригать кануннары нигезендә язылган исемнәр, җиңел исемнәр: Адәм, Идрис, Әдһәм, Әхмәт, Асат, Ислам, Исмәгыйль, Исхак, Ибраһим, Асаф, Әснәф, Ильяс һ.б.; 2. Ике кәлимә булып, мәгънә җәһәтеннән изафә җаиз шәригатьчә күркәм исемнәр. Бу исемнәрдә Аллаһының бер исеме шәригатьчә бирелгән: Габдулла, Габдерахман, Абдулла, Габдерәхим, Габделгани, Габделхәлүк, Габделгалләм, Габделбари һ.б.; 3. Ике кәлимә булып, дин хафизына изафә белән булган исемнәр, изафәсе мәгънә җәһәтеннән җаиз шәригатькә мөнхи булмаган исемнәр. Моның кебек әүвәл заманда мәдх касты белән олуб истималь улунмуш: Шәмсетдин, Нәҗметдин, Сираҗетдин, Җамалетдин, Кемалетдин, Кыяметдин, Садретдин, Зәйнелетдин, Фәхретдин, Әкъмәлетдин, Гарәфетдин һ.б.; 4. Хәзрәти Мөхәммәд (с.г.в.) дәверендә булмаган, Иран һәм Туран халкының мөселман булуы нигезендә кулланылган исемнәр: Әхмәтгәрәй, Әхмәтсадыйк, Мөхәммәтҗан, Хаҗигәрәй, Мөхәммәтфатыйх, Мөхәммәтзәки, Вәлиәхмәт, Зарифҗан, Нурмөхәммәт; 5. Хәзрәти Адәмнән хәзрәти Мөхәммәдкә (с.г.в.) кадәр булган исемнәр: Апуш, Сиамак, Конак, Хам, Сам, Яфис, Ям, Кантур, Лауз, Иран, Әрван һ.б.; 6. Хәзрәти Мөхәммәдтән (с.г.в.) соң мәшһүр исемнәр: Хишан, Һарунрәшит, Мәдхи, Гайбулла, Мәрван һ.б. Кыз балаларга күркәм исемнәр: Әминә, Асия, Бакирә, Сания, Салисә, Җәмилә, Хафизә, Хәмидә, Хәмдия, Хәят, Һава, Хәдимә, Рабига, Разия, Рәхимә, Заһидә, Зөһрә, Зәйнәп, Зәйтүнә һ.б. [Бендуков, 1899: 12].

30-50 нче елларда татар исемнәре буенча сүзлекләр басылмый диярлек. Бары тик XX йөзнең 60 нчы елларында гына тел белемендә ономастикага карата кызыксыну уяна һәм бу күренеш татар антропонимикасын да җанландырып җибәрә.

60 нчы еллардан башлап татар антропонимикасы аерым тармак булып үсеш ала башлый һәм фәнни яктан тирәнәя. Һ.В.Йосыпов, Г.Ф.Саттаров, Р.Х.Субаева, Ф.С.Хәкимҗанов, М.А.Җәләлиева һ.б.ның хезмәтләрендә хәзерге татар антропонимикасына нигез салына.

Татар халкының этногенез мәсьәләләре яссылыгында төрки-татар ономастикасын, диалектларын һәм лексикасын өйрәнү буенча фәнни-тикшеренү эше Г.Ф.Саттаров тарафыннан оештырылган Казан ономастика мәктәбендә алып барыла. Аеруча региональ антропонимияне – аерым бер төбәккә караган, халык телендә кулланылышта булган кеше исемнәрен, кушаматлар һәм фамилияләрне өйрәнү-тикшеренү эшләре алып барыла. Бу юнәлештә эшләүче Х.Ч.Алишина, Г.Р.Галиуллина, Ф.Г.Ваһапова, Ф.С.Сәлимҗанова, Г.Ф.Тимканова, Л.Х.Айтбаева, М.З.Вәлиева кебек галимәләрнең хезмәтләрендә аерым бер урынчылыкка караган исемнәрне туплап, аларны тарихи-лингвистик аспектта яктырту максаты куела. Тикшеренүләр XX гасыр антропонимик берәмлекләрен анализлау аша татар антропонимик системасын алга таба җентекле өйрәнүгә гаять әһәмиятле фәнни юл салалар.

Чыннан да, татар исемнәрен өйрәнүнең чал тарихы бар. Әлеге эш бүгенге көндә дә дәвам итә һәм дәвам ителергә тиеш, чөнки исемнәребез халык хәтерен, тарихын саклыйлар. Остазыбыз Гомәр ага Саттаровның 60 нчы елларда башлаган эшенең саллы нәтиҗәсе булган «Татар исемнәре» сүзлеге, үткән буын белән хәзерге буынны бәйли торган татар исемнәренең бөтен матурлыгын, затлылыгын, мәгърурлыгын күрсәтеп, туплап, хәзерге көн укучысына ирештерә алды.

Гүзәлия Хаҗиева,
филология фәннәре докторы ■

Ирек Шәрипов: *«Мирасыбыз көндәшлеккә сәләтле!»*

(Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры ***Ирек Илдус улы Шәрипов*** *белән* ***Фирдәвес Зариф*** *әңгәмәсе)*

– Ирек Илдусович, күпмилләтле республика шартларында Халыклар дуслыгы йортының төп эшчәнлеге нәрсәдән гыйбарәт?

– Дуслык йорты – җәмәгатьчелек белән хөкүмәт вәкилләре бер урынга җыела, берләшеп, төрле мәсьәләләрне хәл итә торган урын. Безнең бер кулыбыз иҗтимагый хәрәкәткә сузылган булса, икенчесе – хөкүмәткә таянып, аның ярдәмен милли оешмаларга җиткерә. Мәгълүм булганча, күптән түгел Россия Президенты В.В.Путин милли җәмәгатьчелеккә дәүләт ярдәмен тәэмин итү мәсьәләсен күтәрде. Тиздән бу юнәлештә Россия күләмендәге иҗтимагый-дәүләти оешма барлыкка киләчәк дип көтелә. Илебездә кирәк дип табылган һәм гамәлгә куелырга торган эш Татарстанда инде 30 елга якын тормышка ашырылып килә. Татарстан халыклары ассамблеясе – бу милли хәрәкәтнең иҗтимагый өлеше. Ә Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты – дәүләт өлеше.

– Үткәргән чараларыгызны күзәтеп киләбез. Сез татар халкының гына түгел, Татарстанда яшәүче башка халыкларның да мирасын торгызуда һәм халыкка кайтаруда зур эшләр башкарасыз...

– Оешмабызның үзенчәлеге шунда – без үзебез чара уйлап табучылар түгел. Бурычыбыз – иҗтимагый хәрәкәтләр кирәк дип тапкан чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру. Милли оешмалар өчен нидер эшләп бирү кирәкми. Әгәр дә аларның көчле активы, дәрәҗәле җитәкчесе, үз яшәешен тәэмин итәрдәй куәте юк икән, димәк, ул үле хәлдә. Аңа булышырга омтылу, булмаган әйберне бар итеп күрсәтергә тырышу дөрес гамәл түгел! Без – эшләгән кешегә ярдәм итүчеләр. Бабайлар: «Әйтеп эшләнгән эш – эш түгел», – дигән. Теге яки бу оешма өчен чаралар уйлап табып, аларны уздырып бирү белән шөгыльләнсәк – бу хата, күз буяу булыр иде.

– Милли гореф-гадәт һәм традицияләрне торгызу мәсьәләсе ничек?

– Әлбәттә, максатыбыз – Татарстандагы һәр милләтнең телен, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклап калырга ярдәм итү. Бу очракта ике төрле фикер яшәп килә. Кайберәүләр, Каравон, Май чабу, Питрау һәм Семыкны оештыру турында сүз барганда: «Аттракцион, карусель, батутлар куйсак, кеше күбрәк килер, күңеллерәк булыр», – диләр. Икенчеләре: «Болар булса, миллилек югала. Әйдәгез, ата-бабаларыбыз кебек итеп, борынгы гореф-гадәтләр нигезендә үткәрик», – дигән фикер белдерә. Монда алтын урталыкны табарга кирәк дип саныйм. Элеккечә генә уздырсак, Питрау бәйрәменә 50 меңнән артык кеше җыелмас, Каравонга да шулкадәр кеше килмәс иде. Бу бәйрәмнәрнең масштабы инде гаилә, авыл бәйрәме кысаларыннан чыгып килә. Милли гореф-гадәтләрне сакларга, күрсәтергә теләсәк тә, без аны заманча, зур форматта итеп үткәрүдән баш тарта алмыйбыз. Кешеләрнең күп булуын да, гореф-гадәтләрнең аутентиклыгын – дөреслеккә тәңгәллеген дә саклап калырга телибез. Күптән түгел генә Май чабу зур мәйданда узды. Анда төрле чаралар оештырылды. Элек кешеләр нинди киемнәрдә булганлыгы, нинди җыр-биюләр башкарганлыгы, ягъни бәйрәмнең тарихи өлеше мәйданның аерым почмагында күрсәтелде.

Республикабызда иң күп халык катнашында үтә торган бәйрәм – Җөри авылындагы Питрауны гына алыйк. Аны элеккеге керәшен авылларында оештырыла торган Питрау дип санасак, әлбәттә, хакыйкатькә туры килми. Шуңа да ул «Питрау фестивале» дип атала. Аның тарихи өлеше аерым узса, 50 мең халыкның күбесе концерт, «Питрау чибәре» конкурсын карый, спорт ярышларында катнаша. Әмма максат бер – Питрау ярдәмендә керәшен татарларының бай милли мирасын халыкка таныту.

– Ирек Илдусович, Халыклар дуслыгы йортында кешеләрне еш кына милли киемнәрдән күрергә туры килә.

– Халыклар дуслыгы йортында, шулай ук республикабыздагы 12 Дуслык йорты һәм үзәгендә ел дәвамында 2 меңнән артык чара уза.

Әмма минем үз гомеремдә җырларга һәм биергә дип кенә оешкан бер генә милли оешманы да күргәнем юк. Һәр милли оешма фәкать проблема булганга гына барлыкка килә. Чөнки җыр-бию өчен халык җыелса, ансамбль оешыр иде. Хәзерге вакытта Татарстанда 38 халыкның 240 милли оешмасы эшләп килә. Бу – 240 урында 38 милләтнең проблемасы бар дигән сүз. Аз санлы халыкның проблемасы да, зур халыкныкы кебек, җитди рәвештә, дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителә.

– Мәгълүм булганча, татар халкын һәм башка милләтләрне халык санын алу көтә. Җанисәп вакытында, этник төркемнәргә бүлгәләнмичә, милли бердәмлекне саклап калу – һәрберебезнең төп бурычы. Сез бу юнәлештә эш алып барасызмы?

– Этник төрлелек байлык булса да, һәр милләтне бердәм итеп күрсәтү күпкә отышлырак. Кайсы гына төбәктән күчеп килмәсен, милли җәмәгатьчелекнең фикере бер: ул – Россиядәге милләтләрнең санын дөрес күрсәтү. Милләтләрне таркатып, аның санын бүлгәләүдән мәгънә юк – бу киеренкелек тудыра. Татарларның һәм башка милләтләрнең күпме икәнлеген төгәл белү – дәүләт өчен мөһим мәсьәлә.

Төрекмән кызы

Марий Эл Республикасы студентлары Халыклар дуслыгы йорты белән таныша. 2019 ел

Якут кардәшләребез Халыклар дуслыгы йортының эш тәҗрибәсен өйрәнә. 2020 елның 5 феврале

Башкорт мәдәнияте көннәре. 2019 елның 26 октябре

Мәдәниятләр мозаикасы фестивалендә этномаркет.
2019 елның 21 сентябре

Милләтләр дуслыгы дәресе. 2019

Казандагы мари ижат төркемнәре һәм сәнгать осталары катнашында концерт.
2020 елның 15 феврале

Татарстанда Төрекмәнстан мәдәнияте көннәре.
2019 елның 7 октябре

Фотолар addnt.ru сайтыннан алынды

Быел халык санын алуда бер яңалык бар: кеше үзенең берничә милләткә нисбәтле икәнен өтер аша күрсәтә ала. Мәсәлән: «Мин – татар, урыс, удмурт», – дип. Бу катнаш гаиләләрдә туган балалар өчен уңай дип саныйм. Әмма, беренче итеп кайсы күрсәтелгән, милләт саны исәбенә шунысы гына керәчәк. Икенче һәм өченче итеп теркәлгән милләтләр төп статистикадан читтә кала. Бу очракта игътибарлы булу кирәк!

– Җанисәп мәсьәләсендә милли оешмалар арасында теләктәшлек бармы?

– Бер генә милли оешма әгъзасының да, әйдә, үзара кушылыйк та югалып бетик әле, дигән теләге юк. Әрмәннәр җыела икән, алар үз милләтләрен ничек саклау турында кайгырта. Оешмалар үзара дус булсалар да, һәрберсенең максаты – үзенең телен, милли үзенчәлекләрен саклап калу.

Республикабызга ел саен 300 меңнән артык мигрант килә. Кайбер төбәкләрдә миграция мәсьәләсе зур проблемага әверелә. Чөнки җирле халыклар үзләренең мәнфәгатьләрен саклап кала алмый. Читтән килгән халыклар аларның яшәешенә җитди басым ясый башлый. Әмма Татарстанда мондый хәл күзәтелми, чөнки татарның көчле менталитеты, гореф-гадәтләргә тугрылыгы бар. Шөкер, һәр өлкәдә дә казанышларыбыз җитәрлек. Бер генә халык алдында да ким-хур түгелбез. Әле күптән түгел генә Якутиядә булып кайттым. Алар: «Мигрантлар килә, безне үзгәртәләр», – диләр. Татарга әлегә мондый куркыныч янамый.

– Гомумән алганда, республикабызда татар халкының менталитеты нинди хәлдә?

– Менталитетны саклаучы мохит – әлбәттә, авыл. Әмма хәзерге көндә Татарстанда авыл халкы 25 процентка калып бара. Нинди генә бай мирасы, мәдәнияте булса да, шәһәр кешесе яки авылдан килеп шәһәрләшкән татар ул башка инде. Шәһәр мохите унификацияләнгән, бер теллелеккә, бер мәдәнияткә юнәлеш тота. Бездә заманча шәһәр милли мохитен тудыру бурычы торырга тиеш. Бу мөмкин эш. Зур гына мишәр авылларының миллилеге, аларның тырышлыгы һәм мәхәллә системасы турында сөйләргә яратабыз. Ләкин бүгенге көндә башка мисаллар кирәктер. Әйтик, Ижауда 70 меңнән артык татар яши һәм шәһәр мохитендә милли хәрәкәт үрнәге тудырылган, милли үзбилгеләнү яшәп килә. Шәһәрдә мәчеткә йөрү татар кешесе өчен дини йола гына булырга тиеш түгел, бу – милли үзбилгеләнүнең беренче адымы да. Милли оешма барлыкка килүнең бер сәбәбе – балаларга милли тәрбия бирү, улны яки кызны башлы-күзле итү, бизнеста партнерлар табу… Татар киредән авылга кайтмаячак, шуңа күрә югары мәдәниятле милли шәһәр мохите тудыру, миллилекне модалы итү кебек нәрсәләр татарлыкны саклауның бер юлы булып тора.

Күптән түгел машина төзәтер өчен бер автосервиска бардым. Анда эшләүчеләрнең барысы да әрмән икән. Димәк, ул – милли сервис. Шәһәр шартларында үзләренә милли мохит, милли бизнес тудырганнар. Шунда бер егет, гап-гади автомеханик: «Америкага китәм! Мин Әрмәнстаннан монда – үзебезнекеләр янына килдем, Америкага барып, анда да әрмән сервисында эшләячәкмен. Хәтта инглиз телен өйрәнергә дә җыенмыйм», – ди. Әрмәннәр, менә шулай итеп, һәр илдә, һәр төбәктә милли мохит тудыра ала. Алар: «Милләтем миңа ярдәм итәчәк, чит кешеләр янына бармыйм», – диләр. Яһүдләрдә дә моның үрнәкләрен күрә алабыз.

Әйткәнемчә, татарларда мәчет – гыйбадәт урыны булу белән бергә, милли тәрбия үзәге, аралашу мәйданы да. Шунда эшлекле мөнәсәбәтләр урнаша, никахлар укыла, татар телендә вәгазь сөйләнә, балалар тәрбиясе, туган тел мәсьәләләре күтәрелә, ана теле дәресләре укытыла, уртак мәнфәгатьләр туа.

– Димәк, миллилек кешенең калебендә, рухында булырга тиеш…

– Һәм ул яшәү рәвеше – отышлы яшәү рәвеше булырга тиеш дип саныйм. Менталитетны саклау – уңышлы милли тормыш моделе дигән сүз.

– Ирек Илдусович, башка милләт кешеләренең татарларга мөнәсәбәте ничек? Үрнәк алалармы, әллә тәнкыйди караштa торалармы? Бүтән милләтләргә ихтирам бер-береңә ихтирам аша килә бит!

– Без әби-бабаларыбызга рәхмәтле булырга тиеш! Татар халкының башка милләтләр арасындагы дәрәҗәсе югары. Мирас, гореф-гадәт, милли яшәү рәвеше нәрсә ул? Бу – беренче чиратта, ата-бабалардан килгән яшәү рәвеше. Милли мирасыбыз көндәшлеккә сәләтле! Хәзерге көндә дә бу яшәү рәвеше уңышлы кеше булырга ярдәм итә ала. Безгә, уңышка ирешер өчен, һич кенә дә үзебез булып калудан баш тартырга ярамый! Татар булу – конкурентлыкка сәләтле заманча яшәү рәвеше. Әрмән ни өчен үзенекенә ябышып ята? Чөнки милли бердәмлеге аңа дөнья базары шартларында көндәшлеккә сәләтле итеп эшләргә, үзенә уңай, җылы, туганнарча шартлар тудырырга мөмкинлек бирә.

– Халыклар дуслыгы йортында эшләп килгән милли оешмаларның катнаш никахта торган әгъзалары үзләренең төп милләте итеп нинди милләтне күрәләр?

– Кызганыч, күпчелек кагыйдәсе өстенлек ала. Бу – шәһәрләшү белән бәйле күренеш. Элек татар авылына башка милләт вәкиленең килен булып төшүе гайре табигый хәл иде. Ә безнең Дуслык йортындагы милли оешмаларга килгәндә, аларның эшчәнлегендә катнашкан барлык кешеләр өчен дә булачак тормыш иптәшеңнең нинди милләттән булуы мөһим мәсьәлә.

ТР Президенты каршында елга берничә мәртәбә Милләтара һәм динара совет җыела. Соңгысында безне гаҗәпләндергән саннар да аталды. Җәмгыятебездә халыкның 30 проценттан артыгы үзен ислам дине кануннары буенча яши яки яшәргә омтылучы дип күрсәтә. 30 проценттан артыгы исә – христиан кануннары буенча. Мине гаҗәпләндергәне шул булды: халыкның 30 проценттан артыгы үзен бер дингә дә өстенлек бирмәүче кеше итеп күрсәтә икән. Бу – җәмгыятебезнең яңа портреты.

– Мондый вазгыять космополитизм үсеп килгәнне күрсәтмиме икән?

– Әйе, нәкъ шулай. Аңа дин барыбер икән, бу – милли тел дә, мәдәният тә кирәкми дигән сүз. Әлеге хәл яңа, үзгә карашлы буын үсеп килгәнлегe хакында сөйли. Әмма вазгыять һәрвакыт үзгәреп тора. 30 ел элек татар теленә игътибар булыр, милли телдәге матбугатның саны артыр, татар интернеты булыр дип уйламый да идек. Әмма алар барлыкка килде һәм милләтне саклау өчен зур эшләр башкарды. ТНВ каналы эшли башлагач, Сарапулда яшәүче өлкән ападан интервью алган идем. Ул: «Мин инде татарны күптән беткәндер дип уйлый идем. Баксаң, дөнья тулы татар, без яшибез икән», – ди. Мәнсез булырга ярамый. Ходай мөмкинлекне биреп тора.

– Россиянең башка төбәкләрендә Халыклар дуслыгы йортлары эшлиме? Аларда татарларга урын бармы?

– Хәзерге көндә Россиядә 30дан артык төбәк күләмендәге һәм 100дән артык шәһәр күләмендәге Дуслык йортлары эшләп килә. Аларның һәрберсендә дә диярлек татар милли хәрәкәте вәкилләре бар. Татар яшәгән һәр шәһәрдә милләттәшләребез күркәм, йогынтылы урын алып тора.

Мондый оешмалар элеккеге союздаш республикаларның кайберләрендә бар. Фәрит Мөхәммәтшин күптән түгел Казакъстан халкы ассамблеясының эше белән танышып, безгә алар тәҗрибәсен тирәнрәк өйрәнергә кушты. Үзбәкстанда да шундый ук структура уңышлы эшләп килә. Әмма Әрмәнстан кебек илләрдә юк, чөнки алар – абсолют моноэтник дәүләтләр. Анда читтә яшәүче әрмәннәргә ярдәм итү белән шөгыльләнә торган дәүләт структурасы актив эшләп килә. Азәрбайҗанда да Диаспоралар буенча комитет бар. Милли мәсьәлә белән без генә шөгыльләнмибез. Бу эшләрне башка милләт вәкилләре дә башкара һәм ул нормаль күренеш.

– Сезнең тәҗрибә белән федераль дәрәҗәдә кызыксыналармы?

– Кызыксыналар. Әйткәнемчә, Россиядә иҗтимагый-дәүләти оешманы рәсми

рәвештә төзергә дигән карар кабул ителде. Хәзерге көндә аны оештыру эшләре алып барыла. Безнең тәҗрибәне өйрәнер өчен, Мәскәүдән берничә эш төркеме килеп китте. Алар Татарстанда халыклар дуслыгы мөнәсәбәтләре ничек корылганын тирәнтен өйрәнде. Нәтиҗәдә, күп кенә эшләребез ил күләмендә дә гамәлгә кертеләчәк, иҗтимагый хәрәкәт вәкилләре белән дәүләт үзара ничек эшләргә тиеш дигән модель Россия буенча да гамәлгә ашырылачак дип уйлыйм. 30 елга якын тәҗрибәбез әлеге гомум эшкә саллы бер өлеш булачак.

Бу күптән көтелгән адым иде. Милләтара мөнәсәбәтләрне Татарстанда гына матур итеп корып, илнең башка төбәкләрендә дә шундый эш алып барылмаса, ерак китә алмаячакбыз. Дөнья, ил күләмендә милләтара ксенофобия күренешләре яшәп килә, аларга каршы көрәш оештырылмаган икән, без үзебез генә, Татарстан чикләрендә генә моны үзгәртә алмыйбыз. Һәр милләткә ихтирамлы караш булырга тиеш!

Идел буе һәм Урал республикалары арасында тарихи дустанә мөнәсәбәт бар. Бездәге удмурт, чуаш, мари мәктәпләренә дәреслекләр һәм укыту ярдәмлекләре күрше республикалардан килә һәм бу эш дәүләт дәрәҗәсендә башкарыла. Татарстанда йөзгә якын чуаш, 24 – удмурт, 20ләп мари теле укытыла торган мәктәп бар. Моннан тыш, Дуслык йортында күпмилләтле якшәмбе мәктәпләре эшләп килә. Анда 20 милләтнең туган теле өйрәнелә. Бу мәктәпләрдә 400дән артык бала шөгыльләнә. Әмма, закон буенча, без әрмән, грузин, азәрбайҗан телләрен ул дәүләтләрдән килгән дәреслекләр буенча укыта алмыйбыз. Шуңа күрә, бу телләрне өйрәнү өчен, үзебезнең галимнәр һәм укытучылар тарафыннан махсус дәреслекләр булдырылды һәм гамәлгә кертелде.

– Телне, милләтне саклап калыр өчен нәрсә эшләргә кирәк һәм бүгенге шартларда нәрсә эшләп булыр иде?

– Уңышлы булырга кирәк! Балаң синең кебек булсын, милләтең башка халыклардан артта калмасын, киләчәктә матур яшәсен, дисәң, үзебезнең яшәү рәвеше, тәрбия моделе уңышлы булырга тиеш. Без уңышлы булсак, киләчәк буын да безнең кебек булырга теләр. Көндәшлеккә сәләтле мәгариф һәм мәдәният системасын булдырырга кирәк. Казанның яһүд гимназиясен генә алыйк, анда татар һәм рус балалары да белем ала. Ни өчен? Чөнки анда уңышлы кешеләр, шәхесләр тәрбиялиләр. Ул мәктәпнең укыту системасы шундый итеп корылган: бала, чыннан да, төпле белем һәм яхшы тәрбия алып чыга. Әлбәттә, анда уку таләпләренең берсе – яһүд телен һәм мәдәниятен өйрәнү. Бу – күпмедер дәрәҗәдә әлеге милләтнең яшәү рәвешен өйрәнеп, аны үзеңә модель итеп кабул итү дигән сүз.

Хәзер полилингваль мәктәпләр төзелеп килә. Әлеге мәктәпләрне көндәшлеккә сәләтле итеп гамәлгә кую – милләтне күтәрүнең бер юлы. Мин милләтебезнең, республикабызның киләчәгенә өмет белән карыйм. Тормыш гел үзгәреп тора. Әгәр дә үзебезне милләт буларак саклап кала алабыз икән, киләчәктә бөтенләй башка мөмкинлекләребез, үзгә шартлар булыр, ИншәАллаһ.

Әби-бабаларыбыз тапшырган мирас бүгенге заман шартларында да яшәргә яраклы. Бу – көндәшлеккә сәләтле зур байлык һәм аны сакларга, арттырырга кирәк. Без булдыра алабыз!

Әңгәмәне журналга ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Гөләйза

Фәүзия Бәйрәмованың «Гөләйза» әсәре архив документларына нигезләнеп язылган. Романда вакыйга 1827-1868 елларда Чистай ягы – Кыр Шонталасы, Чиръле Шонтала, Актау авылларында бара.

Казан яулап алынганнан соң өч гасыр вакыт узган. Шуңа карамастан, татар халкын чукындыру сәясәте һаман дәвам итә. Горур татар халкын һаман тез чүктерә алмыйлар. Гөләйзаның әби-бабасын, көчләп чукындырылгач та үз диннәрен тоткан өчен, кара мунчага бикләп, тончыктырып үтерәләр. Татар халкы, төрле газаплар күреп тә – балаларының язмышы кыл өстендә булганда да, мөселманлыктан, иманнарыннан ваз кичмәгән. Хатыннарны, ирләреннән аерып, урыска кияүгә бирәләр, балаларын аерып алып чукындыралар һәм урыс гаиләсенә тәрбиягә бирәләр. Кеше чыдамаслык шартларда да татар динен, иманын, милләтен саклап калган. Алар бары Аллаһ алдында гына тезләнгәннәр. Иман, дин хакына татарлар бөтен авырлыкларга да түзәләр.

Гөләйза чиркәү кенәгәсенә «керәшен» дип язылган, үзе мөселман динен тота, шуның өчен берничә ел буе суд юлында йөри. Судта аңа Пелагея дип эндәшкәнгә ул, кулына күкрәгенә яшереп алып кергән Коръән тотып: «Минем исемем Гөләйза!» – дип кабатлый, бу аның – йөрәк түреннән чыккан протесты. Канаты каерылган кош кебек булса да, Гөләйза, ана арысландай, балаларын яклый. Кечкенә генә татар хатыны да динен, иманын яклагач, ничек инде ул халык җиңелсен! Хәтта дошманнары да татарларга соклана. Тикшерергә килгән алман Мейснер: «Үз абруен белеп, диненә тугрылыкта, үлгәнче аны бирмәячәге ачык. Динен түгел, башындагы түбәтәен дә бирми татар. Ни әйтсәң дә, Чыңгыз хан нәселе шул, борынгы Биләр-Болгарның дәвамчысы», – дип, куркып, сокланып карый. Урыс побы динен алыштырганнарга: «Сез, үз динегезне сатып, безнең дингә сыенган», – дип, аларга җирәнеп карый, чөнки сатлыкларны бер халык та якламый.

Гөләйза – батыр татар хатыны, дошманнарын җиңеп, мәңгелек дөньяга мөселман килеш күчә. Дисбе дә, буыннан-буынга тапшырылып, әсәрнең буеннан-буена дингә тугрылык символы булып бара.

Гөләйзаның әтисе Ишмөхәммәт Уразмәтов бик көчле, акыллы кеше. Ул милләте, гаиләсе өстенә төшкән авырлыкларны күтәрә. Татар байлары, морзалары, кулларыннан килгәнчә, аларга ярдәм итеп торалар. «Татарны, үзеннән кала, беркем дә якламаячак», – ди Гомәр әзи. Ишмөхәммәт: «Ассагыз да, киссәгез дә, хәтта яткырып суйсагыз да, яңадан урыс диненә кайтмаячакбыз», – ди судта сорау алганда.

«Милләтебез алга таба исән калырмы, динен, телен, үзен саклап кала алырмы – һәрберебездән тора». Гөләйзаның әтисе Ишмөхәммәт авызыннан чыккан бу сүзләр бүген дә актуаль. ИншәАллаһ, динебез сакланып калды, телебез генә куркыныч астында. Әсәрдәге Биләр побы дәвамчылары бүген дә исән, тик эш ысуллары гына икенче. Милләттәшләребез тарафыннан ничә гасыр буе күп корбаннар биреп сакланып килгән телебезгә һаман да һөҗүм дәвам итә. Без, бүгенге татарлар, гасырлар дәвамында ничә буын саклап калган телебездән үз ирегебез белән ваз кичәбезмени?!Безнең барыбыз өчен дә изге бит ул туган тел – татар теле. Телне, гореф-гадәтләрне авыл саклап кала, диләр иде. Инде авыллар да бетү алдында. Чит тел безгә газиз туган телебез була алмый бит. Телебезне бергәләп саклыйк, сатлык җаннар булмыйк!

Сиринә Галиева,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Милләт вәкилләре мәҗлесендә полиция кешеләре

Сүз чыкканда, тагын шуны да әйтим: Милләт вәкилләре мәҗлесендә ишек саен бер полиция кешесе басып тора. Мин моның мәгънәсен һич кенә дә аңлый алмадым, дөньядагы бер генә илдә дә бу хәл юктыр, дип уйлыйм. Бөтен дөньяда парламент әгъзалары, Мәҗлестә генә түгел, башка урыннарда да бөтен төр җаваплылыктан азат ителгән. Хәтта, парламент дәрәҗәсендә булмаса да, Русия Дәүләт Думасы әгъзалары да Дума эчендә үзләре теләгән кадәр иректә. Хәтта, бервакыт, дөньяның иң зур әдәпсезе – Дума әгъзасы Пуришкевич[1], холкы шундый булганга, Думада әдәпсезлек гамәле кылганда, Дума рәисе Головинның[2] тәкъдиме буенча һәм бөтен әгъзаларның бердәмлеге белән, Мәҗлестән чыгарырга дигән карар кабул ителгән иде. Пуришкевич ул утырыштан чыкмады. Дума, Мәҗлес залына полиция кешеләре кертеп ямьсезләнмәс өчен, ул көнне, шул ук сәгатьтән фикер алышуларны туктатып, Мәҗлесне ябык, дип белдерде. Бөтен милләт вәкилләре белән бергә Пуришкевич та чыкты. Кыскасы, парламентны полиция катышуыннан шул дәрәҗәдә читтә тоталар иде.

Японнарда исә, парламент эчендә полиция кешеләре һәрвакыт бар. Бу хәл бөтен мәдәнилек кануннарына каршы төшә.

Хәзер инде максатка килик: икенче утырышта сөйләүчеләрнең чыгышлары милләт вәкилләре тарафыннан бик көчле алкышланды. Чыгышлар бик көчле, хәтта куркыныч та иде. Бер тапкырында, чыгыш вәкилләр тарафыннан алкышланган вакытта, гади тыңлаучылардан бер кеше катнашып китеп, кул чапты. Полиция кешесе килеп, шунда ук ул кешене Мәҗлестән чыгарды. Япониядә полициянең бөтен ил күләмендә бик әһәмияте булмаса да, Милләт вәкилләре мәҗлесендә ул бик үзенчәлекле урын тота икән. Тик нигә алай? Бу – чынлап та, кызыксыну тудыра торган хәл. Мин дә шул хакта бик күп кешедән сорадым, гел, «гадәт шундый», дигән җавап ишеттем.

[1] Пуришкевич Владимир Митрофанович (1870-1920) – уң консерватив карашлар яклы сәяси эшлекле, монархчы, карагруһчы, 2 нче һәм 3 нче чакырылышларда Дума әгъзасы; чыганакларда Дума утырышларында тәртипсез чыгышлар ясаучы һәм Распутинны үтергән кеше буларак та искә алына (тәрҗ. иск.).
[2] Головин Федор Александрович (1867-1937) – Россия империясенең 2 нче чакырылыш Дәүләт Думасы рәисе, земство эшлеклесе, кадетлар партиясенә нигез салучыларның берсе һәм аның ҮК әгъзасы (тәрҗ. иск.).

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Шәех Габдерәшит Ибраһим хәзрәтләре

Япониядә җәмгыятьләр

Япониядә җәмгыятьләр бик күп, бар эш тә диярлек җәмгыятьләр тарафыннан башкарыла. Бөтен һөнәр ияләренең дә үзләренә генә аерым җәмгыятьләре бар. Тарихчылар җәмгыяте, Милли әхлакны саклау җәмгыяте, Ватанны яклау җәмгыяте, Тоһошиги (чыгымнарга саклык белән карау, акчаны саклык белән тоту) җәмгыяте, Һөнәрчеләр җәмгыяте һ.б. Һәр кеше үз мәсләгенә, сыйныфына туры килә торган берәр җәмгыятьне сайлый.

Болар арасында менә шул Тоһошиги дигәннәре – гаять зур җәмгыять. Тоһошиги «җәяү йөрүчеләр» дигәнне аңлата, ягъни, алар фикеренчә, икътисадка шулкадәр игътибарлы булырга кирәк ки, хәтта, мөмкин булса, артык кирәге булмаса, машинага яки трамвайга да утырып йөрмәскә, җәяү йөрергә, акчаны бик кадерләп тотарга

кирәк. Бу җәмгыять тоткан юл шуннан гыйбарәт икән: шулай кысып тоту нәтиҗәсендә тупланган акча милләт мәнфәгатенә сарыф ителергә, гомумән, бар нәрсә дә уртак мәнфәгатьләр өчен тотылырга тиеш.

Әлеге җәмгыятьнең үз фикерләрен язып бастыра торган ике газетасы бар, икесе дә Токиода чыга. Берсе – көнгә ике тапкыр чыга торган «Памата», икенчесе – атнага бер чыга торган «Тоһошиги» газетасы. Җәмгыятьнең бөтен омтылышы – юксыл, фәкыйрь катламның мәнфәгатьләренә хезмәт итү.

Бу җәмгыятьнең рәисе Омиһара җәнаплары – японнарның иң мәшһүр шәехе. Әлеге шәхеснең фикердәшләре йөз меңнәрдән дә артып киткән. Ул шәхес белән арабызда бик якын дуслык хасыйл булды. Махсус минем хөрмәтемә берничә тапкыр мәҗлес җыйды. Шуларның берсе өчен чакыру кәгазен хәтта почта карточкасы рәвешендә дә бастырган иде. Менә шул чакыруның рәсемен, хөрмәтле укучыларым, сезнең игътибарыгызга да тәкъдим итәм.

Бу мәҗлес Токионың иң атаклы мәхәлләсендә – Кандабаши дип йөртелгән җирдә уздырылды. Мәҗлестә катнашучылар алдында бик озын итеп чыгышлар ясалды. Чыгышлар ике сәгать ярым дәвам итте. Аны «Кандабаши чыгышы» дигән исем белән «Галәм-е Ислам»да чыгышлар бүлегендә бирәчәкмен.

Чыгышлар тәмамлангач, мәҗлес башланды. Әлеге мәҗлестә төшерелгән фоторәсемнәрнең беренчесендә мин, Һинд голәмәсе вәкиле Бәрәкәтуллаһ, Мисыр яшьләреннән – Әхмәд Фазлы, Томас Бринан исемле бер инглиз кешесе дә бар. Икенче рәсем аш табыны янында утырганда төшерелде. Әлеге фотода табын артында булганнарның яртысы гына кергән, калганнары кермәгән.

Бу мәҗлесләр һәм анда сөйләнгән сүзләр, чыгышлар Токио газеталарында тулысынча бирелеп барды.

Конт Окома белән күрешү

Беркөнне кабат Конт Окома белән күрештем. Безнең арада мондый сөйләшү булып узды. Конт Окома, сорау биреп, сүзне башлап җибәрде:

– Ничек, безнең япон телен аңлый аласызмы?

– Яшем олы, тик шулай да тырышам, әйтергә теләгән фикеремне әйтә алам, авылларда тәрҗемәчесез генә йөрим.

– Японнарда бер гыйбарә бар: «Яратуны аңлату өчен телгә ихтыяҗ юк», – диләр. Япон теле өйрәнер өчен авыр тел түгел, ләкин язуы авыр.

– Әйе, язуыгыз – өйрәнү өчен авыр, тик катакана язуыгыз бик авыр түгел. Әмма шунысы бар: катакана язуын белү генә җитми.

– Катакана язуын белсәгез, язышыр өчен ул җитәрлек, калганнары әдәбият өчен кирәк.

Мин, сөйләшүне дәвам итеп, болай дидем:

– Мин Сездән кайбер нәрсәләр сорашып белергә телим. Японнарның киләчәге турындагы фикерләрегезне әйтсәгез иде. Япония киләчәктә бөек дәүләт була алачакмы? Бүгенге көндә японнарда халык саны арту бик көчле, һәр ике елда халык бер миллионга арта. Бу хәлгә карап хисап чыгарсак, ун елдан соң халыкның бүгенге саны биш миллионга, бәлки, тагын да күбрәккә артачак. Әле хәзер дә җир җитәрлек түгел, эшсез, җирсез калган японнар бар. Ә алда нәрсә булачак? Хөкүмәт бу хакта уйлыймы?

– Әйе, әлбәттә, биш елдан соң түгел, японнарга бүген үк җир кирәк. Бу хакта уйланабыз. Корея гына түгел, биш елдан соң Маньчжурия дә, Монголия дә кирәк булачак. Ул җирләргә генә түгел, Һинд океаны утрауларына кадәр үрелергә исәплибез.

– Ул хәлдә японнарның киләчәге Аврупаның үчегүенә дучар булмасмы?

– Ни генә булса да, вазгыять мәҗбүр итәчәк. Японнарның яшәеше моннан соң кылычларының очында, ядрә атар тупларының авызында булачак.

– Шуларны уйлаганга, мин бу сорауларны бирдем дә инде. Нәкъ менә шушы урында башыма бер уй килде. Аврупалы дип йөртелә торган көнбатыш халыклары үз мәнфәгатьләрен гел башкаларның зарарыннан, яшәүләрен башкаларның үлеменнән эзлиләр. Үзләре яшәсен өчен нәрсә комачаулый, нәрсәне, кемне юк итәргә кирәк – юк итәләр, бер дә икеләнеп тормыйлар. Вөҗданнары да мондый хәлләргә бик яраклашып тора. Каршыларында башка берәр көч торуын, әлбәттә, һич кенә дә теләмиләр. Шулай булгач, элек-электән яшәп килгән бу ялган-ялгыш максатлары белән, болар японнар турында бик үк сау булмаган фикер йөртмәсләрме? Тагын да ачыграк итеп әйтсәк, болар гел Япония зарарына эш итмәсләрме?

– Берәү дә, беркайчан да, каршысына үзеннән көчлерәк көндәш чыгуын теләми – бу бик табигый хәл. Көнбатыш халыклары да һичбервакыт көнчыгышта мондый көч чыгуын теләмәс һәм, гомумән, Көнчыгышның бөтен уй-фикере моңа юнәлдерелгән. Сары расадан куркулары да шуннан. Тик безнең вазыйфабыз да үз мәнфәгатьләребезне кайгырту лабаса. Бүген Япониянең Аврупа каршысында торкан билгеле урыны бар, ул урынны саклау һәм мөмкин булган кадәр ныгыту, киңәйтү – иң олы максатыбыз.

– Төркия хөкүмәтенең [Госманлы империясенең] аврупалылар каршысында торкан гаять зур урыны бар иде. Ул чакларда халкының саны да 70-80 миллионга җиткән, коры җир өстендә, диңгездә торкан урыны да көчле, киләчәге дә якты иде. Ләкин беркөн килеп, аврупалыларның үтә сизгер сәясәт барометрлары моны тотып алуга, еракларны күзәтә белүче дипломатлары, бар форсатны кулланып, акрын-акрын бу киңлеккә чик куярга тотындылар һәм, 150 ел үтәр-үтмәс, бүгенге хәленә китереп тә җиткерделәр. Инде төрекләргә аңнарына килергә бик кыен, ник дигәндә, аврупалылар боларның рухларына үчеккәннәр һәм әхлакларын таркатканнар, рухсыз гәүдә хәленә китергәннәр. Японнарга карата да шундый чаралар күрмәсләрме?

– Аврупалыларның японнарга карата да моңа охшаш уй йөртүләрендә шик юк, чөнки бөтен тирәлекне дер селкетеп торган мәсьәлә бар – яшәп калу яки юкка чыгу. Әмма японнарның төрекләр белән чагыштыргысыз сыйфатлары бар. Беренчедән, японнар – бер генә милләт, бүгенге көндә илле миллион кешедән торган халык бер уртак фикергә хезмәт итә. Кирәк булганда, биш миллион гаскәри, корал тотып, үзләре теләгән якка юнәлә ала. Японнарга Ватан өчен җаннарын фида итү берни түгел. Ирме, хатын-кызмы, «Алга! Марш!» диелсә, шунда ук алга ташланачак. Руслар белән булган сугыш нәкъ шуны күрсәтте дә. Бер елга сузылган сугышта бер карыш та артка чигенмәделәр. Японнар уй-фикерләрен эштә раслап күрсәттеләр. Японнарның борынгыдан килгән инанулары бар: сугыш вакытында кире чигенү һич кенә дә ярамый. Шуңа күрә, японнарның үз араларында барган сугышларда да вакытлы килешүне башта җиңүче якның таләп итүе, кагыйдә буларак, кабул ителгән иде. Японнарның болардан башка да күп кенә үзенчәлекле яклары бар, шул сәбәпле, японнарны төрекләр белән чагыштырып булмый. Аврупалы халыклар, күпме генә тырышсалар да, Японияне бүгенге хәленнән кечерәйтә алмаслар. Тагын шул да бар: бөтен Шәрыкның уяныр вакыты җитте. Боларның барысын да игътибарга алырга кирәк. Моннан тыш, төрекләрнең оеп йоклауларының төп сәбәбе – ул вакытта төрек дошманнарының да йоклавы. Ә бүгенге япон дошманнары исә, бар да уяу, бар да аякта, көн саен күпләп- күпләп ара үтәләр. Шулай була торып, японнар ничек йокласын?! Шунысы да бар: безнең вазыйфабыз – гел эшләү, тырышу.

Конт Окома бу мәсьәләгә карата сүзен шулай тәмамлады.

Моннан соң озакка сузылган фикер алышу башланып китте. Исемдә калган

Безнең мирас №4 апрель 2020



謹啓春暖之候愈々御多祥奉賀候陳者今般徒歩主義發展策之
一手段として來る貳拾壹日(日曜日)午後一時より京橋區銀
座貳丁目東仲通り梅林俱樂部に於て青年團大懇親會を開催
致し席上今回來朝の本會々員露國大徒歩家エドイブラヒム
氏招待大演説會開催の件外種々協議を可仕候間萬障御一排
是非共御奮臨被成下度此段御案内申上候
當日會費金貳拾五錢御持參の事
追て準備の都合有之候間御出席の有無折返し銀座四丁目松田元方京橋支部
迄御一報被下度候尚今回は有志諸君よりの寄贈品も似に數拾点に達し居り
候得者御辨當茶菓の外種々餘興の後大福引執行可仕候
月 日 徒歩主義青年團大懇親會發起人
戸谷太郎 梅原喜太郎
清水吉康 久住久
松田元 道明直次郎
藤田貫一

"Тоһошиги" җәмгыяте рәисе оештырган мәҗлескә чакыру язуы

кадәрен теркәдем. Кыскача эчтәлеге менә шул алда әйтелгәннәрдән гыйбарәт иде. Конт Окомага болай дидем:

– Мин японнарның тарихларын, аннан да бигрәк, бүгенге хәлләрен һәм конституцион идарәнең тарихын белергә, аңларга телим. Бу хосуста кайбер дусларым принц Ито белән күрешергә һәм аннан мәгълүмат алырга киңәш иттеләр.

– Әйе, бездә кануннарны төзүче – принц Ито җәнаплары. Әгәр аның белән күрешсәгез, бик күп мәгълүмат ала алырсыз. Моннан тыш та сезгә принц белән күрешергә кирәк. Ул – бүгенге көндә безнең Япониядә иң бөек кеше. Теләсәгез, тәкъдим итәрмен, мин – аның бик күптәнге дусларының берсе.

– Бу яхшылыкны эшләсәгез, бик шат булыр идем.

– Безнең арабызда рәсмият юк, принц Ито белән бер тапкыр күрешеп танышсагыз, аннан соң һәрвакыт рәсмиятсез күрешә алырсыз. Мин тәкъдим хаты язармын һәм иртәгә сезгә җибәрермен. Сез иртәгә кайда буласыз, Токиодамы, әллә Йокохамадамы?

– Мин иртәгә Йокохамада булам, чөнки бүген кич анда бер конференция булачак. Мин дә кыска гына чыгыш ясарга уйлыйм.

Шуннан соң, Конт Окоманың бакчасында чәй эчтек, бераз бакчада йөрдек. Конт Окоманың бакчасы – Токиода иң мәшһүр бакчаларның берсе. Бераздан, саубуллашып, киттек. Мин турыдан Йокохамага кайттым. Биредә Хонҗи мәктәбенә 25 ел тулуга багышлап оештырылган кичәдә катнаштым.

Хонҗи мәктәбе

Бу – башлангыч мәктәп икән. Ачылуына нәкъ 25 ел тулган. Шул вакыт эчендә милләтенә күрсәткән хезмәте белән таныштырдылар. Тагын бер кат искәртәм: бу – башлангыч мәктәп. 25 ел эчендә мәктәптә 12314 укучы белем һәм тәрбия алган. Боларның 7086сы мәктәпнең таныкнамәсен алып чыккан.

Игътибарымны җәлеп иткән нәрсә шул булды: башлангыч мәктәп 25 ел хезмәт күрсәткән, нәрсә эшләгәне мәгълүм. Уйлавымча, безнең урта мәктәпләребезнең дә хәтта нинди хезмәт күрсәткәннәре билгеле түгел. Бар да укыган да киткән, хисабын Аллаһ белә.



Конт Окоманың хаты

Мин биредә кичәдә булдым. Башта мәктәп мөдире мәктәпнең төзелүе, ачылуы турында сөйләде, аннары шактый гына кеше чыгыш ясап, кыскача гына мактап котладылар. Сүз чираты миңа килде һәм мин болай чыгыш ясадым:

«Япон телен бик яхшы белмим, сезнең башыгызны авырттырасым да килми, ләкин шулай да, миңа күрсәткән илтифатыгыз мине берничә сүз әйтергә мәҗбүр итә.

Хезмәтләрнең иң олысы – белем һәм мәгарифкә хезмәт итү, көч-куәтнең дә иң зуры – белем һәм мәгариф. Тик милләтләрнең мәңге яшәве өчен белем генә җитми. Моның өчен әле тагын милли әхлакның һәм милли рухның саклануы кирәк. Бүген французларда белем бар, бар нәрсә бар. Тик әхлаклары булмаганга, болар – чүгәргә хөкем ителгән бер милләт. Иртәме-соңмы, французлар таркалачак. Япон милләтенә булган көчле мәхәббәтем сәбәпле, күңелемнең бөтен самимилеге белән шуны киңәш итәм: сез мәгариф өчен күп көч куйган кебек, зур тырышлык куеп, «йамата тамаши» милли әхлакны саклауга да көч куегыз. Милли рухы булмаган халык озак яши алмый. Японнарның руслар белән булган сугышта җиңеп чыгулары да милли рух аркасында мөмкин булды. Шуның белән сүземне тәмамлыйм».

Иртәгесе көнне Йамамотаның өендә кунакта идем. Почтачы безгә хат китерде, хаттан башка, бер зур конверт эчендә җеп белән бәйләнгән тагын бер төргәк бар иде.

Карадым, Конт Окома (элеккеге чит илләр эшләре министры) миңа хат язган, үзенең фоторәсемен һәм принц Ито исеменә тәкъдим хатын җибәргән.

Конт Окоманың үз кулы белән язган хатын биредә хөрмәтле укучыларым игътибарына тәкъдим итәм. Әлеге хатның эчтәлеге:

«Олы кунагыбыз Габдерәшит Ибраһим!

Ерак илләрдән шулкадәр зур мәшәкатьләр чигеп килгән хөрмәтле кунагым, олы ихтирам белдереп, кичерүегезне үтенеп сорыйм. Үзем Сезнең белән күрешергә килә алмадым, шул сәбәпле, рәсемемне җибәрәм. Сүз биргәнчә, Сезгә адресны һәм принц Итога тәкъдим хатымны яздым. Кабул итеп алыгыз, Сезнең белән тагын күрешүне өмет итәм.

10 март, Окомасики Нубу».

Шулай итеп, 11 март көнне мин принц Ито җәнаплары белән күрешергә киттем.

Төрекчәдән

***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Каһарман Гали мажаралары

Хикәят

Хәзрәти Рәсүлуллаһ мәчеттә утырганда, бер әсхаб[1], торып, үтенечен белдерде:

– Әй, Рәсүлуллаһ! Фәлән яһүдкә бурычым бар иде, дүрт мең динар, – диде. – Ике улымны гәрәү[2] куйган идем, вәгъдәсе өч көн калды, ни кылырмын? Әгәр өч көннән үти алмасам, икесе дә яһүдкә китә, – диде, һичкем җавап бирмәде.

Хәзрәти Гали торып әйтте:

– Әй, Рәсүлуллаһ! Миңа рөхсәт бир, моның эшен башкарырмын, иншәАллаһ, – диде.

Рәсүлуллаһ әйтте:

– Әй, Гали! Сабыр кыл, – диде.

Бераздан соң әсхаб, торып, тагын сорады:

– Әй, Рәсүлуллаһ! Һичкем бармы минем бу эшемне бетерердәй? – диде. Янә һичкем җавап бирмәде.

Хәзрәти Гали тагын, торып, җавап бирде:

– Әй, Рәсүлуллаһ! Мин бетерермен, иншәАллаһ, – диде.

Хәзрәти Рәсүлуллаһ:

– Сабыр кыл, йә Гали, – диде. Хәзрәти Гали утырды.

Бераз вакыт утырганнан соң, әсхаб, торып, түземсезләнеп әйтте:

– Әй, Рәсүлуллаһ! Һичкем бармы минем шул эшемне үтәрдәй? Вәгъдәсенә өч көн калды, әгәр кыла алмасам, ике улым китәдер, йә Рәсүлуллаһ! – дип елады.

Шулвакыт хәзрәти Рәсүлуллаһ галәйһиссәламнең күз алдына күренде хәзрәти Галинең фәлән шәһәргә баруы, анда бу эшне тиз арада башкаруы, нинди вакыйгалар буласы – киләчәкнең нәтиҗәсе ачылды.

Хәзрәти Гали, шул әсхабтан инде өченче тапкыр бу сүзне ишеткәч, түземсезләнеп торды:

– Әй, Рәсүлуллаһ! Рөхсәт бир, иншәАллаһ, мин бу эшне башкарып чыгармын, моңа минем сабырлыгым калмады, – диде.

Хәзрәти Рәсүлуллаһ галәйһиссәлам рөхсәт бирде.

Шуннан соң Гали хәзрәти Рәсүлуллаһ, хәзрәти Бибифатыйма, хәзрәти Хәсән, Хөсәен, чәһрейарлар белән саубуллашып, әсхабны алып, бергә юлга керделәр.

---

[1] Әсхаб – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) иярченнәреннән – яраннарыннан булган мөселман, сәхабә.

[2] Гәрәү – залог, закладка салу.

Шәһәрдән чыгып бераз барганнан соң, Гали әйтте:

– Әй, әсхаб! Күзеңне йом, – диде. Әсхаб күзен йомды.

– Күзеңне ач, әй, әсхаб! – диде. Әсхаб күзен ачты: үзен башка бер шәһәрдә күрде. Әсхаб сорады:

– Әй, Гали! Бу кайсы шәһәр? – диде.

Хәзрәти Гали:

– Бу – Бәлх[3] шәһәре, – диде.

Әсхаб сорады:

– Монда кадәр күпмелек юл? – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Атлы кешегә өч айлык юл.

Әсхаб елый башлады:

– Әй, Гали! Минем балаларым китте инде яһүдкә, – диде, – моның кебек ерак җирдән ничек итеп балаларымны коткарырмын, яһүдигә өч көн вәгъдәм калды, – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Сабыр ит, иншәАллаһ, барча эш бетәр, – диде. Әсхаб сабыр кылды.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Әй, әсхаб! Син мине: «Колым», – дип, базарга алып кереп сат. Син хуҗа бул, мин кол булыйм, – диде.

Ул көн коллар сатыла торган базар көн иде, әсхаб, хуҗа булып, хәзрәти Гали, кол булып, базарга кереп утырдылар.

Падишаһка бер кол кирәк иде. Аның бер бәге килеп, падишаһ өчен кол карап йөрер иде. Хәзрәти Галине күрде:

– Әй, кол! Хужаң кайда? – диде.

Әсхаб килде, әйтте:

– Без – хуҗа, – диде.

Бәк әйтте:

– Бу колыңны сатасыңмы, сатсаң, бәһасе нидер?

Әсхаб:

– Әй, бәк! Кол бәһасен үзе белер, – диде.

Бәк хәзрәти Галигә карап әйтте:

– Әй, кол! Бәһаң нидер? – диде.

Хәзрәти Гали:

– Ун мең динар, – диде.

Бәк әйтте:

– Әй, кол! Ун мең динарга мин йөз кол ала алам, – диде.

Хәзрәти Гали:

– Әгәр син ун мең динарга йөз кол алырга итсәң, мин шул йөз колның кылганын булдыра алам, – диде.

Бәк шул сәгать, кире кайтып, падишаһка хәбәр бирде:

– Шундый бер гаҗәп кол бар, бәһасенә ун мең динар сорый, – диде. Колның гәүдәсен, йөз-кыяфәтен сурәтләп бирде.

Падишаһ, моңа гаҗәпләнеп, базарга үзе килде. Әсхаб янына барып сорады:

– Әй, хуҗа! Колыңны ни бәһадән диярсең?

Әсхаб әйтте:

– Ун мең динар! – диде.

Падишаһ колга карап әйтте:

– Әй, кол! Ун мең динарга мин йөз кол ала алам бит, – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

[3] Бәлх – Ирандагы шәһәр.

– Анысы дөрес, падишаһ. Әмма син йөз колны эшкә боерганчы көн үтеп китә, ә мин бер әйтүеңдә йөз кол эшләрлек эшне ялгыз үзем бетерәм, – диде.

Падишаһ, сынар өчен, колны сатып алырга риза булды, ун мең динарны санап, әсхабның кулына тоттырды.

Хәзрәти Гали рөхсәт сорады:

– Әй, падишаһ! Миңа рөхсәт бир, мин хуҗаны озатып килим, аннан соң, кайтып, синең хезмәтеңә мәшгуль булырмын, – диде.

Падишаһ: «Хуш», – диде, рөхсәт бирде.

Хәзрәти Гали әсхабны озатырга чыкты, саубуллаштылар.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Хәзрәти Рәсүлуллаһка, Бибифатыйма, Хәсән, Хөсәенгә һәм чәһрейарларга күп сәламнәр әйтерсең, догалар багышларсың, сәламәт күрешик, – диде. Аллаһы Тәгаләгә ялварып, дога кылырга кулын күтәрде…

Күз ачып йомганчы, әсхаб үзен Мәдинә шәһәрендә күрде, Ходайга шөкерләр кылды. Аннан соң Рәсүлуллаһ катына барды, булып үткән вакыйганы сөйләп бирде, хәзрәти Галинең сәламен тапшырды. Моннан соң тиешле акчаларны яһүдигә биреп, балаларын коткарып, рәхәттә гомер сөрде.

Бәс, хәзрәти Гали янына килик. Ул падишаһ каршына килде, әйтте:

– Әй, падишаһ! Эшеңне боер, – диде.

Падишаһ:

– Эш шунда ки: Бәлх шәһәренә Гомуд дәрьясыннан су ташып кереп, шәһәрне баса, менә шуны киртәләп куярга кирәк, – диде.

Бер вәзирен чакыртты, аңа әйтте:

– Әй, вәзир! Бу колны алып барып, Гомуд дәрьясында торган йөз колны кайтарып, аларның урынына моны куй! – дип боерды.

Вәзир: «Хуш», – диде, Галине алып китте. Барып җиттеләр, вәзир андагы йөз колга кире кайтырга боерды. Нәрсә эшләргә кирәклеген хәзрәти Галигә күрсәтте:

– Падишаһ боерган эш Сезгә шушыдыр, – диде.

«Хуш», – дип, хәзрәти Гали калды, вәзир йөз кол белән кайтып китте.

Вәзир кайтып барганда фикер кылды: «Бу йөз кешенең кылган эшен берүзе ничек кылыр икән, бу ансат эш түгел, моны гади адәм булдыра алмас, моның бер-бер хикмәте бардыр», – дип, кире кайтып, яшеренеп карап торды.

Хәзрәти Гали: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!» – дип, тәһарәт алды, ике рәкәгать намаз укыды, Ходайга ялварды. Моның соңында торды, кулына китмән алды. Ерак түгел бер тау бар иде, хәзрәти Гали тау каршына барды: «Бисмилләһи!» – дип, тауның урта җиреннән бер чапты, өстеннән өч җирдә чапты, ярты тауны күтәреп китереп, Гомуд дәрьясының уртасына салды.

Дәрья буылды, Бәлх шәһәренә хәтта бер тамчы су килмәс булды.

Вәзир, моны күреп, таң калды. Тиз арада падишаһ катына кайтып җитешеп, бу хәбәрне сөйләде.

Падишаһ:

– Бу нинди адәм икән? – дип, борчуга төште, аны алганына курыкты. Шәһәрнең хәлен белергә тиз ат чаптырды.

«Шәһәр сусыз корып утыра», – дип кайтып әйттеләр.

Падишаһ:

– Колга сәлам әйтегез, сорагыз, шәһәргә җитәрлек су үткәрсен, – диде.

Хәзрәти Гали барды: «Бисмилла!» – дип, биш бармагын тауга сукты. Ходайның кодрәте белән, биш бармак эзеннән биш болак-чишмә чыкты, шәһәргә җитәрлек су булды.

Хәзрәти Гали, бу эшне дә тәмам кылып, башкалага кайтты. Падишаһ, аннан котылу өчен, көч җитмәслек бер эш кушарга булды. Чакырып алып әйтте:

– Әй, кол! Сиңа бер хезмәт боерам: миңа бер бакча ясап бир, агачлары яфрак ярып, кайчан ул агачлар җимеш бирсә, сине азат итәрмен, – диде.

Хәзрәти Гали:

– Хуш, булыр, – диде.

Падишаһ бер вәзиргә боерды:

– Фәлән урынга илтеп күрсәт! – диде.

Вәзир хәзрәти Галине үзе белән алып барды, шәһәрдән ерак бер комлы җирдә урын күрсәтте, үзе кайтып китте.

Хәзрәти Гали тәһарәт алды, ике рәкәгать намаз кылды, моның соңында Ходайга мөнәҗәт кылды, ялварды. Аннан соң төрле якка каранды, бер ерак җирдә тау күрде, барды, шул таудан күтәреп туфрак ташыды, тигезләде, аннары шул туфракка агачлар кадап, утыртып чыкты. Моннан соң ике рәкәгать намаз кылып, Ходайга ялварды. Ходайның кодрәтен күр: шул сәгатьтә агачларның һәммәсе яшәреп, яфраклар ярып, чәчкәләр атып, шул арада җимешләр дә пешеп чыкты.

Килик падишаһ катына. Ул, сабыр итә алмыйча, ике-өч көннән үк барып күрергә бер вәзирен җибәрде.

Вәзир барды, ерактан ук комнар эчендә бер бакча күрде. Исе китеп: «Монда һичнәрсә юк иде, бу нинди бакча икән?» – дип, якын килде. Күрде: хәзрәти Гали яшел үләннәр өстендә намаз укып утырыр.

Вәзир, гаҗәпкә калып, җәяүләп падишаһка кайтып, хәбәр бирде:

– Сахрада шундый бер бакча ясаган ки, арыклар агып ятадыр, җимешләр тәмам пешеп өлгергән, – диде.

Падишаһның ачуы килеп:

– Өзегез муенын! – дип кычкырды. Шулай итеп, вәзирне үтертте.

Шуннан соң икенче вәзирне җибәрде. Вәзир карады, күрде: нәкъ баягы вәзир әйткән күренеш. Шул сәгать кайтты, падишаһ катына кереп әйтте:

– Менә кылыч, менә баш, эшләр нәкъ шул вәзир әйткәнчә, – диде.

Падишаһ курыкты, үз-үзенә әйтте:

– Мин кол алмаганмын, үземә бер бәла алганмын икән. Гади бер адәм ничек мондый эш кылсын икән? – диде.

Гаскәрне чакырырга боерды. Җыелышып, падишаһ гаскәр белән үзе барып карарга булды. Барды, күрде, исе китте, Галине мактады.

Падишаһ хәзрәти Галине үзе белән бергә алып кайтты. Кайткач, падишаһ әйтте:

– Әй, кол! Сиңа тагын бер авыр хезмәт боерам, шуны эшләрсең, – диде.

Галине югалтырга ният кылды.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Боер, хуш булыр, – диде.

Падишаһ әйтте:

– Якын җирдә безгә буйсынуда булган бер шәһәр бар, аның каршына бер аждаһа килеп урнашкан, аңа һәр көн корбан итеп бер кеше бирәләр, юкса ул бу шәһәрне харап итә. Шунда барып, аждаһаның эшен бетереп кил, – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

– ИншәАллаһ, хуш булыр! – диде.

Падишаһ, бер вәзиренә бераз гаскәр биреп, Галине шунда озатырга боерды.

Кыскасы, шул урынга барып, бер тау түбәсенә җиттеләр. Карасалар, икенче бер тау түбәсеннән төтен күренә. Вәзир хәзрәти Галигә әйтте:

– Шул күренгән төтен явыз аждаһанықыдыр, без инде бара алмыйбыз, шул түбә башына чыксак, күрер, безнең башыбызны алыр. Син инде үзең бар, – диде.

Хәзрәти Гали: «Хуш», – диде, шунда торып калды, вәзир, гаскәре белән кайтып, падишаһка хәлне сөйләп бирде.

Падишаһ:

– Бу колдан котылдык, ахры, иншәАллаһ! – диде.

Хәзрәти Гали Ходайга мөнәсәбәт кылды, ялварды. Шулвакыт Дөлдөл дигән ат, зөлфәкар дип аталган кылыч җитеште. Хәзрәти Гали Дөлдөлнең колагына әйтте:

– Әгәр миннән өченче мәртәбә тәкъбир өнен ишетсәң, шул сәгать Рәсүлуллаһка бездән хәбәр җитештер, – диде.

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!» – дип, түбәгә чыкты. Күрде ки: бер чокырда искиткеч зур аждаһа ята, ике күзе ут кебек янып тора, сулаган саен борын тишекләреннән төтен бөркелеп тора. Хәзрәти Гали, зөлфәкарын баш түбәсенә тотып, йөгереп барып, аждаһаның авызына кереп китте, кылычы белән башыннан койрыгынача икегә аерды. «Йә, Аллаһ!» – дип кычкырды. Шул мизгел эчендә, хәзрәти Гали «әлхәмдүлилләһ!»не әйтеп бетергәнче, Дөлдөл килеп җитеште.

Аждаһаның башын кисеп алды, баягы атны куйган җиргә килделәр. Хәзрәти Гали Дөлдөлне Рәсүлуллаһка сәлам ирештерергә җибәрде, үзе, утырып килгән атына менеп, шәһәргә кайтты.

Падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ курыкты, йөзенең төсе китте. Шул мизгел падишаһның каршына аждаһаның башын китереп салдылар. Падишаһның һушы китеп, тәхетеннән егылып төште. Бераз вакыттан соң, һушына килгәч, әйтте:

– Әй, кол! Син кемсең , әйт: пәриме, фәрештәме? Ничек мондый эшләр кылдың? – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Минем каенатамның исеме – Аллаһның сөекле хак пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәллам, аның кызы, ахирәт хатыны – минем хәләл җефетем Бибифатыйма, балаларыбыз – Хәсән белән Хөсәен. Мөхәммәд пәйгамбәрнең дүрт дусты, тугрылыклы вәзирләре – хәзрәти Әбүбәкер, хәзрәти Гомәр, хәзрәти Госман, дүртенчесе исә – мин, ә минем исемем – Гали ибн Әбүталиб, – диде.

Моның исемен ишеткәч, падишаһ күңеленә шул килде: «Боларның динендә Мөхәммәд (с.г.в.), ата-ана хакы өчен җан вә башны фида итү дөрес санала. Шул хәйлә белән моның башын бетерим, котылыйм», дип уйлады. Әйтте:

– Әй, Гали! Сезнең динегездә: «Мөхәммәд (с.г.в.), атаң-анаң хакы өчен башыңны-җаныңны фида кыл», – дисәләр, – башы-җанын бирәләр, имеш, шул расмы? – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Растыр! – диде.

Падишаһ:

– Әгәр шулай икән, без шуны теләсәк, син шуны эшләрсеңме – җаныңны фида итәрсеңме? – диде.

Хәзрәти Гали:

– Фида итәрмен, – диде.

Падишаһның теләген хәзрәти Гали кабул кылды, буйсынды. Тиз заман аяк-кулларын богаулап, зинданга салдылар. Башкалага якын булган шәһәр әмиренә:

– Мин Галине тоттым, зинданга салдым. Фәлән тауның түбәсенә фәлән көндә җитешегез, бергә хөкем кылып, үтерик, – дип хәбәр бирделәр.

Хәбәр барып ирешкәч, тиз заман шул тау түбәсендә җыелышып-җыелышып тордылар. Шул сәгать мәйдан уртасына хәзрәти Галине китерделәр, мәйдан тирәсендә, түгәрәкләнеп алып, ялан кылычлы җәлладлар басып тордылар.

Шул мизгел хәзрәти Җәбраил фәрештә Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәлламгә күктән иңеп килде, сәлам әйтеп, хәбәр бирде:

– Хира тавының башына чыгып карагыз хәзрәти Галинең сезнең өчен җан вә баш фидасының һиммәтен, бөеклеген, – диде.

Хәзрәти Рәсүл, хәзрәти Бибифатыйма, Хәсән белән Хөсәен, хәзрәти Әбүбәкер, хәзрәти Гомәр, хәзрәти Госман һәм башка сәхабәләр карап күрделәр (Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән): хәзрәти Гали якын арада каршыларында тора.

Шулвакыт падишаһ җәлладларга:

– Орыгыз Галинең муенын! – дип боерды. Бер җәллад уртага чыкты, башын чабып өзәргә дип, кылычын баш өстенә күтәрде. Кулы шул күтәрелгән килеш катып калды, ора алмады. «Икенче кулым белән чабыйм», – дип, кылычын икенче кулына алып, югары күтәрде – ул кулы да катып калды.

Икенче җәлладка боерды, шул хәл аның белән дә булды, аннан соң өченче, дүртенче җәлладка боерды – һәммәсенең куллары шулай катып калды.

Янә падишаһ әйтте:

– Әй, Гали! Син һаман ихтыярыңны тулы ышаныч белән биргәнең юк икән, – диде.

Хәзрәти Гали җаны белән тоеп торды: Рәсүлуллаһ, Бибифатыйма һәм чәһрейарлар Ходайдан хәзрәти Галинең сәламәтлеген, иминлеген теләп торыр иделәр. Шулардан илһам алып, хәзрәти Гали: «Бисмиллаһ!» – дип Ходайга сыенып, кулларын, аякларын сузды, богаулары, тәмам өзелеп, җиргә төште. Тора салып, кулы белән падишаһның якасыннан тотып каршына китереп, әйтте:

– Әй, кәфер! Динсез! Минем ышанычым, иманымда синең ни эшең бар?! Аллаһы Тәгаләнең сөеклесе Мөхәммәд галәйһиссәлам, ахирәт хатыны Бибифатыйма һәм чәһрейарлар карап, бу хәлне күреп, Ходайдан миңа ярдәм теләп торалар. Әй, кәфер, минә кара! – дип, падишаһның ике күзе турысына бармакларын куйды.

Падишаһ карады, күрде: барчасының җисемнәре нурланып торалар. Падишаһ сорады:

– Әй, Гали! Фәләнчәсе кем?

– Ул – Аллаһның сөеклесе Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәссәлламдер. Ә анысы – ахирәт хатыны Бибифатыйма – минем хәләлемдер, ике янында ике улы – Хәсән белән Хөсәендер, ә калганнары – чәһрейарлар – Әбүбәкер Сыйддыйк, Гомәр, Госмандыр, – диде.

Падишаһ әйтте (Ходай Тәгалә күңеленә илһам нуры, иман бирде):

– Тиз миңа иман китерүне өйрәт, юкса миндә тәкать[4] калмады. Әгәр синең динең рас булмаса, мондый эш кылу мөмкин түгелдер, – диде.

Хәзрәти Гали аңа шәһадәт кәлимәсен[5] өйрәтте, падишаһ:

– Әшһәду әллә лә иләһә иллә Аллаһ, вә әшһәду әннә Мухәммәд габдүһү вә рәсүлуһү! – дип, иман китерде, мөселман булды. Шул җирдә кырык биш мең кәфер мөселман булды, барча гаскәр белән шәһәргә керделәр.

Хәзрәти Гали, ничә көн шул шәһәрдә торып, дин-шәригать кагыйдәләрен өйрәтеп, ничә көннәрдән соң, хәзрәти Гали падишаһтан рөхсәт сорады:

– Мин инде Рәсүлуллаһ каршына кайтыйм, миңа рөхсәт бирегез, – диде.

Падишаһ әйтте:

– Әй, Гали! Безне дә Рәсүлуллаһ катына алып бар, – диде.

Хәзрәти Гали әйтте:

– Бездән соң килерсез, – диде.

Хәзрәти Галине, ничә көнлек җиргә кадәр килеп, гаскәре белән озатып калдылар. Хәзрәти Галигә күп маллар биреп, күп теләкләр теләп, хөрмәт итеп җибәрделәр.

Хәзрәти Гали, сау-сәламәт килеш, Мәдинә Мөнәүвәрәгә җитеште. Күп мал һәм хезмәтчеләр белән Рәсүлуллаһ, чәһрейарлар, хәзрәти Бибифатыйма, Хәсән, әсхаблар, каршы чыгып, Гали белән күрештеләр, шатланышты-куаныштылар. Башыннан үткәннәрне сөйләп, барысының да күңелләре хуш булды.

Беркадәр заманнан соң, падишаһның күп гаскәр белән Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вәссәлламгә күрешергә килүен бәян иттеләр. Күп-күп кыйммәтле мал белән Мәдинә Мөнәүвәрәгә килеп, якын төшеп, аннан соң хәзрәти Рәсүлуллаһ галәйһиссәлам белән күрешеп, игелекләр күрсәтеп, ахыр падишаһ югары дәрәҗәгә ирešте.

*Текстны журналга **Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль** әзерләде.* ■

[4] Тәкать – сабырлык, чыдамлык.

[5] Шәһадәт кәлимәсе – Лә иләһә иллә Аллаһ, Мухәммәд рәсүлуллаһ.

Безнең мирас №4 апрель 2020

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ *татар китабы*

Хатыйп Миңнегулов,
КФУ профессоры

«МИН – БӘХЕТСЕЗ ТАТАР УЛЫ...»
(Шиһаб Нигъмәти. – 1913-1995)

Ш.Нигъмәтинең шигъри дөньясында, гомумән, тормышчанлык, реаль чынбарлыкка нисбәтле фикерләү өстенлек итә. Мәсәлән, автор, гәрчә үз милләтен өзелеп сөйсә дә, аның яшәешендәге аерым кимчелекләрне дә күрсәтә. «Татар хатыны» шигырендә Алтын Урда, Казан мәмләкәтләренең бетүендә «милләтнең пычрак хаиннары»н гаепләп, аларны кискен тәнкыйтьли. «Аерылма» әсәрендә ул башка милләтләргә мөкиббән китеп, үз халкының телен, моңын онытучыларны акылга килергә чакыра: *«...Үз халкыңның янына кил! Аның белән бергә син дә җыла, Аның белән син дә бергә көл»* [4:5-6]. Шуның белән бергә, 1953 елда дөнья күргән җыентыкта романтизм әдәбиятына, аеруча символизмга хас булган аерым сыйфатлар, образ-детальләр дә күзгә ташлана. «Кораб» парчасы [4:33] – шуның ачык бер мисалы. Ул, гәрчә автор тарафыннан искәртелмәсә дә, Дәрдемәнд шигыренә нәзыйрә рәвешендә язылган:

Әнә диңгез, ә диңгездә
Йөзеп бара бер кораб.
Үзе торган илен ташлап,
Ерак илләргә карап...

Алга таба автор, үз элгәргесеннән үзгә буларак, шигырьнең эчтәлеген киңәйтә, аны өстәмә күренеш-детальләр белән дә баета.

Кан коюлы сугышның үзәгендә кайнаган Ш.Нигъмәти бу дәһшәтнең гайре табигыйлеген, адәм балаларын бәхетсез итүен, «көне-төне суда, карда һәм күктә яңгыраган кара туплар»ның «мәхәббәт йолдызларын сүндерүен» яхшы аңлый [4:23], аның кай тарафлардан башлануын да конкрет күрсәтә: *«Көнбатыштан килде туп тавышы, Канлы сугыш анда башланды»* [4:9]. «Төрек дөньясы» дип исемләнгән әсәрендә автор «Көнбатыштан» килгән афәтнең тормышны пыран-заран китерүен, «миллионлаган йортларны» җимерүен, балаларны ятим, аналарны баласыз калдыруын искәртә [4:20]. Шагыйрь карашынча, гәрчә дөнья сугышы тәмамланса да, кешеләрнең тереклеге әле һаман куркыныч астында. *«Безнең тормыш – бензин савыты, Әйләнәсе аның ут кебек»*, – ди ул 1945 елның октябрендә язган бу шигырендә [4:12].

Мәгълүм ки, күп гасырлар буе төрле сугышларда катнашып килгән Төркия Икенче Бөтендөнья сугышында, нигездә, битарафлык саклый. Аның бу позициясен Ш.Нигъмәти хуплый, Истанбулның төрек дөньясы өчен «кыйбла» кебек булуын да искәртә [4:20-21].

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2020) санында.

Эфир вакытында (сулдан уңга): Ш.Нигъмәти, Г.Солтан һәм Ф.Исхакый

Үзенең чордашы, язмышташы Минһаҗ ага Исмәгыйли кебек, Ш.Нигъмәти дә әсирлек, сугыш, сагыну темалары белән генә чикләнмичә, дөньяның глобаль мәсьәләләре хакында да уйлана. Бу яктан аның «Уян, Шәрык» шигыре игътибарга лаек. Халкыбызның күпгасырлык рухи тормышы [дине, фәне, мәгарифе, әдәбияты] Мөселман Көнчыгышы, ягъни Шәрык белән бәйле. Шуңа күрә дә шагыйрь өчен бу темага мөрәҗәгать итү бик тә табигый, мантыйкый. Ш.Нигъмәти Урта гасырларда дөнья цивилизациясенең мөһим үзәге булган Шәрыкның яңа заманда күпләрдән артта калуына борчылуын белдерә, аны уяныргa чакыра:

Уян, Шәрык, уян инде,
Нигә йоклап ятасың?!.
...Уян, Шәрык, ач күзеңне,
Әйләнәңә ач та бак!
Шушы пычрак тормышыңнан
Үзеңә чыгу юлын тап!..

Автор Шәрык дөньясын заманга туры килми торган иске гадәт-йолалардан, күренешләрдән арыныргa өнди. Әмма бу урында аның бер искәрмәсе аеруча мөһим: *«Тик онытма, һич онытма Алланы!»* – ди ул [4:35].

Җәмгыятьтәге гаделсезлекләр, «пычраклык», бозыклык шагыйрьнең җанын телгәли. «Бирегез канат» шигырендә [4:27] ул, чарасызлык чоңгылына төшеп, «караклар», «җәлладлар» оясы булган бу җирне ташлап, «башка планета»га күчү теләген дә белдерә:

Аһ, бирегез миңа ирек!
Бирегез канат,
Биеклеккә таба очыйм!
Башка планетага мин күчим!

Ш.Нигъмәти бер парчасында бу дөньяның ялганга, алтынга корылуына борчылуын белдерә, аңа алданмаска чакыра: *«Кышың киң түгел, кызың тиң түгел, Барысы ялган, берсе чын түгел»* [4:23]. 1953 елгы җыентыкта иҗтимагый, сәяси, әхлакый мәсьәләләр

белән беррәттән, еш кына алар белән бәйләнештә мәхәббәт темасы да яктыртыла, пейзаж лирикасы үрнәкләре дә бар.

Ш.Нигъмәти шигырьләре үз чорының татар язма әдәби телендә иҗат ителгән. Себер шивәсенә генә хас элементлар юк дәрәҗәсендә. Кайвакытта сүз башында «е» авазын «җ» хәрефе белән бирү күзгә ташлана (егет – җегет, елау – җылау, ямьле – җәмле…).

Автор үз әсәрләренә эчтәлек-мәгънәгә, төп аһәңгә туры килешле, кыска, матур яңгырашлы исем-атамалар бирә белгән («Көтә микән», «Аерылма», «Әйтче», «Тыңлар идем», «Җырла, егет!», «Югалттым» һ.б.). Аның кайбер шигырьләре көй-музыка язуны сорап тора. Аларда татарның образлы фикерләвенә, сүз сәнгатенә хас сыйфатлар шактый.

Ш.Нигъмәти, строфалар, шигъри үлчәмнәр куллануда традиционлыкны саклау белән бергә, аларга теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр дә кертә, чагыштырмача иркенрәк форма-кысаларда да язып китә («Шаулый камыш», «Мөмкин түгел» һ.б.).

Җыентык авторы, эстетик максатны күздә тотып, бер шигырьдә бер үк сүзләрне, юлларны кабатларга ярата. Мәсәлән, «Сөям» парчасындагы өч строфа да «Сөям, илем…» сүзләре белән башлана [4:39]. «Җырла, егет!» шигыренең бөтен композициясе кабатлауга корылган:

Җырла, егет, мин тыңлыймын,
Җырла моңлы җырларың!
Җырла, егет, күргәннәрең,
Җырла үткән елларың... [4:14].

Күрәсез: бу төр кабатлау уй-кичерешләр дулкынын көчәйтүгә, шигырьнең тәэсир көчен арттыруга ярдәм итә.

Ш.Нигъмәти китабындагы шигырьләрдә эндәш-мөрәҗәгать, риторик сорау, рәдиф, эчке рифмалашу һәм кайбер башка төрле әдәби чаралар иркен файдаланыла. Еш кына аларның берничәсе берьюлы да кулланыла. «Әкертен, җил» шигырендә, мәсәлән, кабатлау һәм юлбаш анафора да, эндәш-мөрәҗәгать тә бар:

Әкертен, җил, монда – кабер,
Монда адәм күмелгән.
Монда ятим яшь баланың
Күз яшьләре түгелгән!
Әкертен, җил, әкертен ис,
Туздырма чәчкә-гөлен... [4:42].

«Авырый башым» парчасындагы әсәр атамасы, һәр строфада икешәр мәртәбә кабатланып, лирик геройның рухи һәм физик халәтен, күңел тынгысызлыгын ачуга булыша. Ахырда, халык җырларындагы кебек, шартлы җавап та бирелә:

Авырый башым, түзәр хәл юк,
Әллә чәчем җиткәнгә?
Әллә авырый микән башым,
Ялгыз читкә киткәнгә?..
...Авырмас иде башкаем, –
Минем язмышым кара [4:26].

Күргәнебезчә, Ш.Нигъмәтинең «Шигырьләр» җыентыгы, гәрчә кечкенә күләмле булса да, эчтәлеге, идея-проблематикасы, образ-сурәтләре, кулланылган әдәби чаралары белән шактый бай һәм күптөрле. Без исә, бу язмабызда аның кайбер якларына, төп хосусиятләренә генә тукталдык.

Татар рухи дөньясында мөһаҗирлектә иҗат ителгән шактый гына әсәрләр бар. Алар арасында Ш.Нигъмәти шигырьләре дә үзенә лаеклы урынны били. Шунысын да искә төшерик: илдән читтә иҗат итүчеләр арасында Түбән-Тубыл якларында туып үскән

Әсфәндияр Ишгай (Исфәндияр Чынбай) да бар (1908–16.06.1992). Ул да, якташы, чордашы Шиһаб Нигъмәти кебек, 1941 елның ахырларында әсирлеккә эләгә, зиндан-лагерь газапларын чигә, Алманиядә татар милли хәрәкәтендә катнаша. 1948 елда Төркиягә күчеп китә. Берничә китап бастыра. Шунда ук вафат та була.

Шиһаб Нигъмәтинең тормышы, эшчәнлеге әле тиешенчә өйрәнелмәгән, хәтта әле аның тәрҗемәи хәлендәге төп моментлар да тәмам ачык түгел. Минһаҗ ага Исмәгыйли бу затның әдәби иҗат белән 1953 елгы җыентыгы чыкканнан соң да шөгыльләнүен искә ала иде. Аның шәхси архивы кайда? Туган-тумачалары да булырга тиеш. Төмән университеты профессоры, күренекле җәмәгать эшлеклесе Ханисә ханым Алишина раславынча, урыс телендә язучы Төмән төбәге шагыйре, тәрҗемәче Николай Шәмсетдинов – Ш.Нигъмәтинең бертуган сеңлесе Йомабикәнең улы икән. Шиһаб аганың алман хатынынннан туган Сания исемле кызы булуы да билгеле. (Бу мәгълүматны һәм Ш.Нигъмәтинең фотосурәтен җибәргәне өчен, Ханисә ханымга ихласи рәхмәт!) Мондый фактлар әле тагын да бардыр. Әмма, ни кызганыч, шәхсән аларын хәзергә белмим. Шуңа күрә бу язма, алдагылары кебек, Көнбатыш Себердән чыккан татар шагыйренең иҗатын өйрәнүдәге бер баскыч буларак кына кабул ителергә тиеш.

* * *

Мәкаләдә инде Ш.Нигъмәтинең 1953 елда латин графикасында нәшер ителгән «Шигырьләр» китабыннан аерым әсәрләр, өзекләр китерелде. Шуларга өстәп, укучыларга шагыйрьнең янә ике шигырен тәкъдим итәбез. Әйткәнебезчә, алар оригиналдагыча калдырылды, өстәмә-төзәтмәләр кертелмәде. Атамасыз парчаларга исемнәр, тексттан алып, безнең тарафтан куелды. Алар квадрат җәяләр эчендә күрсәтелде.

Ш.Нигъмәти

Шиһаб Нигъмәти шигырьләре

Тапмадым

Гүзәл иде мин үскән ил:
Чиксез аның урман-кырлары.
Бизәлгәннәр төрле чәчәкләргә
Урманнары, елга буйлары.
Шул гөлләрнең берсен өзеп,
Күкрәгемә алып такмадым.
Үз илемнән, яшьлегемнән
Гүзәл(е)рәк чәчәк тапмадым.

Югалттым

Югалттым мин бу дөньяда,
Югалттым шул барысын да.
Хыялларым гына калды инде, –
Югалтырмын микән анысын да?!
Үткән көннәрдән ядкәр булып
Калды милли моңнарым.
Үлгәнче мин югалтмамын
Хыялларым белән җырларым. ■

Җиңүгә – 75 ел

Идел һәм Муса

(Чын хикәя)

Мәхмүт Хәсәнов

Бу вакыйга булганга да бик күп еллар үтте инде. Бәлки, шуңа күрәдер, ул көн дә гадәттән тыш булып искә төшә... Ул көнне, чыннан да, бернәрсә дә гадәттәгечә түгел иде кебек. Искиткеч аяз иксез-чиксез күк йөзе. Гадәттән тыш зәңгәр, мул сулы киң Идел... Дулкыннар өстендә, уйнаклап, ап-ак акчарлаклар оча. Хәтта пароходлар да ул көнне гадәттәгечә түгел иде. Җиңел йөзәләр, ә үзләре, нәкъ һавада очкан акчарлаклар кебек үк, күз явын алырлык ап-аклар...

Без, бер төркем яшьләр, Маркиз утравында ял итә идек. Идел өсте тулы көймәләр. Барысында да ял итәргә чыгучылар. Көймәләр, көймәләр... Исәбе-хисабы юк аларның.

Арабыздан берәү, әле генә яр буена килеп туктаган моторлы көймә ягына күрсәтеп, әйтә салды:

– Карагыз!.. Әнә, әнә... шагыйрь Муса Җәлил!

Бер кеше кебек булып, шул якка борылдык.

– Кайсысы?

– Соң, әнә инде!

– Әле генә ярга сикереп төшкәнеме?..

Сай булгангамы, көймә яр буена ук килеп җитә алмаган. Шунлыктан көймәдәгеләргә, аяк киемнәрен чылатмас өчен, берәр метр чамасы араны сикереп үтәргә туры килә иде.

Муса абый да көймәнең борын өлешенә якынайды һәм ярга сикереп төште. Аксыл күлмәген җилкәсенә салган. Тәне кояшта тигез булып янган аның. Йомры җилкәләренә, мускуллары уйнаклап торган нык беләкләренә һәм гәүдәсен гаять дәрәҗәдә төз тотуына караганда, ул, шагыйрь булудан бигрәк, спортчыга күбрәк охшаган иде.

Үзе генә булмаган икән Муса абый. Сикереп төшү белән, көймә ягына борылып, кулын сузып, җиңел күлмәк кигән нәфис кенә буй-сынлы бер хатын-кызга да төшәргә ярдәм итте. Шунда ук алар, көлешә-көлешә, аяк киемнәрен салдылар да кайнар комлы сукмак буйлап өскә таба күтәрелә башладылар...

Ул вакытта инде Муса Җәлил безнең сөекле шагыйребез иде: йотлыгып ялкынлы шигырьләрен укый, дәртле җырларын җырлый идек. Шунлыктан аның белән кызыксынуыбыз да чамадан тыш булган, күрәсең, без аларны күздән яздырмаска тырыштык...

Өскә – куе әрәмәлеккә күтәреләләр дип курыккан идек. Юк, яр буенда, бөдрә башын Иделгә таба иеп үскән куе таллык күләгәсендә туктады алар. Бераздан Муса абый да, аның юлдашы да, мәш килеп ял итүчеләрнең һәркайсы кебек үк, су коену костюмнарыннан гына калдылар.

Шулвакыт Муса абый тал төбенә җыеп куйган чалбар кесәсеннән әллә ни зур булмаган куен дәфтәрен чыгарды да юлдашына нәрсәдер укый башлады.

Гади генә нәрсә укымаганлыгы хәрәкәтеннән үк күренеп тора иде аның. Үзенә җайлы урын таба алмаган кеше сыман, ул йә тезләнә, йә яңадан утыра, һаваны ярып,

Муса Җәлил кызы Чулпан белән. 1940 елның 5 сентябре

куллары белән ишарә ясап куйгалый. Бер мизгелгә укуыннан бүленеп, юлдашына нәрсәдер аңлатып алырга да өлгерә…

Аларның чак кына үзәнлерәк урында утыруларыннан файдаланып, якынлаша башладык… Сиздермичә генә, әлбәттә. Бер дә исебез китмәгән кыяфәт белән, билгеле. Янәсе, безнең урыныбыз да нәкъ алар тирәсендә…

Шулвакыт мин, гомеремдә беренче тапкыр буларак, Муса абыйның тавышын ишеттем. Укыган нәрсәсе дә гади шигырь генә түгел иде аның:

Маркиз утравы. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәрге фото. 1957-1958 нче еллар

Балаларым Алтын Урдадан.
Килмешәк хан килеп бу илгә,
Кан һәм кылыч белән ханлык төзеде,
Үз хөкемен куйды Иделгә.
Коллык сөймәс безнең бабабыз,
Килмешәк хан белән сугышып,
Һәлак булды...
Явыз аждаһа
Кисте аның соңгы сулышын.
Мин тол калдым. Сезне еланның
Ерткыч тырнагыннан яшердем.
Хан әзерләп килгән монда хәзер
Сезнең канны, минем яшемне.
Тик, улларым, шуны белегез,
Тез чүккәнче ханга кол булып,
Аягүрә сугышып үлегез!..

Тугзак ана, тирмәдән кылыч алып чыгып, иң кече – тугызынчы улына бирә. Ирек өчен көрәштә бу улы да башын сала… Хан ананы да әсир итә, җәзалый. Ике күзен чукытып алдыра, аяк табаннарын яндыра…

Беркадәр вакыт үткәч кенә, мин Муса абыйның атаклы «Алтынчәч» либреттосын укыганлыгын белдем. Һай, бу тормыш дигән нәрсә! Соңрак миңа, артист булып, хәтта бу операда катнашырга да туры килде. Тик ул вакытта Муса абыйның исемен телгә алу гына да җинаять булып санала иде. Әмма либреттоны беренче тапкыр ишеткән вакытым һәрвакытта да күз алдымда булды минем.

Менә ул, чиксез бирелеп, чын-чынлап дулкынланып, кулларын болгый-болгый укый.

Тугзак карчыкның бердәнбер исән калган оныгы – Җик. Ул инде егет булып үсеп җиткән. Ана-карчык аны да көрәшкә озата.

Җик:

Дусларым, борчылмагыз...
Кояш дәрт бирде миңа,
Җир сәләт бирде миңа!
Сер сынатмас атым бар,
Җирдә ятмас халкым бар,
Юханы юк итәргә
Илгә биргән антым бар.
Ризалык бир, әбкәй, ялгыз көрәшкә!

(Тугзак алдында тезләнеп баш ия.)

Тугзак (акрын гына Җикне кулбашларыннан тотып торгыза һәм тыныч кан белән):

Идел-Чулман арасы –
Тугзак батырның иле.
Тугыз батыр анасы –
Тугзак әби мин идем.
Син – иң кече туруным,
Синдә әткәң каны бар.
Тугыз батыр улымның
Сәләте, дәрманы бар.
Ук-җәяңне ал, улым!
Яуга каршы бар, улым!
Тугыз батырның үчен
Кулупайдан ал, улым!..

Ә Муса абый, илһамланып, укый да укый. Ул бу минутта бернәрсә дә күрми, бернәрсә дә ишетми иде булса кирәк. Чөнки алар белән без генә түгел, тагын бик күпләр кызыксынганнар икән. Әнә, Муса абый белән аның юлдашы урнашкан нәни генә үзәнлекне яшьләр, җыелып, тирә-яктан шактый тыгыз боҗра итеп чорнап та алганнар. Тик Муса абый белән аның юлдашы гына моны сиздермиләр иде.

Муса абый укый да укый:

Тугзак (хан каршына килеп):

Тукта, ханым!
Мине таныйсыңмы?
Сиңа килдем бүген кунакка.
Күзем күрмәсә дә, кан исеннән
Мин таныдым сине ерактан.

Хан (каушап):

Тугзак... Ул исән...
Кит!.. Кит!.. Күз алдымнан югал!..

Тугзак:

Тугзак ана күзен чукып алып,
Качалмадың илнең күзеннән,
Тугзак ана табан астын ярып,
Котыла алмадың илнең үзеннән.
Бетермәкче идең ыругымны,
Менә – үзем, менә – улларым.
Халык мәңге үлми.
Йә, сиздеңме,
Кыскарганын канлы кулларың?..

Дошман җиңелә. Халык шатлана, тантана итә.

Муса абый финал хорының: «Алтын кояш нурларында, ямьле Идел буйларында...» дигән соңгы сүзләрен укыды да менә шул, дигәндәй, тынып калып, дәфтәрен япты. Әмма дөньясын онытып тыңлап утырган юлдашы авыз ачарга да өлгерә алмады, шулвакыт бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Үзәнлекнең безгә каршы ягында торган бер төркем яшьләр (студентлар иде бугай) дәррәү кул чаба башладылар. Аларга, билгеле инде, без дә кушылдык...

Бу көтелмәгән хәлдән Муса абый аптыраште калды. Уңайсызланды. Аннары, сикереп торып, куен дәфтәрен җәһәт кенә киемнәре астына кыстырды да, үзләрен чорнап алган халыкны ерып чыгып, аска таба йөгерде. Һәм, йөгереп килгән шәпкә, Иделгә кереп тә чумды.

Колачын киң җәеп, әле генә өскә таба менеп киткән зур пассажир пароходының дулкыннарында чайкала-чайкала йөзде ул. Аның шәп кенә түгел, хәтта матур итеп йөзүенә сокланып, байтак вакыт карап тордык. Бераздан инде ул, шактый ерагаеп, Идел уртасында коенучылар арасында күздән югалды.

* * *

Хәзер инде Маркиз утравы юк. Су астында калды. Шулай ук Идел дә үзгәрде. Хәзер инде таң кебек якты булып, җыр кебек матур булып, ишелә-ишелә аккан яңа Иделне таный да алмас идең, Муса абый. Өзелеп яраткан, күп сандагы җырларыңда назлаган Иделең, нәкъ синең исемең кебек, хәзер зур ул, бөек ул!.. ■

Җиңүгә – 75 ел

Һәр солдатның үз язмышы

(Әнәс Галиевнең тууына 100 ел)

Әнәс Галиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гариф Ахунов, Нур Гыйззәтуллин

Фаҗигале тормыш кичергән бу фидакяр милләтпәрвәр – Әнәс Галиевнең (1920-1996) бу көннәрдә 100 яшьлек юбилее билгеләп үтелергә тиеш. Ул Татарстанның хәзерге Арча районына кергән Кушлавыч авылында Мөхәммәткасыйм исемле указлы мулла гаиләсендә 1920 елның 3 апрелендә туган. Аның язмышына бары тик кыйналулар-кыерсытылулар гына язылып куелган, диярсең.

Фатиһ Кутлу миңа «100 сорауда Аяз Гыйләҗев» дип аталган сораулар тезмәсе биргән иде. Рәхмәт төшкере! Үткәнем, Аяз белән яшәвебез турында ниндирәк юнәлештә язып калдырырга дип баш ватып йөргәндә, шул сораулар, миннән җавап таләп итеп, өстәл артына утырырга мәҗбүр итте. Алар арасында: «Әнәс Галиев әсәрләренә алынуы?» – дигән сорау да бар. Аяз Әнәс абый белән 80 нче елларда аралаша башлады. Әнәс абый яшь чагында шигырь язу «чире»нә юлыккан. Сугыш, әсирлек җәзаларын үтү чорында проза әсәрләре язарга керешкән. Нәшриятлар ул елларда «кыерсытылганнар»дан читтәрәк булуны хуп күрәләр иде. Ә Аяз исә андыйларны, алны-артны карамыйча, үзенә якынайтты. Әнәс абыйның әсәрләрен әдәби яктан эшкәртеп, аларны бастыру артыннан да йөрергә тырышты. Ул Аязга бик рәхмәтле булды. Озын сүзнең кыскасы: Әнәс абыйның «Һәр солдатның үз язмышы» повестеннән өзек тәкъдим итеп, аның рухын шатландырасым килде. Бу повесть язучы автобиографиясенең солдат елларындагы башлангыч өлеше...

* * *

1941 елның апрель башында безнең 268 нче КАПны – корпус артиллерия полкын – Краснодардан Кировоградка күчерделәр.

Полк сугыш техникасының соңгы казанышларын исәпкә алып коралландырылган иде. Яңартып ясалган озын көпшәле, еракка ата торган бер йөз егерме ике миллиметрлы гаубицаларны көчле тракторлар тарта, ә сугышчылар кузовлары махсус көйләнгән автомашиналарга утырып йөри.

Кировоградка без берничә эшелон булып килдек. Вагоннардан вокзал артындагы запас юлга кертеп бушаттылар да шуннан дүрт-биш чакрым читтәге агачлык эченә урнашкан лагерьга алып та киттеләр.

Без палаткаларда яши башладык. Кар эреп беткән булса да, салкын иде. Кичләрен өсне чишенеп одеал астына кергәндә яки иртән торып физзарядкага басканда, тешкә теш бәрелә.

Краснодардан соң мондагы лагерь режимына өйрәнү кыен булды. Анда чакта без шәһәргә еш чыгып йөри идек. Мин татар клубына бара идем. Әйе, Краснодарда татар клубы бар иде. Ул үзәк урамдагы – Красная урамындагы зур йортның беренче катында урнашкан иде.

Шәһәрдә татарлар шактый күп. Аларның барысы да диярлек – Пенза ягыннан күчкән мишәрләр. Күбесе сәүдә оешмаларында эш майтара. Шәһәрнең төрле почмакларында яшәгәнлектән, очрашу өчен буш вакытларында клубка җыелалар. Клуб кичләрен халык белән тулы була. Китапханәсе бар. Казаннан гел китаплар алдырып торалар. Драмтүгәрәк эшли. Бер мәртәбә «Галиябану»ның соңгы репетициясенә туры килдем. Үзешчән артистларның уеннарын бик теләп карап утырдым.

Яшь вакыт – яшь вакыт инде. Чибәр генә бер татар кызы белән танышып, мәхәббәт утында да яна башлаган идем…

Менә шундый иркенлектән соң, монда – Кировоград янында лагерьда ябылып яту бик авыр тоелды, әлбәттә. Өстәвенә, занятиеләр бик каты иде. Еш кына төннәрен сугышчан тревога була. Тәмле йокыдан уятып, ут капкандай алып чыгып китәләр дә, уннарча километр җир йөгертеп, кире лагерьга алып кайталар. Йөгерү генә булса бер хәл иде, туктатып окоп казыталар. Берсен казып бетермисең, икенче җиргә йөгертеп күчерәләр. Ә көндезен расписание бозылмый, иртәдән кичкәчә өйрәнүләр дәвам итә.

Мин топовзводта исәпләүче булып хезмәт итә идем. Безнең исәпләүләр отделениесендә – югары һәм урта белемле егетләр. Ә отделение командиры – өч класс белемле Зорин фамилияле сержант. Ул украинлы иде. Украинлыларга хас акцент белән сөйләшә. Хезмәт срогын тутырганнан соң, армиядә үзе теләп калган. Шулкадәр теләп хезмәт итә ки, аның өчен гүя солдат хезмәтеннән дә изгерәк бүтән бер эш тә юктыр кебек. Командирлар алдында чәче белән җир себерергә әзер. Бик чиста йөри. Кирза итеге көзгә кебек ялтырый. Гимнастеркасына акбүз яканы көненә ике-өч мәртәбә алмаштырып тегә.

Артиллериядә исәпләүче хезмәте ул вакытта ук инде иң кимендә урта белем таләп итә иде. Чөнки ут ача торган ноктаны батарея белән бәйләр өчен, шактый катлаулы исәпләүләр ясарга кирәк. Безнең сержант әзер формулалар белән эш итә иде. Ул аларны бик тырышып яттан бикләгән һәм һәр сугышчыдан шуны таләп итә. Шул формулалардан тайпылып исәпләгән мәгълүматларны кабул итми. Аларны бүтән юллар белән дә исәпләү мөмкин булуын хәтта башына да сыйдырмый.

Сүз уңаеннан, әле Краснодарда чагында ук, бер поэма тәмамлап, Казанга – Язучылар берлегенә җибәргән идем. Муса Җәлилдән сөенечле җавап та алдым: «Поэмагыз ошады. Альманах чыгарырга җыенабыз. Әсәрегезне шул альманахка тәкъдим итәргә уйлыйбыз. Ләкин исемен алмаштырырга туры килер, «Сайрый тургай» килешеп бетми». Поэманың шуннан соңгы язмышы миңа билгесез. Кульязмасы үземдә калмады. Альманах чыккандырмы, юктырмы – белмим. Поэма дигәнем кып-кызыл итеп язылган

озын бер шигырь иде. Вакыты шундый, нәрсә генә эшләсәк тә, барысын да Сталин исеме белән бәйли идек. Танылган шагыйрьләр: «ул исем – балалар тел ача торган исем» дип язганда, безнең кебекләргә нишләргә иде соң?!.

Ә иҗат итү теләгем зур иде. Әмма шигырь язуым өчен отделение командиры сержант Зорин мине эзәрлекли үк башлады. Беркөнне мендәр астымнан кулъязмаларымны алган. Алар латин хәрефләре белән язылган иде, чөнки безне мәктәптә яңалифчә укыттылар. Шуңа күрә миңа латин хәрефләре белән язу җиңелрәк иде.

Минем кулъязмам сержант күңелендә шик тудырган. Ул мине ниндидер ярамаган эш белән шөгыльләнүдә гаепләргә чамалый башлады. Һәм миңа үземнең нәрсә язуымны әйтүдән башка чара калмады. Тик аны әйтеп кенә ышандырып булмады. Казан дәүләт китап нәшрияты чыгарган шигырьләр җыентыгымны күрсәтергә мәҗбүр булдым. Бу вакытта минем ике шигырь җыентыгым бар иде. Дөресрәге, бер ярым җыентык. Беренче җыентык 1938 елда яңалиф белән басылып чыккан иде. Аның беренче өлешендә – Әгъзам Камал шигырьләре, икенче яртысында минем шигырьләр иде.

Ул елларда вакытлы матбугатта, шул исәптән, «Совет әдәбияты» журналында (хәзерге «Казан утлары») шигырьләрем еш басылды. Әгъзам Камал да шигырьләрен еш чыгарды. Ул, тиз арада бер җыентык әзерләп, нәшриятка илтеп бирде. Редактор булып эшләгән Зәкия Садыйкова икебезнең җыентыкларны, ни өчендер, бер китап итеп чыгарды. Җыентыкта Әгъзам Камалның «Җилфердә, байрак» дигән шигыре бар иде. Китапка шул исемне куйдылар.

Икебезнең шигырьләр бер китап булуга мин канәгать, чөнки Әгъзам белән дус идем. Без Казан финанс-экономика техникумында укыганда таныштык. Ул техникумны миннән ике ел алда тәмамлады. Аны кайсыдыр районның финанс бүлегенә эшкә билгеләсәләр дә, анда китмәде, зур шагыйрь булырга исәпләп, Казанда калды. Шактый вакыт эшсез йөрде. Торырга урыны булмаганлыктан, мин аны техникум тулай торагында үз янымда яшәттем. Ел чамасы икәү бер түшәктә йокладык. Беркайчан да тормыш авырлыгыннан зарланмады Әгъзам дус. Читен вакытта, Бальзак сүзләрен бераз үзгәртеп: «Чыда, Камал, чыда, синең язмышың шундый – шагыйрьләр авылда туалар, шәһәрдә үләләр!» – ди торган иде. Хәтерем алдамаса, заманында яхшы ук танылган врач, укымышлы һәм бай тормышлы Әлханкамал исемле туган тиешлесе бар иде. Әмма ул аңа ярдәм сорап бармады. Йөри торгач, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә эшкә урнашты. Мин армиягә киткәндә, шунда эшләп калган иде. Сугыштан кайткач, аның фронтта һәлак булуын ишеттем...

Икенче җыентыгым «Сөю» хәзерге әлифбада 1940 елда чыкты.

Ике китап та үзем белән иде. Армияга киткәндә әйберләремне үзем белән алган идем....

Мин Казанда ялгызым яши идем. Әти-әни авылда торалар. Аларга армиягә алынуымны хәбәр итмәдем. Акком асты урамындагы фатир хуҗасы белән исәп-хисапны өздем дә, чемоданымны күтәреп, туп-туры военкоматка киттем. Солдатка китү – күршегә керү кебек кенә хәл ителде...

Казаннан безне товар вагоннарына төяп алып киттеләр. Бу минем үз гомеремдә беренче мәртәбә шундый ерак сәфәргә чыгуым иде. Шуңадырмы, юлда бик ямансу булды. Өстәвенә, билгесезлек эчне пошырды. Кая, нинди частькә баруыбызны әйтмәделәр. Поезд бик акрын барды. Пенза, Балашов, Ростов шәһәрләрен узып, Төньяк Кавказга килеп кердек. Ниһаять, Краснодарда туктадык. Матур, бай шәһәр, барыннан да бигрәк, андагы яшеллек безне таң калдырды. 1940 елның июнь азагы иде бу...

Частебыз шәһәрдән читтәрәк, әрмән зираты янындагы хәрби шәһәрчектә урнашкан иде. Шәһәрчек территориясе чиста итеп җыештырылган, юлларга ком түшәлгән, ике яклап чәчәкләр утыртылган – тәртип монда...

Өйрәнүләр көннән-көн кызды. Кырык беренче елның апреле узганын сизмичә

дә калдык. Беренче майда, коралларыбызны күтәртеп, Кировоградка хәрби парадка алып чыктылар. Шәһәр зур түгел икән. Ярты өлеше калкулыкта, икенче яртысы иңкү җиргә урнашкан. Бер юнәлештә генә йөри торган трамвае бар....

Парадтан соң туры лагерьга кайттык һәм ул көнне бик иркенләп ял иттек. Май бәйрәменнән соң өйрәнүләр тагын да катыланды...

1941 елның 22 июне. Якшәмбе. Иртәнге сәгать биштә палатка янындагы агачка элеңгән репродуктордан: «Коминтерн» исемендәге радиостанция сөйли», – дигән сүзләрне ишетеп, йокыдан уяндым. Ял көне булудан файдаланып, иркенләп соңгы хәбәрләр тыңларга исәбем. Мине, барыннан да бигрәк, Казан, Татарстан хәбәрләре кызыксындыра. Ул көннәрдә Казанда, Казанда гына түгел, бөтен Татарстанда Мәскәүдә уздырылачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек алып барыла иде. Бу әзерлек турында Мәскәү радиосы еш хәбәр итеп тора. Бүген дә шул турыда хәбәр ишетәсем килә иде – декада зур сынау бит. Ләкин тапшыруларның бик буталчык башлануы мине сискәндерде... Көндез Тышкы эшләр халык комиссары Молотов радиодан чыгыш ясаячак, дип белдерделәр...

Иртәнге аш вакытында сугышчан тревога булды. Безне, штаб батареясында хезмәт итүчеләрне, шәһәргә алып киттеләр. Шәһәр хәрби комиссариаты янына килеп туктаганда, урам халык белән, кырмыска оясы кебек, мыжлап тора иде. Безне хәрби комиссариат ишегалдына алып кереп, һәркайсыбызның кулына күп итеп повесткалар тоттырдылар. Аларны кичкә чаклы таратып бетереп, корешокларын кире кайтарырга тиешбез. Кайсы йортка барып керсәң дә – елау тавышлары, тәртипсез мәҗлес... Бүгенгедәй хәтеремдә, Овчаренко фамилияле кешегә повестка тапшырырга кердем. Өйдәгеләр радиодан Молотов чыгышын тыңлыйлар иде. Мин аның чыгышының соңгы сүзләрен генә ишетеп калдым: «Наше дело правое, враг будет разбит, победа будет за нами!..»

Лагерьда безнең 268 нче КАПның дүртенче дивизионы гына калган иде. Өч дивизион һәм полк штабы көндез моннан киткән. Дүртенче дивизионга запастан чакырылган кешеләрне өстәп, яңа полк оештырганнар. Шулай итеп, мин яңа – 374 нче КАПка күчтем...

Ниһаять, бер тәүлек дигәндә безнең 374 нче КАП фронтка китәргә әзер хәлгә килде. Безне майор Макс Соломонович Киселев кабул итеп алды...

Безне Румыния чигенә алып баралар икән. Ләкин чик буена ук җитәргә туры килмәде. Бельцы дигән шәһәр янында эшелоннан төшерделәр. Монда бер пограноторяд оборонада тора икән, без шуңа кушылдык...

Шул вакытта немецлар ерактан ата торган туплардан ут ачтылар. Снарядлар шактый еракта ярылсалар да, бик куркыныч тоелды. Чөнки бу шундый көчле ут астында калуыбызның беренчесе иде. Бераздан безнең тирәдә миналар ярыла башлады. Кечкенә калибрлы минометтан аталар...

* * *

Менә шулай итеп Әнәс Галиев көтмәгәндә канлы сугыш вакыйгаларына кереп китә. И-и, аның кичергәннәре турында уйлап, хәзер дә күземнән яшь ага. Камалышта калып, әсирлеккә төшүе, аннан соңгы «советча» тормышы. Ул намус кушканча гына яши ала торган кеше иде бит! «Намус кушканча» әсәрен үзем машинкада ничә тапкыр бастым икән?!. Без алар – сугышка беренче көненнән үк кергән гөнаһсыз яшьләр алдында мең кат бурычлыбыз!

Бу язмада Әнәс абыйның яшьлегенә өлешчә генә булса да тукталасы килде. Аның иҗаты, үткән юлы турында әдәбият галимнәре сүз кузгатырга тиеш дип нык ышанып язуым. Бу Җиңү бәйрәме көннәрендә матбугатта зурлап телгә алулары рухын шатландырсын иде Мөхәммәткасыйм улы Әнәс Галиевнең! Әмин!

Нәкыя Гыйләҗева



1968 елда нәшер ителгән «Авылым сандугачы» – язучы Фаил Шәфигуллинның, проза әсәре буларак – беренче, тәртип буенча икенче китабы (1967 елда «Яңа ел бусагасында» исемле шигырьләр җыентыгы чыга). Титул битенең эчке ягына: «Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен. Яшь авторның хикәяләрендә бүгенге авыл тасвирлана. Җыентыкның төп идеясе туган җиргә, кешеләргә мәхәббәт хисе тәрбияләүгә багышлана» – дигән нәни генә аннотация язылган. Редакторы – Резеда Вәлиева.

Кулъязмага ике (миндә саклананнары) эчке рецензия язылган. Икесе ике төбәктән. Казаннан – Барлас Камалов, Әлмәттән – Гариф Ахунов.

«Шәфигуллинның уйлап, кат-кат үлчәп язуы сизелеп тора. Авторның берничә әйбәт сыйфаты бар: ул күзәтә, күрә белә. Күргәнен кыска итеп яза, сюжет төзи белә. Таушалмаган татарча теле дә бар», – дип бәяли Гариф Ахунов.

«ТӘНКЫЙТЬ – кирәкле шәйдер»

Эльмира Шәрифуллина

Шушы ук фикер Барлас Камаловта да әйтелә:

«Җентекләп укыгач туган фикер шундый: прозага үзенчәлекле яшь каләм килә. Ул тормыш белән шактый әйбәт таныш, күзәтүчән һәм тотып ала белүчән. Күргәнен оста итеп тасвирлый белә. Аның геройлары каннары-сүлләре белән күз алдына басалар, сөенә дә, көенә дә беләләр, җәмәгать интереслары өчен дә яналар, табигый буларак, үзләрен дә онытмыйлар».

Фикер уртаклыгы, кулъязманың уңышлы якларын әйтеп, эшлисе урыннарын күрсәткәннән соң, «Зәңгәр каток» хикәясенә кагылышлы өлешендә дә күзгә ташлана. Әйтелгәннәр белән килешеп, Фаил аны бу китабыннан төшереп калдыра һәм, өр-яңадан эшләп, 1976 нчы елда чыккан «Әлфинур» исемле җыентыгына «Зәңгәр шугалак» исеме белән кертә. «Тәнкыйть кирәкле шәйдер», дип кабатламыйча да булмый. Хәзер исә «Зәңгәр шугалак» аның иҗатындагы уңышлы хикәяләренең берсе санала.

«Әйбәт уйланылган, музыкаль яңгырашка ия исем авторны укучыга тәкъдим итүнең алыштыргысыз формасы, дип уйлыйм», – ди Барлас абый Камалов, сүзен йомгаклап. Әйе, китапның үзенә тартып торырлык исеме булу бик мөһим. Остазларын шатландырып, чынлап та, музыкаль исем дә таба Фаил. Китабын, бер хикәясенең исеме белән, «Авылым сандугачы» дип атый.

Фаил Шәфигуллин иҗатка бик таләпчән, өлкәннәр сүзенә колак сала торган язучы иде. Хәер, түбәндә тәкъдим ителгән кулъязмаларны укыгач, моңа үзегез дә ышанырсыз.

Игътибарга лаек әсәрләр

«Бүгенге башлап язучылар арасыннан әдәбиятка чынлап торып килүче прозаиклар бик сирәк. Әнә шул җәһәттән Фаил Шәфигуллин хикәяләре – игътибарга лаек әсәрләр.

Авторның берничә әйбәт сыйфаты бар: ул күзәтә, күрә белә. Күргәнен кыска итеп яза, сюжет төзи белә. Таушалмаган татарча теле дә бар.

Җыентыктагы ун хикәянең («Зәңгәр каток»тан калганнары) барысы да җиңел укылалар, ялыктырмыйлар. Яшь автор авыл кешеләренең төрле-төрле тойгыларын, омтылышларын шактый ук уңышлы итеп сурәтләп бирә. Монда баласын өзелеп көткән ана да, туган авылында лаборантка булып калган комсомолка кыз да, авылга кайткан яңа мулланы хур итеп җибәргән икенче бер чая кыз да, инвалидлыгына сылтаулап, урлашып яткан вак карак та, ат өчен җанын корбан итәргә әзер конюх та бар.

«Ана күңеле», «Өч бөти» кебек өчәр битле генә хикәяләр дә күңелдә хис уята. «Ана күңеле» хикәясендә, минемчә, улын көтеп зарыгып яшәгән ананың тойгылары матур бирелгән. Күпме вәгъдәләр биреп тә, һаман да туган авылына кайтмаган улын көтүдән ана һич туктамый. Төн. Тышта яңгыр. Ана ишегалдына чыгып керә.

«– Әни, синме ул? – дип сорый аңардан кызы.

– Мин, – диде хәлсез карчык тавышы, – әле син дә йокламадыңмыни?.. Кичә почта ящигын карарга онытканмын, имеш. Хат-мазар килеп, чыланып ятмасын дип чыккан идем… Карале, кызым, абыең соңгы хатында плащ алам дип язган идеме әле? Алды микән соң, Ходаем?.. И ява инде…»

Хикәя әнә шулай тәмамлана. Чыланып ятмасын дигән хат, чыланып йөрмәсен дигән олы малай (плащ детале) – болар хикәяне бик чын итеп, ананың олы күңеллелеген арттыралар, аналарын оныткан балаларга карата күңелдәге әрнү хисен тагын да көчәйтәләр.

Мондый уңышлы мисалларны барлык хикәяләрдән дә китереп булыр иде. Ләкин безнең максат ул түгел, ә китап булып чыкканчы, җыентыкның кимчелекләрен киметергә булышу.

Хикәяләрнең сюжеты төзек булуын әйткән идек. Шәфигуллинның уйлап, кат-кат үлчәп язуы сизелеп тора. Эшлисе эш хикәяләрнең телендә. Нигездә, татарча тел белән язылган булсалар да, урыны-урыны белән кирәксезгә кулланылган сүзләр, буталчык җөмләләр очрый.

«…Арба көпчәкләре чокыр-чакырлардан пычрак ияртеп чыгалар да…» – дип яза автор. Без хәзер әлеге җөмләнең «өскә чәчрәтәләр» дигән дәвамын көтәбез. Логика шуны таләп итә. Ә автор әйтә: «пычрак ияртеп чыгалар да, эч пошырып, шыгырдыйлар», – ди. («Көзге юлда» хикәясе). «Зур, кабарынкы өянке» шулай ук сәер. Җәелеп үскән өянке, шаулап үскән өянке, зур ябалдашлы өянке булуы мөмкин.

«Яшьлек хатирәсе» дигән хикәядә шундый бер җөмлә бар:

«…мәгънә тирәнлегендә ниндидер киная яңгырап торган сүзләре, ни өчендер, минем таркау хәтеремә бик авырлык белән генә килеп ирешә». Бик буталчык бу. Беренчедән, киная яңгырый алмый, киная – чак сизелерлек хәрәкәт яки сүзнең сизелер-сизелмәс төсмере бит ул. «Мәгънә тирәнлегендә киная яңгырау» – монысы инде бөтенләй дә аңлашылмый. «Таркау хәтеремә ирешә» – бу ни дигән сүз?

Мондый буталчык урыннар җыентыкта күп түгел. Ләкин бөтенләй булмасалар, бигрәк тә шәп булыр. Сүз уңаеннан әйтик, авторның җөмләләрне чорнап-чорнап язуга омтылышы бар. Болары байтак. Хәзердән үк аңлы рәвештә үз-үзенә контроль ясамаса, чиргә әйләнү куркынычы бар. (Редакторның да әнә шул чорнауларга игътибар итүен сорыйм.)

«Зәңгәр каток» хикәясенең сюжеты сыек. Күпсүзле. Бигрәк тә баштагы биш бите. Кертмәскә, керткән сурәттә, бик нык «тарарга» кирәк.

Дин белән бәйле ике хикәя бар. Турыдан-туры бәйле. Калган хикәяләрдә дә дин сүзләре артык күп. Киметә төшәсе иде. Юкса, ул сүзләр хикәяләрнең барысын да бер яккарак тарта башлыйлар.

Гомумән алганда, җыентык кызыклы, хикәяләрдә автор үзе тапкан, үз күңеле белән ирешкән, укучыларга әйтәсе килгән сүз бар. Әнә шунысы кирәк тә инде аның. Редактор белән җентекләп бер карап чыккач, җыентык тагын да яхшырыр, чүп сүзләрдән чистарыр, дип уйлыйм.

Китапны бастырып чыгарырга кирәк.

Хәерле юл Фаилгә!

Гариф Ахунов. Әлмәт, 17 апрель, 1966 ел.»

Фаил Шәфигуллин хикәяләре турында

«Фаил Шәфигуллин матбугатка үзенең юмористик һәм сатирик шигырьләре белән килде булса кирәк. Һәрхәлдә, хәтердә шулай калган. Менә хәзер ул Татарстан китап нәшриятына үзенең хикәяләрен тәкъдим иткән. Җентекләп укыгач туган фикер шундый: прозага үзенчәлекле яшь каләм килә. Ул тормыш белән шактый әйбәт таныш, күзәтүчән һәм тотып ала белүчән. Күргәнен оста итеп тасвирлый белә. Аның геройлары каннары-сүлләре белән күз алдына басалар, сөенә дә, көенә дә беләләр, җәмәгать интереслары өчен дә яналар, табигый буларак, үзләрен дә онытмыйлар.

Авторның теле бик матур. Ихтимал, персонажлар теле белән автор тасвирлавы аркасында булырга тиеш чик-нормалар сакланмыйдыр, ләкин бу тора-бара урынына утырачак хәл. Хәзерге Фаил исә бөтен байлыклары берничә йөз сүздән торган «телсез» яшь иптәшләрдән нык аерылып тора.

Алда язган юлларым белән мин иптәш Шәфигуллинны тәмам җитлеккән художник дияргә җыенмыйм, әлбәттә. Һич юк. Ул, авыр, мактаулы, күп хезмәт сорый торган иҗат юлына басканда, беренче адымын матур атлый. Хикмәт шунда. Калганы да үзеннән торачак.

Кимчелекләре, җитешмәгән яклары бармы? Бар һәм аз да түгел. Кулдан килгәнчә шуларны күрсәтү максаты белән конкрет хикәяләргә күчәм.

Мин, мәсәлән, «Әллә йокладыңмы, якташ?» хикәясен җыентыкка кертмәү ягында. Сәбәбе? Реаль түгел ул хикәя. Колхозчы Шәйхелислам абзый, кызы Гөлсинәнең химия белән мавыгып йөрүен чамалап, кызы зур шәһәргә китәчәк дип сөенә. Баксаң, Гөлсинә колхозда, агрохимлабораториядә калачак икән… Туп-туры әйтим: «Гомер юлымны тагын ничек дәвам итәсе?» – дип торган көннәрдә, сантый шикелле йөри алыр идемме? Ә бала үзе ата-анасына шултикле сансызлык күрсәтер идеме? Аттестат алучыларның язмышы болай гына хәл кылынса икән! Ул очракта семья, мәктәп, бөтен җәмәгатьчелек баш ватып та тормас иде. Мәгълүм булганча, быел хөкүмәт һәм партия Үзәк Комитеты февраль аенда ук, махсус карар кабул итеп, дәүләткүләм бу җитди эшне олы юлга салып җибәрде.

Хикәяне көлке тонда язылган дип тә аклар хәл юк.

Монда отышлы бары бер деталь күзгә ташлана, ул да булса – хикәягә исем биргән соңгы абзац, артык калучы, йоклап калучы кешегә бик кыска, бик оста, русча әйтсәк, шәп подтекст белән ишарә. Бу уңышлы детальне Фаил «иҗат капчыгына» салып куйсын. Дөнья бит, кирәге чыгар.

«Зәңгәр каток»ны да җыентыкка кертмәү хәерле. Беренчедән, ул бик чырайсыз хикәя. Сюжеты соң дәрәҗәдә зәгыйфь, образлар да тулы канлы булып чыкмаганнар.

Икенчедән, яшь үзенчәлеге белән дә бүтән барлык хикәяләрдән читтә. Балалар өчен язылган. Олы әдипләрнең сайланмалары гына булмаганда, чуарлыктан, гомумән, качарга кирәктер ул.

Минем карашка, җыентыкка бәхәссез керергә тиешле бер төркем хикәяләрдән

Ф.Шәфигуллинның «Яшь ленинчы» газетасы үткәргән конкурста, җиңүче буларак, бүләк алган вакыты. Уңнан сулга: Фаил Шәфигуллин, Барлас Камалов, ...

мин «Айлы төндә», «Өч бөти», «Яшьлек хатирәсе», «Тәүге адымың белән, әбием» һәм «Көзге юлда»ны саныйм. «Галимҗан бабай»ны да шуларга өстәргә була, әмма бер шарт белән: әйбәтләп кыскартырга кирәк. Ул ясалма сузылган.

Тагын бер төркем хикәяләр. Аларны минем кармакка куеп, билге кую хокукы бирсәләр, мин «5»ле куяр идем. Болар рәтенә мин җыентыкта төп урынны алырга тиешле «Дезертир»ны, психологик яктан иң көчле булган «Яшел эшләпәле кеше»не һәм, әлбәттә, яшь авторның кыскалыкта осталыгын раслаучы «Ана күңеле»н куям.

Боларга карата да кечкенә тәкъдимнәрем бар. Бәлки, Фаил аларны искә алыр.

«Дезертир» композицион яктан ике өлештән тора, ә әсәрнең «тозы», нигезе – икенче өлеш. Сәет язмышы. «Тәнзилә – Хәлимә – Сәет» линиясе. Моңа автор 6 бит урын бирә. Димәк, төп өлешкә 15 бит кала. Пропорция сакланып җитми. Өстәвенә беренче өлеш диңгездәге хәлләрне озак тасвирлау белән ялыктыра да. Кыскасы, беренче алты битне беркадәр кыскартканда, хикәя отачак кына.

«Яшел эшләпәле кеше»дә, киресенчә, берәр деталь өстәү кирәктер. Дөресрәге, Таһир белән теге кешене полкташлар да итәсе иде. Бәлки, Таһир аны оныткан гынадыр да. Яисә ул кешенең батырлыгы бәяләнгән булуын берәр штрих белән төсмерләп узасы иде.

Боларның бары тик теләк төсендә генә әйтелүе аңлашылса кирәк.

Тагын бер принципиаль мәсьәлә. Җыентыкның исеме юк бит. Беренче китап чыгаручы бүтән кемгә караганда да, бу хакта уйланырга тиеш, минемчә. Әйбәт уйланылган, музыкаль яңгырашка ия исем авторны укучыга тәкъдим итүнең алыштыргысыз формасы, дип уйлыйм.

Менә шулар. Моңа өстәп: «Хәерле сәгатьтә!» – диясем генә килә.

Барлас Камалов. Казан, 8 июль, 1966 ел.» ■

Ул, һәр очрашкан саен, сине, кысыграк күзләрен тагын да кыса төшеп, күзлеген төзәтә-төзәтә, якты чырай белән елмаеп каршылар. Карашында аның: «Кирәгем булса – әзермен...» – диган кебегрәк сораулы чалым да чагыла сыман, һәрхәлдә, миңа ул һәрвакытта шулайрак тоелды. Хәзер дә шулай. Аны мин утыз елдан артыграк беләм инде. Төгәлрәк әйткәндә, Язучылар берлеге каршындагы Әдәби фондта эшләгән вакытыннан бирле. Сүзем – тырыш язучы, әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшләп килә торган Лирон Хәмидуллин турында.

ТЫЙНАК ТАБИГАТЬЛЕ КАЛӘМДӘШЕБЕЗ

Миркасыйм Госманов

Язучыларыбыз турындагы махсус белешмәлек китабыннан һәм аның хакындагы кайбер биографик язмалардан күренгәнчә, Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин 1932 елның 22 октябрендә (рәсми кәгазьләрдә 10 ноябрендә) элекке Куйбышев өлкәсенә кергән, хәзер исә Ульяновск өлкәсенең Малыклы районына карый торган Иске Төгәлбуга авылында хезмәтче гаиләсендә туган.

Лиронның каләм тибрәтә башлавы 60 нчы еллар башында, төрле хәбәрләр, очерклар язу белән, «Татарстан яшьләре» гәзитендә башланып китә. 1968 елда үзе яхшы белгән тимерьюлчылар тормышына багышланган «Юлда» исемле хикәяләр җыентыгы, аннары «Дала иртәсе» диган повесте (1971) һәм «Офыктагы рәшәләр» дип аталган хикәя вә очерклар җыентыгы (1990) дөнья күрә. Әйтергә кирәк, язучының бу әсәрләре әдәби тәнкыйть тарафыннан җылы каршылана. Мәсәлән, XX гасырның өченче чирегендә актив эшләгән әдипләребездән Г.Ахунов, Т.Әйди, Р.Даутов, Ф.Миңнуллин, Х.Сарьяннар Лирон Хәмидуллин әсәрләренең уңай сыйфатларын билгеләделәр, аның иҗатына хас җылылыкны аерата атап күрсәттеләр. Бу күренеш, минемчә, очраклы булмаса кирәк: язучы реаль тормыштагы танышбелешләрен генә, язмамның башында әйтелгәнчә, теләктәшлек белән елмаеп каршыламый, бәлки, күңелендә үзе иҗат иткән геройларына карата да самими хөрмәт хисе саклап яши.

Л.Хәмидуллин ун ел чамасы Татарстан Язучылар берлеге идарәсе каршындагы Тәрҗемәчеләр секциясенә җитәкчелек итә. Аңар мондый бурычның йөкләнүе дә очраклы түгел иде. Ул әдәби тәрҗемәчелек белән дә шактый актив рәвештә шөгыльләнгән язучы. Л.Хәмидуллинның каләме ярдәмендә татар укучысы тугандаш әдәбиятларның кызыклы үрнәкләре белән танышып килде. Ул күбрәк казакъ, каракалпак әдипләренең

әсәрләрен яратыбрак тәрҗемә итте шикелле. Моңа, ихтимал, аның яшьлек елларында Казакъстандагы Актүбә шәһәрендә беркадәре яшәве, казакъларның телләре, гореф-гадәтләре белән дә танышлыгы сәбәп булгандыр (каракалпак теле казакъ теленә бик якын). Мохтар Әүәзев, Сырбай Мәүләнев, Әнүәр Әлимҗанов, Сайын Моратбәкев, Мохтар Мәгауин, Уралхан Бүкиевләрнең повесть һәм хикәяләре «Отрар хатирәсе» (1974), «Ак дөя» (1979), «Дуслык аланы» (1979), «Арал дулкыннары» (1981), «Әрем исе» (1986), «Дала гөлләре» (1991), «Җәйләүдә» (1993), «Бөртекләп җыелган алтын» (1996) исемле китапларда һәм күмәк җыентыкларда урын алганнар. Ул җыеп чыгарган казакъ халык әкиятләре дә мөһим. Бигрәк тә Абай Конанбай улының «Хикмәтле сүзләр» (казакъча оригиналда «Гакълия сүзләре») исемле гаҗәеп мәгънәле уй-фикерләрен тәрҗемә итү аерата җаваплылык сораган зур эш («Абай», 1981).

Тәрҗемәченең шулай ук үзбәкчәдән мәгълүм әдип Әсгать Мохтарның киң планлы «Чинар» романын (1976), русчадан белорус язучысы Василь Быковның сугыш вакыйгаларын чагылдырган повестьларын «Һәйкәл» исемле китапта (1984) татарча яңгыратуы да җәмәгатьчелектә уңай бәя алды.

Л. Хәмидуллин бер үк вакытта хәзерге чор татар әдәбияты үрнәкләрен башка төрки телләрдә чыгару эшләренә дә актив катнаша. Мәсәлән, казакъ телендә Алматыда чыккан «Татар повестери» (1979), каракалпак һәм үзбәк телләрендә Ташкентта, Нүкүстә нәшер ителгән «Татар гүрриңлери» (1981) һәм «Йиллар вә йуллар» (1981) исемле җыентыкларның оешуында да аның тырышлыгы зур.

Лирон Хәмидуллинның әдәби иҗатында махсус тәкъдир итүгә лаек тагын бер юнәлеш бар. Ул – элекке чор күренекле әдипләребезнең тормыш юлларын, мирасларын өйрәнүгә багышланган эзләнү һәм бастырып чыгару эшләре. Бу өлкәдәге кызыксынулар Лиронның Орскида яшәгән, эшләгән елларында ук башланган булырга охшый. Чөнки тормышлары шул шәһәр белән бәйле мәгълүм драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзи белән атаклы шагыйребез Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) хакында махсус эзләнүләр башкарылу, шул максат белән алар эзеннән йөреп, Башкортстандагы Җиргән һәм Юлык авылларына, Баймак шәһәренә барып чыгулар, Чиләбе өлкәсендәге Балкан һәм Требия авылларында, Уфа һәм Оренбург шәһәрләрендә эзләнүләр, әлеге әдипләрнең оныкларын, туганнарын эзләп табу, алар белән хатлашулар, ниһаять, архивларда казынулар нәтиҗәсендә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән «Офыктагы рәшәләр» китабы һәм «Галиябану туган якларда» исемле кульязмасы барлыкка килгән.

Әдипнең шушы юнәлештәге эшчәнлеген игътибарга алып, мин Лиронны «Шәхесләребез» сериясендә чыгарга тиешле «Бертуган Рәмиевләр» исемле фәнни-биографик китапны әзерләү эшенә катнашырга чакырдым. Ул бу эшкә җиң сызганып, хәтта дәртләнеп тотынды. Яшьрәк төзүчеләрдән дә җиңелрәк хәрәкәтләнеп, махсус мәкаләләрен язды, төрле җирләрдә сибелгән фотосурәтләрне барлады, аларның оригиналларын яисә күчермәләрен булдырырга тырышты. Шул ук вакытта бу эш процессында да аның эшлеклелек, табигый тыйнаклык һәм ихлас теләктәшлек сыйфатлары артыгы белән расланды. Димәк, «Бертуган Рәмиевләр» китабы эчтәлекле, күргәзмәле материалларга бай һәм, гомумән, зәвыклы булып чыккан икән, мондый изге эштә Лирон Хәмидуллинның да лаеклы өлеше бар!

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1982) Л. Хәмидуллинның чын мәгънәсендәге хезмәт сөюче кеше булуын, шул гадәтне башкаларга да сеңдерүгә сәләтле икәнлеген, минемчә, тагын бер факт раслый. Аның миндә укып чыккан, соңра академик институтта аспирантура узган улы Булат та эзләнүчән, хезмәткә җаваплы карый торган тарихчы буларак үсеп, җитлегеп килә. Бөтен аңлы гомере иҗатка багышланган кешенең баласы шундыйрак юл белән китүдә, минемчә, ата-ананың тәрбияви тәэсире, гамәли үрнәге дә аз роль уйнамаган булырга тиеш.

2002 ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

Шәхесләребез: *Галимҗан Латыйп, Хөснул Вәлиуллин һәм Зәки Нури*

ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙП
(1912-1986)

Шагыйрь Галимҗан Латыйп

4 ноябрьдә үпкәсе шешүдән һәм инфарктан Галимҗан Латыйп больницада вафат булды. Авырый башлавына да күп вакыт узмаган иде, яше дә 70тән аз гына узган иде, шулай да врачлар алып кала алмадылар.

Шуннан бер көн элек мин врачта булып, алар миңа дүрт-биш көн өйдә торырга, тышка чыкмаска кушканнар иде. Шуның өстенә өйдәгеләр: «Шәһәрдә бик усал грипп хөкем сөрә, температураны 40ка кадәр күтәрә, синең яшеңдә андый гриппны кеше күтәрә алмый, халык күп урында грипп йоктыруың ихтимал», – дип куркыттылар. Шул сәбәпле мин өч көннән бирле өйдә ятам, бер җиргә дә чыкмыйм, табигый, Галимҗанны озатып калырга да бара алмадым.

Безнең буын кешеләре башкаларның кайгы-хәсрәтенә, борчуына игътибарлы, үлем-җитем мәрасименә катнашучы булып тәрбияләнгән. Моңа кадәр мин күренеклерәк язучыларның берсенең дә җеназасына бармыйча калмый торган идем. Менә бүген Галимҗанны озатырга бара алмадым. Гәрчә сәбәбе җитди булса да, үземне гаепле кеше сыман хис итәм. Дачада без аның белән озак еллар күрше булып яшәгән идек бит. Галимҗан берәр ел чамасы элек инфаркт кичергән иде. Ул башта яхшы ук сакланып яшәде. Әмма, күрәсең, соңгы вакытта үзен тәмам тазарып җиткәнгә санагандыр, Аккош күлендә авыр эшләргә тотынган, салкында юка киенеп эшләгән. Шунда ике үпкәсенә дә салкын тигән. Казанга кайткач, шифаханәгә салганнар. Кинәт хәле начарланып киткән. Аны аерым палатага салганнар, хатынын да, врач улын да кертмәгәннәр. Коридорга аның ыңгырашкан, кычкырган тавышы ишетелгән. Әмма барыбер якыннарын кертмәгәннәр. Ята торгач, ул вафат булган. Нинди фаҗига! Дүрт-биш көн элек таза-сау булган кешене улы белән хатыны палатадан мәет хәлендә алып чыгалар.

1986, 6 ноябрь

ХӨСНУЛ ВӘЛИУЛЛИН
(1914-1993)

Өлкән буын вәкилләре берсе артыннан берсе дөнья куя. Бүген Хөснул Вәлиуллинны озату мәрасимендә булдым. Табутта чәчләре агарган ябык кына бер карт ята. Аның инде бу дөнья белән эше беткән, аны менә хәзер мәңгелек юлына алып чыгып китәчәкләр.

Ул Саба авылыннан иде, минем анам Зифа туган яктан. Тыйнак кешеләргә ихтирамым бик зур. Хөснулла Вәлиуллин «Самат» операсын һәм бик күп санда яхшы җырлар язган кеше. Ләкин ул беркайчан да үзенең композитор булуы белән масаймады. Хәзер генә ул чиле-пешле берәр җыр сыман нәрсә әмәлләп чыгарган борын асты кибеп җитмәгән малайлар газеталарда «композитор-фәлән» дип үзен беренче планга куярга оялмый.

Менә шул талантлы кешебезнең фәхри каравылында булып, Композиторлар йортыннан соңгы мәкаменә озатып кайттым. Без аның белән дус идек.

Яткан туфрагың йомшак булсын, якташ!

1993, 25 сентябрь

Композитор Хөснул Вәлиуллин. 1950 нче еллар

ЗӘКИ НУРИ
(1921-1994)

Әдипләр Зәки Нури һәм Афзал Шамов. 1960 ел

Озак авырганнан соң, кичә Зәки Нури вафат булды, бүген аны җирлиләр. 73 нче яшенә чыккан иде. Тормыш мине әдәбият дөньясында аның белән берничә мәртәбә очраштырды. Мин Язучылар союзының рәисе чагында ул сәркатип булып эшләде. Бик тырыш, бик тә өлгер кеше иде, мәрхүм. Соңыннан үзе дә рәис булып, «Казан утлары»ның җаваплы мөхәррире булып та байтак еллар эшләде. Шигырь китаплары, җырлары да байтак кына.

Мине Зәкинең дусты дип атап булмас иде. Ул җитәкче булып эшләгәндә, аның кайбер гамәлләренә каршы чыккаладым. Әмма өлкә комитетының идеология сәркатибе М.Вәлиев З.Нурига җил-яңгыр тидермәскә тырышты.

Минем каршы чыгуым Зәкигә ниндидер дошманлык хисе саклаудан түгел, бәлки, ялгышларын төзәтү теләге белән эшләнгән иде.

Гомеренең соңгы елларында, бичара, гакылына зарар килеп, бик күп авырлыклар кичерде, хатыны – белорус кызы Валентина – аңа карата соклангыч фидакярлек, түземлелек күрсәтте.

Зәки Нури сугыш каһарманнарының соңгыларыннан була торгандыр инде. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең. Әмин.

1994, 19 февраль

Истәлекләр Гомәр Бәширов көндәлегеннән алынды.

Әдәбият:

1. Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кульязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

Гомерлек үкенеч

Фатиһ Кутлу

Төрек кызы Әминә ананың баласы рухына багышлыйм

Күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов һәм Галиәсгар Камал театрының аксакал артисты мөхтәрәм Илдус Әхмәтҗановның бертуган (аталары бер булган) апалары, Төркиядә туып үскән төрек кызы Әминәнең өченче баласы булып дөньяга аваз салган (8 гыйнвар, 1927) Мәгъния әби белән 2016 елның 25 июнендә туган авылы Кандызга барып танышкан идем[1].

Шул очрашу, күрешү күңелләребезгә уелганга, Мәгъния әби белән телефоннан сөйләшүләребез алга таба да дәвам итте. Фәкыйрегезне күңеле бик якын күрә иде. Туксан елга якын гомер кичереп, үз канынннан, әнисенең туган ягыннан булган бер төрек баласы белән беренче кат очрашып танышу аны нихәтле шатландырганын бер Аллаһ кына беләдер... Мин дә аны, үз иленнән меңнәрчә чакрым еракта эти-

Илдус Әхмәтҗанов бертуган апасы Мәгъния әби белән. 2017 ел, Казан

[1] Бу хакта «Безнең мирас» журналының 2016 елгы 11 һәм 12 нче саннарыннан укый аласыз. «Еллар кайтавазы яки бер сәфәр». – 106-111 һәм 104-107 битләр.

әнисен, туган-тумачасын күрмичә сагынып-саргаеп, бик яшьли бакыйлыкка күчеп, Кандыз авылының Сөләйман зиратында җирләнгән якташым, милләттәшембәгыркәем Әминә ананың бердәнбер тере хатирәсе, аның әманәте дип күреп, бик якын иттем…

Казан-Кандыз арасы бик ерак бит! «Кабат күрешүләр булырмы, ай-һай!» – дип борчылып йөри идем. 2017 елның октябрендә «Мәгъния әбине Казанда яшәүче кызы Әлфия апа тәрбиягә үз янына алган» дигән хәбәр ирешә миңа. Шушы хәбәргә бик сөендем. Күк капусы ачылгандай булды. Ходайның бүләге иде бу миңа! Шуннан соң Әлфия апаларга Мәгъния әбине күрергә йөри башладым. Әлфия апа да, ире Ришат абый да якын итеп чакыралар иде. Рәхмәт яусын аларга! Җәй көннәрендә Казаннан ерак түгел урнашкан дачаларына күченәләр дә, кыш җиткәнче, шунда торалар иде. 2019 елның җәендә Мәгъния әби янына анда да бардым. Әбиемнең хәле кышка таба бераз авырайган. Әлфия апа аша хәлләрен белешеп тора башладым. Аяклары йөрсә дә, бик үк сөйләшә алмый башлаган. 92 яшь бит инде.

Коръәннең төрек басмасы

Быел 12 февраль көнне 21 сәгать 21 минутта Әлфия ападан телефоныма шундый хат килде: «Әни авырып китте әле, хәле яхшы түгел. Бүген ашамады, эчмәде. Алла ни язган инде!»

Раббым Аллам! Шушы хәбәрдән соң иртәгә иртүк беренче эш итеп анда барырга ниятләп өйдән чыгып киткәндә, телефоным шалтырады. Әлфия апа: «Әни бүген вафат булды!» – дигәч, катып калдым… Иннә лилләһ, вә иннә иләйһи раҗигун. Урының оҗмахта булсын, Мәгъния әбием!

Бүген, рәсми кәгазьләрне алганнан соң, Кандызга алып кайтып җирләячәкләр икән. Кандыз бик ерак, анда кайтып җиткәнче караңгы төшә. Шуңа бу төнне үз йортында кундырып, иртәгә шунда юып, кәфенләп җирләргә булганнар. «Хушлашырга ничә сәгатьтән килсәм була?» – дип сорадым Әлфия ападан. «Ике сәгатьтән килсәгез була», – диде ул. Сәгать уннарда шунда бардым. Бусагадан атлап кергәндә, бер ханым Әлфия ападан: «Әллә авылга алып кайтучы шофермы бу кеше?» – дип сорагач, ул, якын итеп: «Мәгъния әбинең оныгы бит ул!» – диде. Әлфия апаның бертуган абыйсы Ярулла абый Баулыдан ук килеп җиткән икән. Кочаклашып күрештек. Мәгъния әбинең җансыз гәүдәсе ак япма белән капланган, карават өстендә сузылып ята иде… «И-и, Мәгъния әбием, урының җәннәттә булсын!»

Күрше бүлмәдән Коръән тавышлары ишетелә иде. Мин монда килгәндә, мәет әле юылганчы аның рухына багышлап Коръән укырга ярыймы, дип, китаптан караган идем. Хәер, кызы Әлфия апа, мәрхүмәнең соңгы төнендә баш очында «Ясин» сүрәсен укып чыккан икән. Ә баягы сорауга җавап: мәет булган бүлмәдә түгел, икенче бер бүлмәдә Коръән укырга ярый икән. Алар, шуны белгән төсле, күрше бүлмәдән Коръән укыган тавыш ишетелә. Баксаң, ул сүрәләрне Мәгъния әбинең атасы ягыннан сеңлесе, шулай ук Илдус Әхмәтҗановның да сеңлесе Сания апа укый икән. Озакламый Илдус абый да килеп җитте. Аның белән дә кочаклашып күрештек.

Ишек катыннан залдагы өстәлдә берничә Коръән китабы күрдем. Ерактан кызыл

тышлысына күземнең төшүе булды, бала йоннарым кабарып китте! Бу бит – мин балачакта укып үскән Төркия, Истамбул басмасы булган Коръән Кәрим иде! Өстәл янына барып, шул Коръәнне кулыма тотып, битләрен актара башладым. Әйе! Чыннан да, бу – безнең мәшһүр Каешзада Госман хатты белән язылган Коръән Кәрим иде! Әлфия апа, минем шулхәтле шатланганымны күреп: «Без ул басманы болай да укый алмыйбыз, мин сезгә бүләк итим аны», – дигәч, ничек сөенгәнемне күрсәгез иде!

Бу йортка ничә мәртәбә килеп, нәкъ шушындый көнне генә төрек басмасы булган бу Коръәнгә тап бул әле син! Әминә ананың кызы Мәгъния әбине соңгы юлга озатырга килгәндә… Хикмәт инде, хикмәт! Әлеге Коръәннең үзләрендә булу тарихын Әлфия апа да хәтерләми. 90 нчы елларда – перестройка вакытында булгандыр инде, диде. Коръән 1985 елда басылган икән. Хәзер мондый тышлыкта басмыйлар да кебек. Мин Әлфия ападан язып бирүен үтендем. Ул болай дип язды: «Фатих туганыбызга Мәгъния әбинең соңгы бүләге. 13.02.20».

Шул арада җеназаны Кандызга алып кайтучы машина да килеп җиткән. Әлфия апаның улы Энгель әфәнде рәсми эшләрне хәл итеп килгән иде. Без өйдә дүрт ир-ат: Мәгъния әбинең улы Ярулла абый, энесе Илдус абый, оныгы Энгель әфәнде һәм мин. Әлфия апаның ире Ришат абыйга яңарак кына операция ясалган, ул хастаханәдә икән. Мәгъния әбинең җәсәден җәймәгә салдык. Ярулла абый белән мин кара-каршы, баш очыннан тоттык. Минем янда оныгы Энгель урта бер җиреннән һәм Илдус абый Әхмәтҗанов аяк очыннан тотып, дүртәүләп, саклык белән 7 нче каттан аска әкренләп төшерә башладык. Шунда мин уйлап барам: Ходайның рәхмәте бу миңа, дим, әбинең иң якыннары – улы, энесе, оныгы һәм мин, төрек баласы, күтәреп, мәетне төшереп барабыз. Әлфия апаның мин ишектән килеп кергәндә: «Мәгъния әбинең оныгы!» – дигән сүзе гамәлдә раслангандай булды. Казанда түгел, ә туган авылында җан тәслим кылса, мондый нәрсә миңа насыйп булмас иде. Моны миңа, гаиләсеннән бер кеше төсле насыйп иткән өчен Раббыма шөкерләр булсын!

Аска төшеп җиттек… Бергәләп җеназаны машинага урнаштырдык. Әниләре янына кызы Әлфия апа белән улы Ярулла абый утырды да, җеназа машинасы, уникe тулып егерме минутлар иде бугай, Кандызга таба кузгалып китте. Исән-сау гына кайтып җитсеннәр. Җирләү үзенең туган җирендә – Баулы районының Канды авылындагы Сөләйман зиратында иртәгә сәгать 11дә булачак. Урының җәннәттә булсын, төрек баласының дәвамы!

Шушы урында күптәннән инде башымда йөрткән уемны, күңелемдәге теләгемне әйтәсем килә. Килер бер көн, Мәгъния әби Кандызда вафат булса, шунда барып, җеназа намазында һәм җирләүдә катнашырмын дип хыяллана идем. Моның сәбәбе – әнкәсе Әминә вафат булгач, Төркиядән бер туганы да җеназа намазында һәм җирләүдә катнаша алмаган. Ичмасам, аның кызы – соңгы баласының җеназасында бер төрек катнашсын иде дигән теләгем бар иде. Шуңа күрә иртәгә сәгать 11дә Кандызда булырга тели идем. Моның өчен иртәгә иртүк бишенче яртыда юлга чыгарга һәм көнендә Казанга кайтырга да кирәк иде. Берүземә машина белән ерак юлга чыгу хәвефле, шуңа миңа бер иптәш, юлдаш кирәк дип уйладым. Бер дустыма шалтыраттым. Алдан билгеләнмәгән, кисәк кенә килеп чыккан хәл бит! Дустым, гафу үтенеп, үзенең иртәгәгә планнары барлыгын әйтте. Аны да аңлыйм, үпкәләмим, әлбәттә. Шуннан соң интернеттан автобусларны, маршрутларны караштыра башладым. Ләкин иртәнге дүртләрдә Баулыга баручы бер транспорт та тапмадым. Анда бара алмау мине бимазалый иде. Нишләргә хәзер, нишләргә?!

Кылт итеп исемә төште. Кандызга үзем бара алмасам да, бер төрек кешесенең катнашуы җитә бит! Шундук дулкынланып, Бөгелмәдә яшәүче милләттәшемә шалтыраттым. Аннары, нәүмизләнеп, телефонны куйдым: аның да эшләре бар икән, артык кыстамадым… Соңгы талпынуым итеп, Казандагы тагын бер дустыма шалтыратып карадым. Нәтиҗәсе булмады. Боегып калдым…

Мәгъния әби кызы Әлфия апа белән. 2019, июнь

Кич җиткәч, сәгать җиделәрдә, Ярулла абыйга «Кандызга исән-сау барып җиттегезме?» – дип шалтыраткан идем. Ул вакытта әле юлда булганнар икән. Соңрак үзе шалтыратты. Сигезенче яртыларда авылга кайтып җиткәннәр. Юлда җиде сәгатьтән артык булганнар инде. Иртәгә анда барырга бик теләгәнемне, ләкин барып чыкмавын әйтеп, гафу үтендем. Ул мине юатты, рәхмәтләр әйтте. Ләкин барыбер күңелемне тынычландыра алмый идем. Узган ел шушы вакытларда нәкъ моңа охшаш хәл булган иде. Алабуга дәүләт педагогия институтында укыткан шәкертем – 6 бала атасы Винер (Габделкәрим) Моратовның гомере 15 февраль көнне юл һәлакәтендә өзелгән иде. Шул көнне Минзәләгә барырга бик нык теләсәм дә, бик көчле давыл чыгып, җеназага бара алмый калган идем. Менә иртәгә, 14 февраль, тагын бара алмыйм: «Йә, Раббым! Минем изге ниятемне беләсең. Мин гаҗиз калдым, көчем җитмәде анда барып җирләргә. Үз-үземә биргән сүземдә тора алмадым, ярлыка мине, Илаһым! Әмин!»

14 февраль көнне иртүк Ярулла абыйга тагын шалтыраттым. Кабер казыйлар икән, ярый әле соңга калмаганмын. «Мәгъния әбине җир куенына тапшырганда, ана исеме белән: «Әминә кызы Мәгъния», – дип төшерегез, яме», – дидем. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә шулай әйтергә кирәклеген бер дин галименнән ишеткән идем. (Бу урында аз гына тукталасым килә. Ни өчен ата түгел, ә ана исеме белән? Моның бер хикмәте шулай булырга мөмкин. Кешенең анасының кем булуында шик юк... Ә ахирәттә Кыямәт көнендә һәркем атасының исеме белән чакырылачак. Анда бөтен серләр фаш ителәчәк. Кемнәрдер хурлыкка калачак: хатын – иреннән, ире баласыннан качачак... Аллам сакласын!)

Төрек кызы Әминә ана (1902-1928) өч бала дөньяга китергән: Бәхтияр (1923-2006), Әмрия (1925-1939) һәм менә соңгысы – Мәгъния әби (1927-2020).

Җирләүдә Баулы район хакимиятеннән һәм авыл җирлеге идарәсеннән, авыл халкыннан бик күп кеше катнашып, олылап җиргә иңдергәннәр. Ярулла абыйдан әниләренең кабер ташын ясатканда, «Хәниф һәм Әминә кызы Мәгъния» дип яздыруларын үтендем...

Урының оҗмахта булсын, Мәгъния әбием! Син дә ата-анаң, бертуганнарың булган галәмгә күчтең. Алар белән кавыштың. ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

Истә, һаман да истә!

Язучы
Әнәс Галиевнең
тууына 100 ел



Шагыйрь һәм прозаик Әнәс Галиев 1920 елның 3 апрелендә Татарстанның Арча районындагы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туган.

1940 елда ул Кызыл Армия сафларына алына һәм Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтның алгы сызыгында була. 1942 елда дошман кулына әсир төшә һәм 1945 елның апреленә кадәр фашистлар тоткынлыгында газап чигә.

Ә.Галиевнең беренче шигырьләре 1937 елда «Кызыл яшьләр» газетасында басыла.

Китаплары: «Җилфердә, байрак!» (1938), «Сөю» (1940), «Кыен юл» (1958), «Тормыш баскычында» (1960), «Йолдызлар шаһит» (1968), «Намус кушканча» (1984, 1990).

Ул 1996 елның 26 июлендә Казанда вафат булды.

Артист
Рәшит Мәрдехановның
тууына 90 ел

Татарстанның атказанган (1979) һәм Татарстанның халык артисты (1991) Рәшит Мәрдехан улы Мәрдеханов ТАССРның Минзәлә районындагы Чулпан (элекке Матвеевка) авылында 1930 елның 8 апрелендә туган.

1951 елдан алып 1990 елга кадәр Минзәлә театрында эшли.

Уйнаган рольләре: Җиһанша – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Гыйлемдар – «Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт), Тимербулат – «Икәүдән-икәү» (Г.Ахунов), Заһит – «Хыянәт» (Х.Вахит), Шатун – «Гарасат» (Г.Сабитов), Суиндон – «Шайтан шәкерте» (Б.Шоу) һ.б.

Р.Мәрдеханов 1995 елның 16 декабрендә Минзәләдә вафат булды.

Шагыйрә
Заһирә Гомәрованың
тууына 90 ел

Шагыйрә һәм мөгаллимә Заһирә Әбүбәкер кызы Гомәрова 1930 елның 12 апрелендә Татарстанның Арча районындагы Чөмә-Елга авылында туган.

Керәнне авылында укытканда, аңа «Кыз урлау», «Ташкыннар», ә Эзмәдә «Башмагым» спектакльләрендә Мөхәммәт Мәһдиев белән бергә уйнарга туры килә.

1959 елда ул Казан педагогия институтын тәмамлый.

Шагыйрәнең «Яшьлек таңы» дип аталган тәүге китабы 1964 елда дөнья күрә. З.Гомәрова «Чын герой» (1968), «Нәни врач» (1970), «Әниснең алмалары» (1980), «Йөгерек елга» (1991) дигән китаплар авторы да.

Ул 2002 елның 4 гыйнварында Чаллыда вафат булды. Бүгенге көндә Чөмә-Елга авылының бер урамы Заһирә Гомәрова исемен йөртә.

Язучы
Гомәр Толымбайның
тууына 120 ел

Күренекле язучы, фольклорчы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гомәр Толымбай (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов) 1900 елның 14 апрелендә хәзерге Татарстанның Буа районындагы Толымбай (Адав-Толымбай) авылында туган.

Совет режимы оештырган репрессияләрнең иң котырган вакытында – 1937 елның 8 июнендә Г.Толымбай кулга алына. Кайбер каләмдәшләренең әйтүенә караганда, ул, бер елга якын дәвам иткән сорау алулар вакытындагы җәза-кыйналулар нәтиҗәсендә, акылыннан яза һәм аны шул ук елда, ягъни 1938 елның 8 маенда Пләтән төрмәсендә атып үтерәләр.

Г.Толымбай 1934 елдан бирле СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Артист
Фердинанд Фарсинның
тууына 90 ел

Татарстанның атказанган артисты (1968) Фердинанд Юныс улы Фарсин 1930 елның 24 апрелендә Чистай шәһәрендә туган.

1951 елда ул Казан театр училищесын тәмамлый.

1951 елдан пенсиягә чыкканчы, ягъни 1981 елга кадәр К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында эшли.

Аны халыкка таныткан рольләрнең берсе – Җ.Җаффарлының «Сулган чәчәкләр» трагедиясендә Баһрам образы була. Ф.Фарсин уйнаган кайбер рольләр: Ногман — «Данлы көннәр» (Т.Гыйззәт), Ибрай — «Кызыл йолдыз» (М.Фәйзи) һ.б.

Ф.Фарсин 2012 елның 2 апрелендә вафат булды һәм Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнде.

Шагыйрь
Әбрар Сәгыйдинең
тууына 125 ел

Шагыйрь һәм журналист Әбрар Сәгыйди (Әбрар Закир улы Сәгыйтев) 1895 елның 14 апрелендә Казан губернасының Зөя өязендәге (хәзерге Татарстан Республикасының Апас районы) Кече Кошман авылында туган.

Романтик рухта язылган тәүге шигырьләре 1914 елда «Кояш» газетасында басылып чыга.

Шагыйрь әдәби тәрҗемә һәм драматургия жанрында да үз көчен сынап карый: Рабиндранат Тагор һәм Уолт Уитменның аерым шигырьләрен тәрҗемә итә, «Сахра кызы», «Ишан улы», «Кызыл тау» исемле пьесаларын яза.

Китаплары: «Ирек азаны» (1917), «Сугыштан абыем хатлары» (1917), «Яшьләр иле» (1921), «Умарта бакчасы» (1930), «Эш курае» (1930).

Ә.Сәгыйди 1939 елның 1 апрелендә туган авылы Кече Кошман авылында вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Җиңүгә – 75 ел

Сагыш

Рәдиф Сәгъди

Балачакта – дөньяны азрак тоя-аңлый башлаган чорда өлкәннәрнең, ниндидер язмаларны укыганда, күз яшьләрен яулык очлары белән сөртә-сөртә тыңлаганнары хәтергә уелып калган. Ятим калган балаларны, туганнарын кызганып ухылдашулары безнең күңелгә дә авыр тәэсир итә торган иде. Үсә төшкәч, өлкәннәр авылдан-авылга, кулдан-кулга күчеп йөргән бәетләрне безгә укыттыра башладылар. Шул чорларда Иске Казиле авылы кешесе Мөхәммәткә багышланган язма безнең Балчыклы авылына да килеп җиткән иде:

...Сызылып таңнар аткан чакта,
Ямьле май иртәсендә,
Иртән үк сулар болганды
Таулы күл эчләрендә.
Бәрелгәч ярга дулкыннар,
Шом салды йөрәгемә.
Күл төбендә үлärмен, дип,
Уйламадым һич кенә!..

Бу бәет Икенче Бөтендөнья сугышыннан, каты җәрәхәтләр алса да, исән әйләнеп кайта алган Мөхәммәт Биккининга багышланган. Кайтып, хәерчелек сазлыгында тибрәнгән авылларын аякка бастырырга дип, җиң сызганып эшләп йөргән батыр йөрәкле элеккеге солдатның үлеме бөтен тирә-якны тетрәндерә. Апалар һәм әбиләр: «Өч баласы белән хатыны утырып калган бит. Әниләренең укытучылык хезмәт хакына гына ничек яшәрләр инде бәгырьләр! Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташлый күрмәсен инде! Хөкүмәт ул балаларга ярдәм итәр инде, әтиләренең күкрәк тулы орден-медальләре булган бит!» – дип, борчылуларын белдерәләр...

* * *

Әхмәт, үзен белә-аңлый башлаганнан бирле, гомерен авыл хуҗалыгы, җир белән бәйләде. Сабый чагыннан ук апаларына, әнисе Гөлсылуга ияреп бәрәңге алганда да хәленнән килгәнчә чүпләшә-булыша торган иде. Үсә, дөньяны күбрәк аңлаган саен, нидер җитмәгәнлекне нарасый күңеле белән тоя торды ул. Тик нәрсә икән? Тора-бара урамга чыгып, үз ишләре белән уйнаганда, шаярышканда берәрсенең әтисе килеп чыгып: «Улым, әйдә, ашарга кайт!», йә булмаса, «Пычракка батып, чучкага әйләнеп беткәнсең бит инде!» – дип сүккәндә, аңа ата кешенең җитмәгәнлеген аңлый башлады. Өйгә кайтып: «Кая соң безнең әти?» – дип төпченсә, әнисе: «Безнеке юк инде, балакаем, юк», – дип, газиз улын итәгенә алып сөя, юата иде. «Нишләп юк соң ул, башка малайларныкы бар, нишләп безнеке юк?» – дип, тагын өзгәләнеп сорап куя. «Үлде шул, улым», – дип, Гөлсылу ханым күз яшьләрен яулык очы белән сөрткәләп ала иде. Мәктәптә белем бирүче, үзенең чамалы гына хезмәт хакына дүрт җанны тәрбияләүче әниләренә өч баланы аякка бастыру җиңелләрдән булмагандыр. Шул сәбәпле, апалары белән Әхмәт кул арасына иртә керде. Өстәвенә, дәү әтисе белән дәү әнисе,

---

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

кызларының ире, ягъни кияүләре вафат булгач, төп нигезне ташлап, шунда күченде. Әлегә хәтле азмы-күпме терәк булган өлкәннәрнең бу галәмәте сугыштан соңгы ачлы-туклы, мең ямаулы чорны тагын да катлауландырып җибәрде. Нишлисең, киленгә караганда үз кызлары кадерлерәк шул! Тагын да ныграк мохтаҗлык-хәерчелек китереп басты Гөлсылу апаның гаиләсенә! Ул, башлангычларны укыту өстенә, азмы-күпме кереме булыр, дип, мәктәпнең интернатына мөдир һәм тәрбияче булып урнашты. Өйдә ир кешенең җитмәве аларны тагын да ныграк берләштерде. Йорт тирәсендә Гөлсылу апага ике кызы терәк булса, тора-бара, Әхмәт тә әнисенең төп ярдәмчесенә әйләнде. Ни әйтсәң дә, малай гына булса да, ир кеше бит ул: утынын да вата, чалгы тотып, печәнен дә чаба. Ләкин үсә төшкән саен, әтисен юксынуы аның күңелендә куерганнан-куера гына барды. «Әй, әти, син дә исән булсаң икән!» – дип, кешегә сиздерми генә сыкрый иде Әхмәт.

* * *

...Иске Казиледә гомер итүче Нургали абзыйның үзен дә, өч улын да сугышка алалар. Шуларның берсе – Арслангалие яу кырында ятып кала. 1943 елны чакырылган Мөхәммәтне, яшь солдатларны әзерләү мәктәбен тәмамлагач, Днепропетровск 10 нчы танк корпусының 11 нче мотоукчы бригадасына элемтәче итеп билгелиләр. Теньки районы хәрби комиссариатыннан киткән комсомол әгъзасы, туган илен саклап, яу кырында зур батырлыклар күрсәтә. Партиягә, туган иленә бирелгәнлекне тулысынча раслый. Аның бүләкләү кенәгәсендә: «Риганы алуда күп батырлыклар күрсәткәне һәм дошман атакасын кире кайтарудагы батырлыклары өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә», – дип искәртелеп кителә.

1944 елның 24 октябре. Подполковник Эйдельман кул куйган документлардан шунысы аңлашыла: бу канкойгыч сугышта ул тагын бер бүләккә лаек була. «Отделение командиры кече сержант Мөхәммәт Нургали улы Биккинин, үзенең кул астындагы солдатларга яхшы тәрбия бирә алганы, Риганы алганда күрсәткән каһарманлыгы өчен, Кызыл Йолдыз орденына лаек», – дип язылган Аэродромнарны саклау һәм тәэмин итү батальоны командиры өлкән лейтенант Татаренко әзерләгән бүләкләү документында. Бүләкләү кенәгәсен актара торгач, тагын бер сәхифә ачылды. Элегрәк 0571, 3-го ПВФ санлы әмер белән ул 1944 елның октябрендә Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән булган икән. Димәк, әлегесе – аның иң беренче ордены. Бүләкләү документы, шул чорда фронтташ дуслары белән төшкән фотосурәте дә шуны дәлилли.

Уртада – Мөхәммәт Биккинин. 1944 ел

Мине иң нык гаҗәпләндергәне – Мөхәммәт аганың уң күзен, шул ук яктагы колагының ишетү сәләтен югалткан килеш тә, кире сугыш кырына кайтып, хәрби хезмәтен дәвам итүе. Кемнәрдер кулына яки аягына үзе пуля җибәреп исән калырга, су-

Мөхәммәт Биккинин гаиләсе белән. Уртада – бертуган сеңлесе Дания. 1956 ел

гыш кырыннан качарга тырышса, Мөхәммәт Нургали улы шул хәлендә дә туган иленә тугрылыгын раслый. Әле фашистлар Германиясе капитуляция ясагач та, ул хәрби хезмәтендә кала. Сыңар күз, чукрак колак белән эш итүләре бер дә җиңелләрдән булмагандыр. Әллә үз хәлен аңлап, әллә инде җитәкчелекнең таләбе беләнме, Мөхәммәт Биккинин хәрби хезмәттән азат ителә. Бер күзгә сукыр, уң колакка чукрак калып, бик күп айлар госпитальләрдә дәвалангач, туган авылына үз аягы белән кайтып төшә. Ул чагында күмәк хуҗалык «Дөрес юл» дип аталса, без белгәндә Ленин исемендәге колхоз иде. Мөхәммәт абый анда башта-идарә хисапчысы, аннары гомеренең соңгы тугыз елында авыл советы рәисе булып эшли. Үзенең ярдәмчеллеге, кешелеклелеге белән аерылып тора. Ни кызганыч, утлар-сулар кичеп, каты яралар алса да, туган авылына исән кайткан ата кеше, майның эссе бер көнендә су кереп, көзән җыерудан батып үлә. Бу фаҗига Иске Казиле авылы халкын гына түгел, тирә-як авылларныкын да бик тетрәндерә. Ул вакытта бишенче яше белән барган кызы Галия: «Иртә белән эшкә барганда әти мине дә, җитәкләп, үзе белән алгалый иде. Сельпо тирәсеннән узган апалар мине: «Галия тагын күзен юмагандыр әле», – дип шаяртып үртиләр иде. Мин аларга: «Юдым, юдым күземне!» – дип акланам. Соңыннан аңладым: моңа әтиемнең миңа: «Кара күзем», – дип яратып эндәшүе сәбәп булган икән. Бервакытны әтиемнең кибеттән төсле карандашлар алып бирүе, аның кабинетындагы өстәл артына утырып, рәсемнәр ясаганыбыз хәтеремдә. 12 май көнне язмыш безнең гаиләгә коточкыч фаҗига алып килде. Бөтен кеше елый, әтине озатырга мине дә күтәреп алып бардылар. Аны соңгы тапкыр күрүемне аңлап та бетермәгәнмен әле мин. Көз көне 21 ноябрьдә, үзенең әтисез калганлыгын, аны гомерендә дә күрә алмаячагын белмичә, энебез Әхмәт дөньяга килде. Ул көнне ишеп-ишеп ап-ак кар яуды. Без апам белән чана шудык. Өйгә кайтсак, әни янында биләүгә төрелгән бик матур малайны күрдем. Чишенеп, алар янына сәкегә үк менеп кунакладым. Алдагы көннәребездә әниебез безнең өчен әни дә, әти дә булды. Нинди генә авырлыклар күрсәк тә, ул безне: «Кеше булыгыз!» – дип тәрбияләде. Әнинең йөзенә кызыллык китермәс өчен, үзебез дә бик тырыштык. Әтиле балалар йоклап ятканда, иртүк торып, суга да бардык, терлекләр дә карадык. Карын да көрәдек, түктек. Җәен мал-туарга кышлык азыгын да әзерләдек.

Гөлсылу апа балалары белән

Урманга хәтле барып, утынын да кистек. Яшелчә үстердек. Колхоз эшенә дә, файдасы булыр дип, бик теләп йөрдек. Әҗере буларак, икмәген бирәләр иде. Өчебезнең дә укуыбыз әйбәт булды. Әни шуның өчен бик горурлана иде. Авылдашларның күбесе тырышлыгыбызны күреп сөенде, кемнәрдер көенде. Иманлы кешеләр арасында: «Әй, Мөхәммәт абый исән булса, сезне күреп сокланыр иде!» – дип сыкраучылар да бар иде».

Тарих мең дә тугыз йөздә
Илле җиденче елда
Фаҗигале эшләр булды
Казиле авылында...

Иманлы кешеләрсез дөнья була алмас дигәндәй, улы Әхмәткә дә андыйлар бик еш очрап торды. Беренче укытучысы Кәүсәрия апасы, бик таләпчән булса да, гадел дә иде. Иске Казиле мәктәбендә, белем белән бергә, тәртипкә дә, игелеклелеккә дә өйрәткәннәр икән. Туган авылында сигез классны тәмамлагач та, укуын дәвам итәргә ниятләде Әхмәт. Күрше Апас районы биләмәләренә кергән Борнаш авылына ун чакрым җәяү йөреп укыды ул. Ни генә эшләсә дә, нинди генә адымга барса да, күңеленнән газиз әтисе белән киңәшә иде. Әнисе генә түгел, әтисе дә: «Укып белемле бул, улым!» – дия кебек иде аңа. Урта мәктәпне дүрткә-бишкә генә тәмамлаган, химияне бик яхшы белгән, республика күләмендәге олимпиадада өченче урынны алган үсмер җиңел генә Химия-технология институтына керә ала иде. Ләкин ул яшьләй үзенең күңеленә якынракны – авыл хуҗалыгын сайлаганлыктан, шул юнәлештәге институтка юл тотты. «Ленин» колхозы стипендиаты биредә дә сынатмады: аның сурәте институтның Почет тактасында эленеп торды. Айлык стипендиянең дә югарысын алып барды. Чөнки аңа үзе өчен генә түгел, аны аякка бастырабыз дип тә тырышкан әнисе, ике апасы өчен дә белем алырга, сынатмаска кирәклеген яхшы аңлады. Институт җитәкчелеге исеменнән килеп торган рәхмәт-мактау хатлары Гөлсылу апаның күңеленә сары май булып яткандыр, иншәАллаһ!

Әхмәт Мөхәммәт улы хезмәт юлын үзләре колхозында баш инженер буларак башлап җибәрде. Җиң сызганып тугыз ай гына эшләп калды ул. Шуннан соң хезмәтен Совет Армиясе сафларында дәвам итте. Ерак Көнчыгыш хәрби округында Тын океан

ярлары тирәсендә үткән еллар күңеленә якты бер истәлек һәм зур сынаулар чоры булып кереп калды. Хәрби тормыш аның характерында «Чишелмәслек хәлләр тормышта юк!», «Сүз бирдеңме – үтә», «Тырыш хезмәт кенә нәтиҗәләрен бирә» дигән принципларны ныгытты.

Армиядән кайткач, Әхмәт Мөхәммәт улы яңадан туган авылында эшли. Үзенең остазлары, аксакаллар дип санаган Шәфигуллин Айдар, Абдуллин Әбрар, Хәсәнов Нургали һәм Зыяфатов Борһан абыйларына мең рәхмәтле ул.

Егетнең тәртипле, ярдәмчел булуы, кешеләр белән уртак тел таба белгәнлеге район биләмәләренә дә тарала. Аны «Госкомсельхозтехника» җитештерү берләшмәсенә баш инженер итеп чакыралар. 1982 елның апреленнән башлап 1985 елның 25 октябренә хәтле ул биредә чарлана. Әхмәтнең намуслы хезмәткәр икәнен күргән җитәкчелек аны Теньки бистәсендәге «Госкомсельхозтехника» махсус бүлекчәсенә директор итеп билгели. Идел аръягында оешманың эшенә яңа сулыш өрә егәре ташып торган егет. Биредә яхшы белгечләр дистә еллар буена тупланган, күбесе, халык теле белән әйтсәк, «алтын куллы», шуларны саклап калу бурычы да килеп баса аның алдына. Кыскасы, 28 яшьлек Әхмәт җиң сызганып эшкә чума.

Бәеткә килгәндә, ул Әхмәт туганчы ук язылган, чөнки Мөхәммәт аганың улы ата кеше күзләрен мәңгегә йомып 6 ай үткәч кенә дөньяга килә. Шул сәбәпле, бәеттә ике кызы белән хатынына гына багышланган урыннар бар:

...Киселде безнең тормышлар,
Хуш, Гөлсылу, онытма!
Мин утырткан каеннарга
Су сибәрсез, корытма!
Наилә кызым, Галия кызым –
«Кара күз» дигәннәрем.
Алларыма алып сөйгәч,
Чыркылдап көлгәннәрем.
Ат белән суга кергәнче,
Кинәт дулкын чайкалды.
Сау булыгыз, әткәй-әнкәй,
Онытмагыз, дусларым!

Әгәр дә Мөхәммәт ага бүгенге көндә, Җиңүнең 75 еллыгы якынлашып килгәндә, исән булса, 95 яшен тутырыр иде. Аллага шөкер, өч баласы – Наилә белән Галиясе, үзе күрергә дә өлгерми калган улы Әхмәт татар милләтенә хезмәт куя. Алар инде Мөхәммәт абыйның оныкларының балаларына тәрбия бирәләр. Батыр йөрәкле солдатның нәселе дәвам итә. Әниләренә терәк булыр өчен эшкә иртә кергән ике кызы – Наилә белән Галия кадерле энеләре Әхмәт Биккининнның югары уку йортында укыганда иң тырыш ярдәмчеләре дә, терәкләре дә булалар.

Әнисе белән якыннарының ышанычын аклады Әхмәт! Ул бүгенге көндә фермер да, умартачы да, иң мөһиме – оныкларына үрнәк бабай – дәү әти дә. Аның фидакарь хезмәте дәүләтебез тарафыннан да югары бәяләнде. «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды ул. Күкрәген «Татарстан авыл хуҗалыгы министрлыгының хөрмәт билгесе» дигән бүләк тә бизи. Россиянең атказанган фермеры да ул. Ләкин Әхмәт өчен әтисе Мөхәммәт Нургали улының Бөек Ватан сугышында кан түгеп алган орденнары барысыннан да кадерлерәк.

...Яз көнендә яфрак ярыр
Мин утырткан каеннар.
Төштә генә күргәндәй булды
Бергә үткән гомерләр.

Бу язмам Бөек Ватан сугышы ветераны Мөхәммәт Нургали улы рухына дога булып барып ирешсен! ■

Сау бул, авыл! ИСӘНМЕ, КАЗАН!

Хәлим Җәләлов

Мин ишле гаиләдә үстем. Без әтидән җиде бала калганбыз. Җидебез дә малайлар. Сугыш башланганда, иң олыбыз Мәхмүт абыйга унбиш яшь була. Сугыш өермәсе аны да үз эченә бөтереп ала. 1944 елда нибары унсигез яшендә Польша җирендә танк эчендә янып үлә ул. Мин аның сугышка чыгып киткәнен ачык хәтерлим. Миңа дүрт яшьләр тирәсе иде. Ә менә хәтергә уелып калган. Арбага төялгән яшьтәшләре безнең өй турысына килеп туктадылар. Мәхмүт абый арбага утырыр алдыннан кинәт борылды да, йөгереп килеп, капка баганасын кочаклап, үксеп елый башлады. Менә шушы күренеш, кинодагы шикелле, бүген дә күз алдымнан китми. Бу аның үлемгә чыгып китүе булган икән.

Калган абыйлар кайсы колхоз эшендә, кайсы ФЗӨдә, кайсы армиядә, ә без, кечерәкләр, мәктәптә. Әнигә үзенә генә тормышны алып бару авыр булгандыр, әлбәттә. Ләкин бу авырлык ил белән килгән иде...

Унынчы классны тәмамлагач, мин Казан авыл хуҗалыгы институтына (хәзерге Казан дәүләт аграр университеты) укырга кердем. Теләгем — авыл хуҗалыгы машиналары буенча инженер-механик булу.

Абыйлар кайсы кая таралышып беттеләр, өйдә, әни янында, төпчек малай – мин генә калдым. Мин дә укырга китсәм, авылда әни япа-ялгыз калачак иде. Шуңа күрә, авылдагы өйне сатып, Казанга күчеп килдек, Бертуган Петряевлар урамында йорт сатып алдык. Минем өчен бөтенләй яңа тормыш башланды. Яңа җир, шәһәр җире. Тик... Ярата алмадым мин аны. Беренче елда авылны сагынып гаҗиз булдым. Мәктәпне, авылны сагынып елаган чакларым булды. Ниһаять, әни, түземлеге төкәнеп, мине авылдан ат җигеп килгән Шәмсетдин җизнигә утыртты да авылга кайтарып җибәрде. Ун көн торып килдем, ун сәгать кебек тә булмады. Авыл шул ук, дуслар шул ук. Көн саен клубка чыгабыз, аулак өйләргә кич утырырга йөрибез. Авыл гөрләп тора. Нигә генә дип Казанга кителгән соң?! Шулай да Казанга кайтырга туры килде. Хат җибәргәннәр. «Тиз кайт, – дигәннәр. – Нәгыйм өйләнә. Институтыңа илтергә бирер справка да юнәтеп кайт».

Миңа Авыл хуҗалыгы институтын тәмамларга насыйп булмады. 1961 елда Казанда театр училищесы ачылды. Тик аңа кадәр дөнья белән шактый гына танышасы бар иде әле.

Казанга килгәч тә, Вахитов клубында, Казан киез итек фабрикасының үзешчән сәнгатендә катнашып, сәхнә тузанының «тәмен» бераз татырга өлгергән идем инде мин...

Вахитов исемендәге клуб әллә ни зур түгел, агач клуб. Сәхнәсе дә кечкенә. Әмма шул сәхнәдә күп кешеләр катнаша торган зур-зур спектакльләр куя идек. Җитәкчебез – танылган артист Һидаят абый Солтанов. Камал театры артисты. Беренче спектаклебез азәрбайҗан драматургы Ж.Җаббарлының «Вафалы (ышанычлы) Сәрия» дигән драмасы иде. Мин, унсигез яшьлек малай, Сәфәргали исемле картны уйнадым. Бу рольне ничек миңа биргәннәрдер инде?! Хәзер әсәрнең эчтәлеге бик хәтердә түгел.



Ш.Хөсәенов. «Зөбәйдә – адәм баласы». Әсхәт ролендә. 1965 ел

Бары тик мин уйнаган картның хәйләкәр булуы, гашыйкларның кавышуына ярдәм итүе һәм тамашачыларның яратып кул чабулары гына истә калган. Спектакльдә төшерелгән фотолар альбомымда саклана. Без бу түгәрәккә Илдус Вәлиев белән бер көнне килеп, бергә йөри башладык. Соңыннан ул да (армиядә хезмәт итеп кайткач), театр училищесын тәмамлап, Камал театрында артист булып эшләде. Искиткеч талантлы артист иде мәрхүм. Тик, кызганыч, гомере генә кыска булды.

Икенче спектаклебез «Тормыш җыры» (М.Әмир) иде. Монда инде мин шаян-шук малай – Каюм ролен уйнадым. Тагын шуны әйтәсем килә: мәктәпне тәмамлаганда, минем буем бик бәләкәй иде. Инде институтта укыйм, ә менә кичке сеанска киного кертмәгән очраклар булды. Берничә тапкыр… Нәкъ инде менә шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең «Буй бәласе» дигән шигырендәгечә. Мин ул шигырьне озак еллар сәхнәдән

дә сөйләп йөрдем. Үземә бик туры килә иде шул. Моны шуның өчен язам: «Тормыш җыры»н куйгач, Һидаят абый бездән китеп барды. Киткән чакта ул миңа: «Сиңа чын артист булырга кирәк иде дә… Ләкин, кызганычка каршы, синең буең бәләкәй. Аннары кыяфәтең дә… Югыйсә артист булырга бөтен мөмкинлегең бар», – дигән иде.

Һидаят абый киткәч, безнең түгәрәккә җитәкче булып Мәсгут абый Имашев килде. Әмма, ничек дип әйтергә, бәхет эше дип әйтимме… Минем буем бер ел эчендә кинәт кенә үсеп китте. (Бер елдан соң очрашкач, Һидаят абыйның гаҗәпләнеп торганы хәтердә.) Үстем дигәч тә, пәһлеван ук түгел инде. Шулай да театр училищесы «стандарты»на туры килерлек булды бугай.

1961 елның җәендә безне кыска вакытлы курсларда укытып, ике ай эчендә комбайнчы һөнәре биреп, чирәм җирләргә, Павлодар өлкәсенә озаттылар. Әле минем мондый ерак юлга беренче тапкыр чыгуым. Аннан яңа тәэсирләр белән баеп кайттык. Ә өйдә мине бер язу көтә иде: «Хәлим, кайтуга, Мәсгут абыйны күр».

Мәсгут абый Имашев ул чакта – Вахитов исемендәге клубта татар драмтүгәрәгенең җитәкчесе. Мин тиз генә Мәсгут абый янына йөгердем. Ул инде училищега керү шартлары белән танышкан иде. Без аның белән имтиханга әзерләнә башладык. Имтихан өчен чәчмә әсәрдән өзек яки хикәя, мәсәл, шигырь өйрәнергә кирәк икән. «Әле өстәмә сораулар да булырга мөмкин, – диде Мәсгут абый. – Җырлатып та карарлар. Сәхнәдә пианино да булыр. Пианинодагы менә шушы кара клавишаларга бас. Синең тональностең шул. Син кыяфәтең белән әллә ни булдыра алмассың, кыюрак бул. Главное, каушап калма».

Әле имтиханга кадәр миңа институттан документларны алырга кирәк иде. Анысы бер бәла булды. Бирмиләр. «Бездә өч ел укыдың, җибәрә алмыйбыз», – диләр. «Мин бит – заочник, читтән торып укыйм. Җибәрмәскә хакыгыз юк», – дим. Бер атна буе көн дә йөри торгач, ниһаять, документларымны бирделәр.

Училищега өч йөз алтмыш гариза кабул ителгән, диделәр. Чама белән татар группасына йөз сиксән гариза була инде. Уналты студент һәм ике кандидат кабул ителәчәк.

10 ноябрь көнне беренче имтихан. Алтмыш кеше имтихан тотачак. Имтиханнарны кичке алтыга кадәр кабул итәчәкләр. Мин эштән соң барырга булдым. Училищега барып кергәндә, коридор тулы кеше, ыгы-зыгы иде. Имтихан тәмамланган. Сәркатип, ишектән чыгып: «Бүгенгә тәмам, соңга калучылар юкмы?» – дип сорады. Мин, ашыгып: «Мин бар», – дидем. Тиз генә пальтомны салып, шундагы урындыкка ыргыттым да ишектән кереп тә киттем.

Өстәл артында утырган абыйларның кайсыберләрен таныйм да кебек. Уртада кабул итү комиссиясе рәисе, олпат гәүдәле Шириаздан абый Сарымсаков утыра. Аның янында Шәүкәт Биктимеров, Празат Исәнбәт, Габдулла Шамуков, Рәфкать Бикчәнтәев. Бүгенгә эш беткән. Шириаздан абый, урыныннан торып, папкаларын, кәгазьләрен җыештыра башлады. Аннары миңа бер күз төшереп алды да, кәгазьләреннән аерылмыйча гына: «Йә, нәрсәләр әзерләдең?» – дип сорады. «Һади Такташ «Җамали белән Камали», — дим.

– Әйдә, сөйлә.

Мин, Мәсгут абый өйрәткәнчә, артык каушамыйча гына сөйли башладым. Ике җөмлә әйтүгә, Шириаздан абый, папкаларын куеп, урынына кире утырды. Башкалар да торырга ашыкмады. Сөйли торгач, бераз мавыгып китеп, кыюланып, өстәл янына якынлашкач, Шириаздан абый: «Чү, чү, сабыррак, сабыррак», – дип, мине арткарак чигендерде. «Тагын нәрсә әзерләдең?» – «Әхмәт Ерикәйнең «Былбыл тирәсендә» дигән мәсәлен». Укып бетердем мәсәлне. «Рәхмәт», – диделәр. Ә бу сүзнең хәтәр сүз икәнен мин белә идем инде. Әгәр икенче турга үтмәсәң, «рәхмәт» дип әйтеп юатып озаталар, имеш. Өметләрем чәлпәрәмә килгәндәй булды. Коридорга чыктым. Көтәбез. Шау-шу. Кайсы көлә, кайсы елый. Менә бераздан исемлекне чыгарып элделәр. Алтмыш кешедән сигезе икенче турга үткән икән. Үз исемемне эзлим. Исемлектә, сигезенче

кеше булып, минем фамилиям тора иде. «Тагын өч көннән икенче тур», – диделәр. Миңа канатлар үскән кебек булды. «Әһә, – мин әйтәм, – тышкы кыяфәт иң әһәмиятлесе түгел икән. Икенче турга тагын да тырышыбрак әзерләнергә кирәк булыр».

Икенче тур 13 ноябрьдә булды. Ул көнне дә чак кына соңга калмадым. Мин барып кергәндә, имтиханнан соңгы кеше чыккан иде. Сәркатип, чыгып: «Соңга калучылар юкмы?» – дип сорады. Мин, тиз генә чишенеп, кереп киттем. Бу юлы Ширияздан абый, мине күрүгә: «Әйдә, Җәләлов, бүген шигырьдән башла әле», – диде. Мин Шәүкәт Галиевнең «Хуҗамал» шигырен ике куплет укуга: «Ярар, җитеп торыр, ә җырлый беләсеңме?» – дип сорады. Мин, кыю гына атлап, сәхнәдәге пианино янына барып, Мәсгут абый өйрәткәнчә, кара клавишага бастым да «Тау башында балкый бер кала…» дип җырлап та җибәрдем. Бер куплет җырлагач, «рәхмәт», дип, мине туктаттылар. Ширияздан абый, өстәл янына дәшеп, каршысына утыртты. Кайда эшләвем, күпме хезмәт хакы алуым турында сораштырды. Мин 125 сум дигәч: «Алай икән, менә без быел театрга Мәскәүдән укып кайткан яшь артистлар кабул иттек, хезмәт хаклары 70 сум», – диде. Телемә кайдан килгәндер инде: «Мин бит күп акча эшләү өчен килмим», – дип әйтеп ташладым. Шуның белән сораулар бетте. «Өченче турга килеп торма, син кабул ителдең. 1 декабрьдән укулар башлана, аңарчы институтыңда да, эшеңдә дә документларыңны җайла, алдагы китек тешеңне дә куйдыр, өлгерә алсаң», – диде. Этюдлар эшләргә туры килмәде. Мин, канатланып, коридорга чыктым. Анда ыгы-зыгы. Менә бераздан берәм-берәм комиссия әгъзалары чыга башлады. Рәфкать абый Бикчәнтәев чыгуга, аны уратып алдылар. Аның өстендә бик матур ыспай пальто, башында үзенә бик килешеп торган зур йонлач бүрек. Ул, туп-туры минем янга килеп, кулымны кысты һәм бик тә җылы сүзләр әйтте. Аның ул сүзләре гомерем буе хәтеремдә саклананалар…

1961 елның 1 декабрендә без беренче дәрескә җыелдык. Курсыбызның җитәкчесе – Ширияздан абый Сарымсаков, укытучыларыбыз – Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимеров, Хөсәен Уразиков, Вахит Хаков, Татьяна Геллер һ.б.

Көндез – дәресләрдә, ә кичләрен көн саен театрда. Спектакльләр карыйбыз. «Спектакль карау – үзе бер дәрес», – диделәр безгә. Ә сәхнәдә нинди артистлар!.. Хәлил Әбҗәлилов, Камал III, Гөлсем Камская, Галия Булатова, Габдулла Шамуков, Фуат Халитов… Берсеннән-берсе кызыграк спектакльләр! «Зәңгәр шәл», «Беренче мәхәббәт», «Татар хатыны ниләр күрми», «Казан сөлгесе», «Зифа» һ.б. Бу спектакльләрне ничәшәр тапкыр караганбыздыр, әйтеп тә булмый.

Икенче көнне караган спектакльләребез турында үзара фикер алышабыз, кызыпкызып бәхәсләшәбез. Бөек артистларыбызның уеннарын да тәнкыйтьләргә җөрьәт итәбез. Нәкъ менә мәзәктәгечә: «Студентлар беренче курста – халык артистлары, икенче курста – атказанган артистлар, өченче курста – артистлар, дүртенче курста студентлар булып укуларын тәмамлыйлар», имеш.

Ә икенче курста инде без үзебез кайбер спектакльләрдә күмәк күренешләрдә (массовкаларда) катнаша башладык. Камал театры сәхнәсенә аяк басу безнең өчен, әлбәттә, әйтеп бетергесез шатлык иде. Әле миңа «Фаҗигале юлда» дигән спектакльдә Бу-юнг исемле хезмәтче ролен дә уйнарга туры килде. Роль зур түгел, сүзләре дә биш-алты җөмлә генә, ә куаныч эчкә сыймый. Программада минем исемемне дә язарга онытмаганнар!

1965 елда, Бөек җиңүнең егерме еллыгына багышлап, «Тормыш җыры» (М.Әмир) спектакле куелды. Монда миңа җырчы малай – Каюм ролен башкарырга туры килде. Бу рольне уйнагач, бер дәрестә Наил Әюпов, уенын-чынын бергә кушып: «Җәләй бер аягы белән театрда инде», – дигән иде.

Без диплом спектакле итеп «Эзоп» (Г.Фигейредо) һәм «Тамырлар» (Ю.Әминов) комедиясен куярга тиеш идек. «Эзоп»ның инде күп өлеше куелган да, ләкин Ширияздан абыйның кинәт каты авырып китүе сәбәпле, эш ярты юлда тукталып калды.

Диплом спектакленнән соң. 1965 ел

Без диплом эше итеп «Тамырлар» спектаклен күрсәттек. Режиссерыбыз – Хөсәен ага Уразиков. Спектаклебез ярыйсы гына барып чыкты. Наил Әюпов белән мине – Камал театрына, Наил Шәйхетдиновны Күчмә театрга (хәзерге Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) кабул иттеләр.

Без Наил белән җәй буе, түземсезләнеп, театрда сезон башланганын көттек. Менә җәйге ялдан соң артистлар, ниһаять, эшкә чыкты. Җыелыш булды, безне, яшь артистларны, труппа иттеләр. Театрга кабул ителүебез белән котладылар. Ә план тактасында инде приказ эленеп тора иде. Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» дигән трагикомедиясе куелачак. Рольләр бүленгән. Ринат Таҗетдинов белән Әсхәт исемле үсмер егет ролен уйнаячакбыз. Ринатның башка спектакльдә җитдирәк эше бар иде. Аннары ул бу рольне уйнарга бик ашкынып тормаганын да сиздерде. «Мин бу роль өчен олырак инде, сиңа гына уйнарга туры килер, бәлки», – диде. Мин, әлбәттә, бик риза идем. Ләкин, һич көтмәгәндә, миңа ашыгыч рәвештә «Ата хакы – Тәңре хакы» (В. Лаврентьев) спектакленә керергә туры килде. Севка ролен уйнаучы актер авырып киткән. Ә ун көннән спектакль чыгарга тиеш. Шушы спектакль белән сезон ачылачак. Рольнең сүзләре күп, Севка – төп рольләрнең берсе. Һич арттырмыйм, икенче көнне репетициягә килгәндә, мин ролемнең сүзләрен ятлап бетергән идем дияргә мөмкин. Режиссерыбыз Празат абый мактап та куйды хәтта. Премьера үтте. Ике көннән газетада рецензия басылып чыкты. Театр белгече Ильтани Илялова, танылган артистлар белән бергә минем исемне дә мактап телгә алган, яшь актерга киләчәктә уңышлар теләгән иде.

Театрда минем беренче сезоным ярыйсы гына уңышлы булды шикелле. «Зөбәйдә – адәм баласы» спектакленнән соң «Күзләре нинди иде?»дә (Ә.Баян) – Рифкать, «Муса Җәлил»дә (Н.Исәнбәт) – Янгир, «Гүзәлем Әсәл»дә (Ч.Айтматов) – Камал, «Хуҗа Насретдин»дә (Н.Исәнбәт) Атамыш ролен башкардым. Бер сезон өчен аз түгел инде бу.

Редакциядән: *Татарстанның халык артисты, язучы һәм тәрҗемәче **Хәлим Бәдретдин улы Җәләловның** апрель аенда гомер бәйрәме – **80 яшь**! Аны юбилее белән ихлас котлап, сәламәтлек, гаилә бәхете, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез!* ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

«Урман кызы»

Мидхәт Фәйзуллин

Һади Такташны искә алу кичәсенә әзерләнгән чакта Җәүдәт Фәйзигә мәрхүм шагыйрьнең өч шигыренә көй язу эше йөкләнде. Шул өч шигырь арасында «Урман кызы» да була. Кичә нибары өч атнадан, ә музыканы, артистларга җырларны өйрәнергә вакыт калдыру өчен, ике атна эчендә язып өлгерергә кирәк иде. Җәүдәт Фәйзи өч шигырьгә дә көйләрне биш төн эчендә иҗат итте.

«Урман кызы», ничектер, баштан ук уңышлы килеп чыкты һәм тиз арада тыңлаучыларның күңелен яулап алды. Бу җырда карурманда туып-үскән чәчәктәй саф һәм гүзәл кызга бер карау белән күңелләрдә ирексездән сөю-мәхәббәт тойгысы уянуы хакында сөйләнә. Төзелеше белән гади, йомшак, ягымлы көй бу образның тәэсир көчен тагын да арттырып җибәрә.

«Син – дошманым минем» җырын композитор марш темпында, ә «Байрак тегәбез» җырын исә романс рәвешендә иҗат итте. Үзенең яңа җырларын автор композитор В.И.Виноградовка күрсәтергә булды, ә ул исә «Урман кызы»н аеруча ошатты һәм аңа югары бәя бирде.

Һади Такташны искә алу кичәсе Галиәсгар Камал исемендәге театрда узды. Программа бик бай эчтәлекле итеп төзелгән иде. Шагыйрьнең иҗаты турындагы докладтан соң, кичәнең әдәби-музыкаль өлеше башланды. Такташның «Күмелгән кораллар» һәм «Камил» пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде. Концерт бүлегендә шагыйрьләр Хәсән Туфан, Сирин, Фатих Кәрим катнашты. Артист Хәким Сәлимҗанов, үзенә генә хас тәэсирле тавыш белән, Такташның «Киләчәккә хатлар»ын укыды. Фәйзулла Туишев – гармунда, Заһид Хәбибуллин скрипкада шагыйрьнең яраткан көйләрен уйнады. Җырчылар Салих Сәйдәшев җырларын җырлады. Аннан соң артистлар Җәүдәт Фәйзинең яңа әсәрләрен башкардылар. Ситдыйк Айдаров, А.Сәгыйтов һәм Галия Кайбицкая башкаруында «Син – дошманым минем», «Байрак тегәбез», «Урман кызы» җырлары яңгырады. Җырчыларның өчесен дә халык бик җылы каршылады, әмма аеруча игътибар һәм кул чабулар Галия Кайбицкая өлешенә тиде. Шушы кичәдән соң, инде җыр радиодан да яңгырагач, аны бөтен концертларда җырлый башладылар. Җырны аеруча яшьләр күтәреп алды, «Урман кызы»н хәзер бөтен җирдә ишетеп була иде: һәвәскәр сәхнәләрдә, өйләрдә, паркларда, урамда... Бу Җәүдәт Фәйзинең композитор буларак халык арасында танылуы иде.

Җыр халык арасында шундый таралды ки, аны хәтта чит илдән килгән студентлар да үз итте. Казан дәүләт университетының актлар залында уздырылган бер концертта университетта укыган Корея студенты Ан Си Ун, җырны татар telendә башкарып, зур алкышлар ала. Бу концертта булган шагыйрь Мәхмүт Хөсәен икенче көнне Җәүдәт Фәйзигә шалтырата һәм шушы гаҗәеп вакыйга турында сөйли. Композиторда кызыксыну уянып, ул Мәхмүт Хөсәеннән Ан Си Ун белән бергә аның өенә килүне үтенә.

«Урман кызы» җырын beznenmiras.ru сайтыннан тыңларга мөмкин



«Урман кызы»ның беренче басылган нотасы. Авторы – Җәүдәт Фәйзи. 1935 ел

Берничә көннән инде алар Җәүдәт Фәйзидә кунакта булалар. Әлбәттә, анда Ан Си Ун композитор өчен «Урман кызы»н татар телендә махсус җырлап күрсәтә. Җәүдәт Фәйзи моңа бик канәгать була, студентка җылы рәхмәт сүзләре әйтә һәм башкаруга кагылышлы берничә төзәтмә кертә.

Берничә елдан соң Җәүдәт Фәйзи үзе җитәкчелек иткән концерт бригадасы белән Кореяга бара. Самолет кич белән соң гына Пхеньянга килеп төшә. Соң булуга карамастан, Советлар берлегеннән килгән артистларны зур чәчәк бәйләмнәре

белән Кореяның рәсми вәкилләре, мәдәният, әдәбият-сәнгать әһелләре каршылый. Аэропортның кунаклар кабул итү залына чакыралар. Җәүдәт Фәйзи, делегация җитәкчесе буларак, алдан атлый. Шул чакта кинәт кемдер аның җилкәсенә кулын сала. Көтелмәгән бу хәлгә Җәүдәт Фәйзи сискәнеп куя. Борылып караса, аның янында, елмаеп, Ан Си Ун тора. Ул инде күптән укуын тәмамлаган һәм менә, Мәдәният министрлыгы хезмәткәре буларак, кунакларны каршыларга килгән икән. Концерт бригадасын рәсми кабул итү мәҗлесендә, Җәүдәт Фәйзигә хөрмәт билгесе итеп, Ан Си Ун йөрәгенә сеңеп калган «Урман кызы»н тагын бер тапкыр татарча җырлый.

Тагы бер истәлекле очрашу Пхеньяндагы Совет илчелегендә була. Концерт бригадасы җитәкчесе вазыйфаларын башкарган Җәүдәт Фәйзи, кайбер мәсьәләләрне хәл итү өчен, илчелеккә бара. Илчелек вестибюленә кергәч, кизү торучыга эшнең асылын аңлатып бирә. Аңа бераз көтеп торырга кушалар.Тиздән келәм җәелгән баскычтан пөхтә киенгән, елмаюлы йөзле бер кеше төшә. Күрешергә кулын сузып: «Урман кызы» авторын күрүемә бик тә шат», – ди. Каршында рәсми кешеме, әллә очраклы бер музыка сөючеме икәнен белмәгәнлектән, Җәүдәт Фәйзи бераз аптырап кала, үзен уңайсыз тоя. Аның бу хәлен аңлаган теге кеше: «Сез мине танымадыгыз, ахры, Җәүдәт Харисович, ә бит без кайчандыр танышлар идек», – ди. Әммә композитор барыбер аны танып җиткерә алмый. Шуннан теге кеше, татарча сөйләүгә күчеп, үзен таныштыра: «Мин – Фәтхуллин, Казанда Татар академия театрында барган «Күзләр» драмасының авторы, без Сезнең белән спектакль караганда танышкан идек», – ди.

– Ә монда Сез нәрсә эшлисез? – ди Җәүдәт.

– Илчелектә рәсми хезмәттә торам.

Шуннан соң җанлы әңгәмә башланып китә.

Кореядагы концертлар зур уңыш белән үтә. Җәүдәт Фәйзи гастрольдән бик канәгать булып, «яшәреп» кайта.

«Урман кызы» бер Кореяда гына җырланмый. РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Фәхри Насретдинов 1958 елда РСФСР Мәдәният министрлыгы оештырган концерт бригадасы составында Вьетнам белән Бирмага барган чакта бу җырны үзенең репертуарына кертә. Аннан соң 1960 елда Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле белән Кытайга баргач та, Пекин һәм башка шәһәрләрдәге концертларда, очрашуларда «Урман кызы»н җырлый. Фәхри Насретдинов сөйләвенчә, бу җыр Вьетнам һәм Кытай тамашачылары тарафыннан бик җылы кабул ителә.

Бераз читкә тайпылдык бугай. Төп темага әйләнеп кайтыйк. «Урман кызы» тыңлаучыларның яраткан җырына әверелде. Бу җыр язылган чакта аның авторына нибары егерме ике яшь иде. Җәүдәт Фәйзи иҗат иткән өч йөздән артык җыр арасында ул иң популяр җыр булып калды.

Мәскәү консерваториясе каршындагы татар студиясенә кандидатлар сайлаганда җитәкчелек алдында «Җәүдәт Фәйзи белән нишләргә, университетның хокук кафедрасында укытучы булып калсынмы яки аны консерваториягә җибәрергәме» дигән мәсьәлә килеп баса. Монда композитор В.И.Виноградов әйткән сүзләр хәлиткеч роль уйный. «Юристлар бездә бар һәм алар, һичшиксез, тагын булыр, әмма «Урман кызы» кебек моңлы җыр яза алган музыкантка юл бер генә – бары тик консерваториягә!» – ди ул.

4 октябрь, 1984 ел

*Материалларны журналга, Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруындагы чыгышка нигезләнеп, **Рөстәм Акъегет** әзерләде.* ■

Сулдан уңга: Заһид Хәбибуллин, Илһам Шакиров, Рәфкать Гомәров. 1969 ел

Филармония артистлары Төрекмәнстан шәһәрләре буйлап гастрольдә. Сулдан уңга: Фәйзи Йосыпов, Рәфкать Гомәров, Илһам Шакиров балалар янында. Чарджоу шәһәре. 1965 ел

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

ӨЧЕНЧЕ ҺӘМ ДҮРТЕНЧЕ УНЪЕЛЛЫКЛАР (1957–1977)

■ 1950 еллар ахырында Концерт бүлеге икегә бүленә: әдәби-музыкаль лекторий һәм эстрада бүлекләре барлыкка килә.

■ 1950 еллар азагыннан алып 15 ел дәвамында тамашачыларның классик һәм халык музыкасына ихтыяҗы гаҗәеп югары була. Бу елларда Музыка сәнгате университетлары ачыла. Филармония аларның иң зурысы санала.

■ Концерт-лекцияләргә билетлар абонемент системасында сатыла. Аларга бик күп студентлар, мәктәп һәм профессиональ белем бирү училищелары укучылары йөри.

■ Концертлар Казанның барлык сәнгать сарайларында һәм Югары уку йортларында – Техник һәм Технологик институтта уза. Иң популяр мәйдан – Казан финанс-икътисад институтының актлар залы була.

■ Концерт-лекцияләр Яшел Үзән, Әлмәт, Бөгелмә һәм Түбән Кама шәһәрләрендә дә уза һәм зур популярлык казана.

Мәдәният хезмәткәрләренең үзәк йортында үткән концерттан соң. 1970 нче еллар

Судан уңга: Николай Велижинский, Геннадий Кляузов, Әлфия Авзалова, Кәрим Габидуллин, Виталий Самойлов, Юрий Любезнов. 1972 ел

Уфадан Стәрлетамакка барган вакыт. Сулдан уңга: Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Айрат Арсланов, Нәҗия Минкина. 1975 елның октябре

■ Чаллыда Татар филармониясенең филиалы оеша. Лекторий артистлары ТАССРда танылуга ирешә.

■ 1960 еллардагы абонемент цикллары: «Орган һәм солистлар», «Музыка дөньясында яшик», «Истәлекле музыкаль даталар», «Музыкаль классицизм», «Музыкаль романтизм», «Фортепиано музыкасының сайланма битләре», «Орган музыкасының сайланма битләре», «Татар композиторлары – балаларга», «Илләр һәм континентлар буйлап», «Совет композиторлары – Ленин премиясе лауреатлары», «Музыка жанрлары тарихы битләреннән», «Симфоник эстрадада опера һәм балет музыкасы», «Җырның зур тормышы», «Шаян жанрның җиде бите», «Классиканың алтын тупланмасы», «Иоганн Себастьян Бах, аның замандашлары һәм элгәрләр», «Борынгы музыка», «Аурупа илләре буйлап», «Әдәбият һәм музыка» һ.б.

■ Артистлар тулай торакларның «Кызыл почмак»ларында, авыл мәктәпләрендә, завод цехларында да чыгышлар ясый.

■ Филармония Казанның мәдәният сарайларында иҗтимагый сәнгать советлары оештыруга ирешә.

■ 1960 елларда филармония уздырган концертларга билетлар табу кыен була, алар бик тиз сатылып бетә.

■ 1960 еллар азагында Казан дәүләт университетында абонемент кысаларында узган Бородин квартеты концертында данлыклы дирижер Натан Рахлин, урыннар булмау сәбәпле, артистлар чыгышын аудиториядән алып кергән өстәмә урындыкка утырып тыңлый.

■ 1970-1980 елларда филармония артистлары елына 4700әр концерт бирә.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, язучыларның Такташ премиясе лауреаты **Рашат Мияссәр улы Низамиев** Татарстанның Саба (хәзерге Теләче) районының Олы Мишә авылында 1950 елның 1 мартында туган.

Яңа тарих язылганда...

Рашат Низами

Элгәредә: «Татар – хәтәр», – дип әйткәннәр,
Гаярьлеген күздә тотып бу халыкның.
Московияне «иго» белән изгән, имеш –
Күрче тарих битләренең юхалыгын!

...Канлы чукмар тотып Илгә кизәнгәннәр,
Ялгыз Казан ханлыгына афәт иңгән.
Идел-йортта күк тетрәгән – чаңнар кагып,
Кылыч селтәп чукындыру афәтеннән.

Буйсынырга теләмәгән халыкларны
Россиядә көтеп торган кара зиндан.
Күз яшенә, канга манып, боргаланып,
Ялган тарих яза биргән Карамзиннар.

«Без исән!» – дип оран сала белдек, ләкин
Ак патшалар, Державаның кысымында.
Менә йөрәк! Күрәсезме, һәммәбезнең
«Кол булмаска» дигән утлы күзы монда.

...Тел вә лөгать алмашып без яшәсәк тә,
Өстебезгә ябырылды яңа афәт:
Дума агай уйлап тапкан кануннарга
Сыймый, имеш, Тукай теле һәм мәгърифәт.

Канун белән, чиле-пешле закон белән
Хәзер инде кизәнәләр Туган телгә!
Чакматаштай чәчрәп торган бүз халкыма
Телиләрме «татар – батар» дип әйтергә?

Юк, батмабыз! Безнең кораб – төзек, исән,
Яшәү төсе балкып тора байрагыннан.
Безнең татар янә калкып чыгачактыр
Мең елдан соң гасырларның аймагыннан!

Редакциядән: Мөхтәрәм каләмдәшебезгә 70 яшь тулды. Аны күркәм гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез! ■

Эт көннәре

Рәис Сәфәров

Эт атамасына бәйле сүзләр, тәгъбирләр, әйтемнәр телебездә йөзләрчә. Алар барысы да ниндидер тискәре, кире, начар мәгънәне белдерә: «эт көненә калу», «этлемәчеле яшәү», «эт белән эт булу», «эт итеп сүгү», «эт каешы», «эт туе», «эт сугару», «эт – эткә, эт – койрыкка», «эттән туган нәрсә», «этлек», «этләнү», «этләү» һ.б.

Ә менә шушы эткә уңайрак караш белдерә торган, аны «эттән алып, эткә салып» сүкми торган берәр җылы сүз бармы? Бар! Ул да булса – «каникул» сүзе. Әйе, әйе, ул – укучыларның гына түгел, хәтта конгрессменнарның да җаен һәм кышын рәхәтләнеп күңел ачып яткан вакытын белдергән сүз.

«Ә этнең бу каникулларга нинди катнашы бар соң?» – диярсез. Турыдан-туры, чөнки юнанча (грекча) канис – «эт», каникула – «эт баласы» (көчек), каникуллар (каникуларис диес) – «эт көннәре» дигән сүз. Барлык Европа телләрендә дә каникул сүзе эт исеме белән бәйле. Немецча – «һунде таген», французча – «йоурис канис», инглизчә – «догдейс». Нигә бу күңелле ял вакыты эт исеме белән йөртелә соң? Моның тарихы юнан (грек) мифларына барып тоташа: Юнанстанда бөтен яктан да килешле чибәр пәһлеван, мәргән, сунарчы егет Орион яшәгән. Аңа Зевс хода кызы Артемида һәм таң ходасы гүзәл Эос та гашыйк була. Артемиданың мәхәббәте шундый көчле, шашкын була ки, ул, көнләшүдән ярсып, Орионны үтерә. Юнанның Олимп ходалары гаепсез үтерелгән Орионны күккә иңдерәләр. Ул йолдызга әверелә. Орион артыннан аның иң яраткан ике эте дә күккә иңә. Шулай «Орион», «Олы Эт», «Кече эт» йолдызлыклары барлыкка килә. «Олы эт» («Созвездие Большого Пса») йолдызлыгындагы Сириус – галәмдә иң якты йолдызларның берсе. Ул күк йөзендә җәйге челләдә, иң эссе көннәрдә пәйда була, бөтен эшләр, укулар «эттәй эсселек» бераз сүрелгәнче туктатыла – җәйге каникуллар, җәйге «эт көннәре» башлана.

Ә бу этләрнең иясе – Орион йолдызы күк йөзендә елның иң салкын көннәрендә, этләр ояларыннан чыгарга курка торган чатнама салкыннарда – кышкы челләдә күренә башлый. Тагын «эт көннәре» – кышкы каникуллар килеп җитә, тагын мәктәпләрдә укулар туктатыла, парламентлар, конгресслар ялга таралалар.

Күрәсез, «эт көннәре» вакытлыча, үтә дә китә, ә менә халык кичерә торган эт көннәре, озакка сузылып, эт тормышына әверелмәсен иде.

Текстны журналга, Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруында яңгыраган чыгышка (1980) нигезләнеп, ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2020

Көлке куа килә...



Гамил Афзал. Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Гамил Афзал

Саескан

Була кеше, ун тел белә,
Ихтирам итә барсын да;
Безнең малай бер тел белсә,
Ана теленнән тарсына.

1961

Илдар Юзеев

Бу бит безобразие!

60 нчы елларда йөзәр кешелек банкетлар үткәрү гадәти хәлгә әйләнде. Ай саен, атна саен бер банкет... Мәҗлесләрне мәшһүр аш-су остасы Юныс Әхмәтҗанов әзерли, үзе үк тостын да әйтеп җибәрә. Заһит ага Хәбибуллин юбилей мәҗлесенә мине дә чакырды, хәтта тамада итеп билгеләде. Тост артыннан тост, дус артыннан дус... Берзаман, малай, пенсионерлар кызып китте: татар ашханәсен дер селкетеп биергә тотындылар. Бии торгач, абзыйларның берсе ауды... һәм, шунда ятып, җан тәслим кылды. Мәҗлес халкы тарала башлады. Заһит ага, ни әйтергә дә белмичә, тегене әрли: «Бу бит безобразие! Кешенең юбилеена килеп, шулай итәргә ярыймыни инде?!»

Зыя Мансур

Галәм киңлекләрен яулаганда

(Кабул иту бүлмәсендә уйланулар)

Ракеталар оча бер-бер артлы,
һәм алдан ук белеп торасың:
һәркайсының
Кайчан, кайда җитеп,
Нинди юллар сызып узасын.

Әйтерсең лә, уен эш кенә бу,
Әйтерсең лә,
Узып барасың,
Ай белән Җир араларын түгел,
Әлмәт белән Шөгер арасын.

Ә мин менә
Ничәнче көн инде
Приемныйда чират көтәмен.
Белә алмыйм һаман начальникның
Кайчан, ничек кабул итәрен...

Туфан Миңнуллин

Әйт шуны!

Татар җыелган җирдә
Бәйрәмсез булмый бер дә.
Гәрәй Рәхим

Татар җыелган җирдә
Бәхәссез булмый бер дә.
Өч-дүрт татар – ун мәсләк.
Берсен-берсе дөмбәсләп,
Милләт, ди-ди, көн итә,
Дин, дип, сәҗдәгә китә.
Кирәк икән укына,
Кирәк икән чукына –
(Мөселман һәм керәшен)
Шундый кавем, күрәсең.
Типтәрләре, мишәре,
Кырымдагы ишләре
Якты көн өмет итә.
Көн артыннан көн үтә,
Ә Мәскәү абзый көтә –
Бу татар кайчан бетә?
Тик татар төкерми дә,
Еламый, үкерми дә,
Ипи булса, шул җитә –
Җыелып бәйрәм итә.

Гәрәй Рәхим. Л.Лерон шаржы

Ризван Хәмид

Өч галим һәм юлбарыс



Ризван Хәмид. Л.Лерон шаржы

Өч галим борынгы мәгарәдә яшәгән кылыч тешле юлбарыс сөякләренә юлыга.

Берсе әйтә: «Мин моның скелетын кабат җыеп бирә алам», – ди.

Икенчесе әйтә: «Ә мин скелетына кабат тән үстерә алам», – ди.

Өченче галим шуңа җан өрә алуын әйтә. Һәм шулай итәләр дә. Юлбарыс терелә дә өчесен дә тотып ашый. Без нәкъ шул галимнәргә охшаганбыз: берәүне күкләргә чөеп мактый-мактый юлбашчы итеп күтәрәбез дә... ул безнең башларыбызны ашарга тотына.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

МАРТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 3 мартта ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфтиТәлгать хәзрәт Таҗетдин белән очрашты һәм аңа татар телендә нәшер ителгән «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» китабын тапшырды.

● 3 мартта Ф.Хөсни исемендәге премия иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган язучы Госман Гомәр вафат булды.

● 4 мартта Россия премьер-министры М.Мишустин Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын һәм «Зөя утрау-шәһәре»н музейлаштыру проекты өчен проект җитәкчесе, ТРның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фондының Иганәчеләр советы рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиевне һәм проект концепциясе авторы, КФУ ректоры Илшат Рәфкать улы Гафуровны Россия хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге премиясе белән бүләкләү турындагы карарга кул куйды.

● 6 мартта Башкортстанның Кушнаренко районында урнашкан Илек авылында нәни татар кызлары арасында «Татар кызчыгы-2020» исемле бәйге үтте. «Ак калфак» хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының Башкортстан бүлеге рәисе Люция Вафина бәйгедә катнашкан барлык балаларга да бүләкләр тапшырды.

● 7 мартта Казанның С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев «Ел хатын-кызы» бәйгесендә җиңүчеләрне (Л.Усманова, Э.Китаева, Ә.Байкина, О.Айдуганова, У.Сатыбаева, О.Ланцова һ.б.) котлады.

● 8 мартта Төркия башкаласы Анкарада узган XIV китап ярминкәсендә Роза Туфетулованың төрекчәгә тәрҗемә ителгән «Язмыш җиле» китабы тәкъдим ителде. Татар китабының төрекчә

варианты «Гөлсем» дигән исем белән Евразия Язучылар берлегенең «Бәнгү» китап нәшриятында басылган.

«Язмыш җиле» әсәрен танылган галимә һәм шагыйрә Чулпан Зарипова-Четинның элеккеге студенты, Афйон Коҗатәпә университеты галимәсе Гүлшаһ Йылмаз тәрҗемә иткән.

● Әлмәт татар дәүләт драма театрында Татарстанның халык артисты, режиссер, Бөек Ватан сугыш ветераны, Әлмәтнең мактаулы гражданины Зәкия Туишеваның (1919-2018) тууына 100 ел тулуны билгеләп үттеләр.

● 13 мартта РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, республиканың Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле композитор Ренат Еникеев вафат булды.

● 18 мартта «Миллият» йортында мөһаҗир-шагыйрь Шиһаб Нигъмәтинең (1913-1995) «Әй, татарым, әй, син – җаным!» дигән китабын тәкъдим итү чарасы узды. Чарада әлеге китапны үз акчасына дөньяга чыгарган галим Хатыйп Миңнегулов, җыентыкны өстәмә тираж белән нәшер иттергән «Мәскәү татар штабы» җитәкчесе

Рөстәм Ямалиев, Ш.Нигъмәтинең оныгы Муса Нигъмәтуллин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, татар зыялылары һәм журналистлар катнашты.

● 21 мартта Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, күренекле галимә Резеда Ганиева вафат булды.

● 22 мартта Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында мәгърифәтче, мөгаллим, татар методик әдәбиятына нигез салучы, беренче дипломлы рәссам-каллиграф, тәүге рәсемле әлифба (1914) авторы Шакирҗан Таһирига (1858-1918) багышланган фәнни-гамәли конференция узды.

● 23 мартта «Безнең мирас» журналы редакциясе, Буа якташлык җәмгыяте белән берлектә, «Борһан Шәһиди – күпкырлы шәхес: дәүләт эшлеклесе, галим һәм язучы» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы уздырды.

● 27 мартта Татарстанның халык шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин вафат булды. ■

Мирасворд

Оренбургта 1906-1918 елларда чыккан татарча газета

Фаил Шәфигуллин туган авыл

Чәй чүбе (диал.)

Аргамак, тулпар

Марсель Галиевнең 2005 елда чыккан китабы

«Киләчәккә ...лар» (Һади Такташ)

Һиндстанда раджа хатыны

Кениядәге елга

... Клаус

Үзәге – Болгар шәһәре

Мылтык көпшәсен чистарту, майлау өчен тимер чыбык (иск.)

Тарихи вакыйганы, атаклы кешенең истәлеген мәңгеләштерүче корылма

Актаныш районындагы авыл

Әбү Рәйхан әл-...

... Зөлкарнәй

Кытайда императорлар династиясе

Фин-угор халкы

Әсәрнең бәян итү объекты

Ат җигү дирбиясе

Хәзерге Франциядә яшәгән кельт кабиләсе кешесе

Гаффар, Мушинский

Шагыйрьләр Әхмәтҗанов, Миңнуллин

Гармун төре

Германиядәге елга

Хәбир Ибраһимның әдәби тәхәллүсе

Александр Македонскийның полководецы

Совет астрономы

Г.Тукайның 1912 елда язган шигыре

Гарәп артикле

Эшнең алга баруы, үрчүе (диал.)

Нильс ... (Дания физигы)

Мәҗүси потханә, табыну урыны (бор.)

Төньяк ярымшардагы иң якты йолдыз

Җиргә казып ясалган чокыр, җәнлек оясы (диал.)

Федерико Гарсиа ...

Фаил Шәфигуллинның 1969 елда чыккан шигырьләр китабы

Борынгы Мисыр мифологиясендә күк Алласы

Купшы, кияз

Г.Тукай яшәгән кунакханә

Балетмейстер ... Таһиров

Анда тукмак та бии

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: әүкат, кока, АН, лазем, Руми, кибар, «Шомбай», «Ургыл», Луи, акара, лак, зир, Лакруа, Рим, Иртыш, ызу, Ола, Ван, язучы, ясак, Роза, Арарат, Гамбәр.
Өстән аска: «Әхлаксызлык», «Көз», буар, уяз, Арк, ура, Тимергалин, чорма, ырам, сыза, шлак, бура, ригая, Кәрами, ур, ситар, Булатова, Кампала, ылак, Ани, Кашан.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы /апрель

Муса Җәлил һәйкәле. Оренбург

990 ел элек (1030)

30 апрельдә солтан Мәхмүт Газнәви (хәзерге Һиндстан, Пакъстан, Әфганстан вә Үзәк Азия илләре киңлегендә ислам динен күндергән шәхес) вафат була.

635 ел элек (1385)

Алтын Урда ханы Туктамыш, зур табыш китерә торган сәүдә юлларына ия булу ниятеннән,Тәбриз (хәзерге Иранга карый), Марага, Маранд вә Нахичеван (хәзерге Азәрбайҗан) калаларын басып ала, гаскәрләре ике йөз меңгә якын әсирне кулга төшерә.

125 ел элек(1895)

3 апрельдә күренекле журналист, җәмәгать эшлеклесе вә «Чаян» журналына нигез салучыларның берсе Мәхмүт Бөдәйли дөньяга килә.

115 ел элек (1905)

Бакы (Баку) каласында Әхмәтбәк Агаев мөхәррирлегендә «Иршад» («Хакыйкатькә юл») дигән газета чыга башлый.

90 ел элек (1930)

12 апрельдә «Кызыл Татарстан» газетасында Һади Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасыннан «Беренче хат»ы дөнья күрә.

80 ел элек (1940)

27 апрельдә Татар дәүләт академия театрында Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» әсәре буенча спектакль куела.

55 ел элек (1965)

6 апрельдә РСФСР Министрлар Советының Казан шәһәрендәге Пионерлар сараена Абдулла Алиш исемен бирү хакындагы карары чыга.

25 ел элек (1995)

7 апрельдә Оренбург шәһәре хакимияте калада Муса Җәлилгә һәйкәл кую турындагы карар кабул итә.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Апрель 2020

И останется в мире слово моё...: Хасан Сарьян.

Историческое наследие: «Род Маматевых – гордость Параньгинского района». Ф.Мусин-Маматев; «Первая царица Улуса Джучи и ислам». И.Миргалиев; «Вы не исчезнете!» (Вечера, посвящённые Тукаю на Дальнем Востоке). Л.Муртазина; «Починок Сосна в жизни поэта». Л.Мухаметшина; «Имя твоё красиво, кто же назвал тебя так?» Г.Хазиева.

Татарский мир: интервью с директором Дома дружбы народов РТ Иреком Шариповым.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Волга и Муса». М.Хасанов; «Критика – необходимая вещь». Э.Шарифуллина.

В глубинах памяти: «Раскаяние на всю жизнь». Ф.Кутлу; «Тоска». Р.Сагди.

Художественное наследие: «Лесная девушка». М.Файзуллин.

Слово – украшение языка: «В дни, когда пишется новая история...» Р.Низами.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

АЛХӘБӘР:

М.Әбделганиева. «Совет чоры ислам ядкәре: Хәниф Вәлиев язмалары»

- **Алтын Урдада пандемия – чума афәте.** Тимур Хәйдәров
- **Тукай ул – безнең татар халкының дәүләте.** Туфан Миңнуллин
- **Батырлар табыла вакыт белән...** Илфар Габдрахманов
- **Фасилның моң чишмәсе.** Әгъзам Фәйзрахманов
- **Галәветдин мулла язмышы.** Равил Салиев
- **Совет чоры ислам ядкәре: Хәниф Вәлиев язмалары.** Мәдинә Әбделганиева

Әдип авылы — фотоларда

Фотолар Арча районының Гөберчәк авылындагы
М.Мәһдиев музее (җитәкчесе – Халидә Габидуллина) фондыннан алынды.

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ындыр табагында – Фирдәүсә белән Миңҗамал

Умартачы Фәһметдин абый

Рәхимҗан һәм Гобәйдулла бабайлар. Уртада – Гобәйдулланың оныгы Ясәви

Авылга яңа трактор кайткач. Механизатор – Борһан Хәбибуллин

ИКЕ КАЗАН

Иванов мәйданы һәм Спас манарасы
Абдулла Дубин архивыннан

Спас манарасы, Кремль урамы

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
• *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
• редакциядә
• *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.